ISSN:2500-011x

Безнең МИРАС

07
июль 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Илдән килгән кунакны
Кабул иттең, Кулаткы!

Сабан туе һәм Иске Кулаткы авылының кайбер истәлекле урыннары белән журналның 58-59 битләреннән һәм www.beznenmiras.ru сайтыннан танышырга мөмкин.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең Мирас

12 +

7(54)

июль 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

27

36 КАЗАН ГУБЕРНАСЫ КЕРӘШЕННӘРЕ ЫШАНУЛАРЫНДА МӘҖҮСИЛЕК КҮРЕНЕШЛӘРЕ. *Семён Максимов*



98 МИН БЕЛГӘН ТУКАЙ. *Рүзәл Мөхәммәтша*

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Сибгат Хәким

ТАРИХИ МИРАС

4 Болгар. Көнчыгыш пулат.
6 Чыңгызхан хәйләсе. *Ә.Мөхәммәдиев*
12 Түбән Новгород татарлары. *О.Сенюткина*
18 Керәшеннәрнең ислам дине изгеләренә гыйбадәте. *Р.Исхаков*
24 Керәшен авыллары тарихын өйрәнү тәҗрибәсе. *Л.Константинова*
27 Питрау мизгелләре
28 Керәшен Сәрдәсе: авыл тарихы, халык язмышы, әүвәлге документлар (1490-1900). *Н.Петров-Текин*
36 Казан губернасы керәшеннәре ышануларында мәҗүсилек күренешләре. *С.Максимов*

ТАТАР ГАМЕ

45 Тирән тарихлы Азнакай. *А.Борһанов*
50 Җөри Даругасы. *Р.Сәгъди*
58 Илдән килгән кунакны кабул иттең, Кулаткы!

«БЕЗНЕҢ МИРАС» — 25

60 Ак юл сиңа, «Мирас»ыбыз!

ПЕДАГОГИК МИРАС

62 Гаилә дәресләре. *Ф.Сөләймания*

ӘДӘБИ МИРАС

66 Кутадгу билик (Котайткыч белем). *Й.Баласагуни*
70 «Күп мәсьәләдә фикерләребез уртак» *(Туфан Миңнуллинның Гәрәй Рәхимгә хатлары)*
76 Махатма Еники һәм Батыев. *Н.Фәттах*

ТАТАР ҖЫРЫ

80 Мәшһүр җырчы, миһербанлы зат... *Р.Курамшин*
84 Үз ягының баласы. *Т.Миңнуллин*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча
мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

86 **Сибгат Хәким**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 **Әткәй каеннарының хәтерләре.** *Ә.Шамова*
94 **Гали абый.** *З.Зәйнуллин*
96 **Солдат** (Актаныш — музеена истәлекле әйберләр). *И.Хәйруллина*
98 **Мин белгән Тукай.** *Р.Мөхәммәтша*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
105 **Әнием теле — күңелем гөле!** *Й.Гәрәй*
108 **Исемнәр, кушаматлар...** *Г.Хаҗиева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

112 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның июль ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

114 **Көлке куа килә...**

118 **Мирасворд**
119 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июль*
120 **Резюме**

Заказ №.М-1565 Тираж – 2000 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 27.06.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм
коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тышлыкның 1 нче битендә – «Питрауга бару». *(Фрагмент)*
Киндер, майлы буяу. 2014 ел. *И.Максимов рәсеме*

СИБГАТ ХӘКИМ
(1911-1986)



***

Тормышта шундый аерым күренешләр була, бары күренеш кенә, сызык кына, ләкин язмышыңны алдан билгеләп куйган ниндидер хәвефле сызык. Гомереңнең башыннан ахырына чаклы ярылып яткан, күккә яшеннәр белән язылган сызык.

***

Талант һәрвакыт яңача ачыла, заманны үзенчә күрә. Поэзиянең байлыгы – төрле талантта.

***

Кайта-кайта уйланырга мәҗбүр иткән иҗат, биографияләр, шәхесләр була. Шуларга килеп терәлгәч, гасырлар буе кабатланган поэзия, шагыйрь дигән иске төшенчәләрне нигәдер кабаттан ачыкларга керешәсең. Әйтерсең поэзия яңадан башлана.

***

Без күп вакыт шигырьнең үзе турында сүз йөртәбез. Ә шигырьне тудырган кеше, шәхес үзе? Шагыйрь – барыннан да бигрәк халык, заман үзе дөньяга китергән, дөньяга сирәк китергән зур шәхес.

***

Кешеләрне күбрәк яраткан саен, кимчелекләре өчен ныграк әрнисең, тормышны күбрәк яраткан саен, ныграк көрәшәсең, матурлыгын тулырак расларга тырышасың.

***

Ватан сугышы темасы... Әйтерсең мин үзем эзләп тапкан аны. Ватан сугышы үзе тартып кертте мине. Ил язмышы, халык язмышы. Башта – язмыш. Темалар соңыннан туалар... Зур вакыйгалар күңелдә озаграк саклана. Кешеләрне мин сугышка кадәр дә азмы-күпме белә идем. Шулай да халыкны чын-чынлап сугышта таныдым. Читтән күзәтеп түгел, үзе белән бергә булып, арасында булып, авыр вакытта, иң кыен вакытта. Халыкның җаны, характеры бөтен матурлыгы, бөтен байлыгы белән киң итеп ачылган чакта.

***

Гомерең буе эзләнәсең, язасың, тәҗрибә туплыйсың, ләкин барыбер һәр шигырьдән соң яңадан шушы сорау алдыңа килеп баса: «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?» Әдәбиятның нигезе бер – тормыш, халык тормышы. Ләкин һәр шәхес үз сүзен үз иҗат газаплары аша әйтергә өйрәнә.

Текстны ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Болгар. Көнчыгыш пулат

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Көнчыгыш пулатны кайвакыт Хан мунчасы дип тә йөртәләр. Ул шәһәр мунчасының хәрабәләреннән гыйбарәт. XIII гасырда төзелгән әлеге кирпеч-таш бина – җәмәгать мунчасы – XVIII гасыр чыганакларыннан мәгълүм. Бүлмәләренең эчке төзелеше, инженерлык җайланмалары, булганлыкның эзләре (идән астыннан җылыту, төтен чыгу юллары, су, канализация системалары) күренеп тора. Тулаем алганда, ул Кызыл пулат, аеруча Ак пулат конструкциясен хәтерләтә. Бу шәһри Болгарның иң зур, иң борынгы җәмәгать мунчасының калдыклары булып санала.

Биредә археологлар 1983-1993 елларда казу эшләре алып бара. Бүлмәләрне чистартканда табылган нумизматика әйберләренең анализы бинаның төзелеш һәм кулланыш вакытын ачыкларга мөмкинлек биргән. Мунчаның XIII йөзнең 90 нчы еллары башында ук актив кулланылуы һәм XIV йөзнең 30-40 нчы елларына кадәр эшләве ачыкланган. Биредә консервация-реставрация эшләре 1990 еллар ахырында һәм 2011-2012 елларда үткәрелде. Диварлары, киселгән таш тезеп, элек консервацияләнгән өлешкә тәңгәл рәвешкә китерелде, юкка чыккан почмак болаклары, бинаның гөмбәзе астындагы өлештә плинфадан һәм таштан түшәлгән идәннәр торгызылды, җылыту каналлары һәм җылылык йөрү юллары реконструкцияләнде. ■

Чыңгызхан хәйләсе

Әзһәр Мөхәммәдиев

Әмир Буян, Җик остазның сәяхәтнамәсен укыган кеше буларак, ихтирам йөзеннән аңа сүз бирде:

– Рәхим ит, Җик остаз.

– Сәүдәгәр Мөхәммәткә минем ике генә соравым бар. Беренчесе: мангул-татарлар төрки телдә сөйләшәләрме, әллә башка бер телдәме? Икенче соравым яки үтенечем: мангулларның ничек итеп Хәрәземне басып алуларын тәфсилләбрәк сөйли алмассызмы? Беренче соравымның мәгънәсе шунда, – диде ул әмиргә карап, – җәмәгатьчелек Чыңгызханны гадәти бер хөкемдар дип кенә саный...

– Минем аңлавымча, без – уйгырлар да төрки, чөнки мангул теленең төрки белән нинди дә булса уртаклыгы юк. Чыңгыз – мангул ханы һәм аның бөтен җегәре мангулның абруен күтәрүгә юнәлтелгән. Икенче сорауга килгәндә исә, биредә Чыңгызханның ничек итеп Хәрәземне яулап алуын ишетмәгән кеше юктыр, дип уйлыйм.

– Ә шулай да? – дип сорады Җикнең сүзне нинди юнәлешкә җибәрергә теләгәнлеген аңлап алган әмир.

– Әфәндем, сугыш – сугыш инде ул. Хан Хәрәземгә алдан ук шымчылар җибәрткән. Алар юлларны, кичүләрне, шәһәрләрне өйрәнеп, хәл-әхвәлне белеп торырга тиеш булганнар. Баш иеп, биләмәләрен саклап калырга теләгән морзалар белән багланышка кергәннәр...

– Азгын[1] морзалар үзләренең биләмәләрен саклап кала алганнармы соң, – дип кызыксынды әмир.

– Ул кадәресен әйтә алмыйм, әмир галиҗәнапләре.

Янә бер-ике сорау биреп караса да, сәүдәгәрдән нинди дә булса кызыксынырдай сүз тартып алырга өметен югалткан әмир аңа китәргә рөхсәт итте. Куелган сорауның җавабын ул Баян остазның сәяхәтнамәсеннән укып белә иде инде. Шулай да, аны диван әһелләренә дә ишеттерәсе килеп, ул:

– Бирелгән сорауга үзеңә җавап бирергә туры килер, Җик остаз. Алтын тауларын өмет итеп, үз илләрен саткан азгын морзалар биләмәләрен саклап кала алганнармы соң? – дип сорады.

– Юк! Саклый алмаганнар, әмир галиҗәнапләре. Чыңгызхан аларны үз янына чакырткан, тегеләре исә бик сөенешеп, юмалау өчен алтын-көмешләрен күтәреп, аның урдасына җыйналганнар. Чыңгызхан исә аларны кымыз белән сыйлаган, аннары исә соңгы сүзен әйткән: «Үз хуҗасын саткан кол камышлыкка атылган ук кебек ышанычсыз ул», – дигән һәм барысын да кылычларга, ә алтын-көмешләрен казнага алырга боерган...

Башы журналның 2 нче санында.

[1] Азгын – баш күтәрүче, сатлык.

Шунысын да әйтергә кирәк, төрле халыклардан торган илләрне Чыңгыз үзара ызгыштырырга, мөмкин булса, мангул канын түкми генә басып алырга ярата. Кайберләренә талатмаска, үтертмәскә сүз бирсә дә, илен басып алгач, сүзендә тормый, шәһәр халкын кырдырып бетерә, авылларын, шәһәрләрен җимертә, ә аларның урыннарын көтүлекләргә әйләндертә...

– Болгар илендә дә шундый ук таркаулык, – дип канәгатьсез тавыш белән сөйләп китте әмир, – алпавытлар, морзалар, бәкләр сугышка әзерләнергә ашыкмыйлар. Үз биләмәләрен дошманга баш иеп, буйсынып саклап калып булыр, дип уйлыйлар. Саксиннар[2] белән татулык юк, Бәпәнәй урдасы белән дә шулай ук дуслык юк диярлек. Мукшылар, чирмешләр дә сак торалар. Суарларның исә бар теләкләре – Болгар йорты белән бер-бер хәл булса, дошманга юл күрсәтеп, күпер салып, үз җирләрен иминлектә саклап калу. Ә бит бу халыклар барысы да диярлек Болгар иле канаты астына үз теләге белән кереп, анда көн күрә[3]... Менә шул Чыңгыз каган файдалана торган куркыныч алымнарның барысы да Болгар илендә ярылып ята. Ничек итеп явыз һәм вәхши дошманга каршы тору кирәклеген үзегез уйлап карагыз...

– Бәлки Аладимер-Суздәл кенәзе Юркәйне, солых төзеп, ярдәмгә чакырырга кирәктер? – диде, моңарчы тын гына тыңлап утырган вәзир Баттал.

– Аладимер кенәзләренең үзләрендә дә бердәмлек юк. Бертуктаусыз үзара ызгышып торалар, – дип җавап бирде әмир һәм сүзен дәвам итте. – Бу мәсьәләне диван саен кузгатабыз, җәмәгать, әмма дә тәгаен генә хәл итә алганыбыз юк! Биредә бүген шул дошманнарны үз күзләре белән күргән яңа кеше бар. – Ул игътибар белән остаз Җикнең борчулы йөзенә карап алды. – Бәлки, Баян әфәнде, Чыңгызханга ничек итеп каршы торырга һәм аны ничек җиңәргә икәнлеген син аңлатып бирерсең? Синең юлъязмаңда бу мәсьәләгә шактый ачыклык кертелгән кебек тоелды миңа...

– Барысы да Аллаһы Тәгалә кулында, – диде Гали сәет сүзгә кысылып...

Җик исә, әмиргә карап: «Чынлап әйтүеме соң моның, әллә көлүе генәме?» – дип уйлап алды. Ни генә булмасын, ул үзе көрәшкә әзер иде. Бохарада фәлсәфи сүз көрәштергәндә бер суфый аңа: «Сүзеңне сүз итим дисәң, сүз башлау белән үк дошманыңның башына чукмар белән берне тондыр!» – дип үзенең алымын өйрәткән иде. Шул алымны истә тотып, ул башта ук һөҗүмгә күчте:

– Мөхтәрәм Гали сәет, миңа Мисырда булырга туры килгән иде. Гарәпләр – пәйгамбәребез Мөхәммәтне һәм аның аша Коръән-Кәримне иңдергән халык. Аларда мондый очракларда әйтелә торган бер әйтем бар: «Аллаһы Тәгаләгә ышан – ул бөек һәм бер генә, әмма дөяңне югалтасың килмәсә, аны бәйләп куй!» Шуңа күрә безгә дә үз дәүләтебезне югалтасыбыз килмәсә, аның өчен кайгыру һәм көрәшү тиеш! Чөнки каһәр суккан дошман Болгар йортының бусагасы төбенә килеп җиткән инде, ә без гәпләшүдән гайре эш кылырга җыенмыйбыз кебек, кардәшләр. Иртәгәгә калдырсак – соң булмасын!

Барысы да, кызыксынуларын яшермичә, тыңлый башлады. Җик җиләненең киң кесәсеннән алдан ук әзерләп куелган зур гына харита тартып чыгарды һәм аны ди-

[2] Саксин – Идел буйлап Әстерханнан 25 чакрым түбәндәрәк урнашкан зур гына утрауда IX йөздә барлыкка килеп, XIV йөзгә кадәр яшәгән хазар (мишәр) шәһәре.

[3] XIX йөздә КДУның Смирнов И.И. дигән профессоры лингвистик һәм археологик материалларга таянып, мари һәм кайбер башка кабиләләрнең көнбатышта формалашып, викинглар һөҗүме нәтиҗәсендә болгарларга таба чигенүләре турында язган иде. Мукшы, чуаш, чирмеш халыклары исемнәрендә, чынлап та борынгы төрки «тауар-ише» дигән сүздәге кебек «иш» кушымчасы тоемлана.

варга эленгән келәмгә энә белән кадап куйды. Хаританың шактый өлеше кара тушь белән буялган иде.

– Күрәсез, Чыңгыз хан гаскәрләре җир шарының күпме өлешен басып алган. Үргәнечне яндырып, харап итеп, Болгар биләмәләре булган Җаек буйларына ук килеп җиткән инде алар.

– Хәрәзем шаһының җирләре бөтенләе белән баскыннар кул астында калган, – диде картага игътибар белән карап утырган вәзир Баттал.

– Шаһ Мөхәммәтнең фаҗигасе шунда ки, – дип сүзен дәвам итте Баян, – ул куркынычның никадәр зур булуын абайлый һәм сизми калды. Чыңгыз гадәти күчмә кырагайлар җитәкчесе генә түгел – ул, бөтен илләрне, шәһәрләрне дә, халкына тимим, дип басып ала да, аннары сабыйларын да калдырмыйча, барысын да суеп чыга. Җитмәсә, ул моңарчы дөньяда күрелмәгән мәкерле бер ерткыч кына түгел, шуның өстенә, даһи оештыручы, дәүләт һәм гаскәр башлыгы да...

– Хуп, нинди көрәш чаралары күзаллыйсың инде мондый мәкерле дошманга каршы, Җик әфәнде? – дип сорады Гали сәет. – Минемчә, Аллаһы Тәгаләгә ныграк инанырга һәм догалар укырга кирәк. – Аннан соң, – дип өстәде ул, – чынлап та, дога китабы укыйсы урынга мондый харитага, тәрегә табынгандай, күз текәп утыру Илаһы каршында дөрес булырмы?

– Гали сәет, башлап әйткән сүземне кабатлап әйтим: һәрнәрсәнең вакыты һәм урыны бар. Кемдер дога укыса, кемдер кулга сөңге-кылыч алып, илне дә сакларга тиештер бит! Мондый хариталар – ислам мәдәниятының бер җимеше генә. Гарәп галимнәре кораблар белән диңгездә юл табар өчен җайланма – компас уйлап тапканнар, ә җирнең шар рәвешле булуын, аның иңен, буен, авырлыгын да һәм кояш тирәли әйләнеп торуын да алар борынгы греклар «астралябиун» дип атаган корал белән үлчәп һәм санап чыгарганнар...

– Мондый гаҗәеп нәрсәләр турында без дә хәбәрдар, ә менә Чыңгызханны мөселман дөньясына, Туранга гына түгел, ә безнең илебезгә дә бәреп керсә, ничек итеп аны ыштансыз калдырырга булыр соң?!

– Минем фикеремчә, әмир галиҗанәпләре, Болгар дәүләтен хәзер бары бер генә нәрсә коткарып калырга мөмкин: ул да булса, зур-зур дәүләтләрне җимереп масайган Чыңгызның аны игътибарга алмавы һәм зур көчкә санамавы.

– Узып кына китәр дисеңме?

– Әйе. Ул, мөгаен, чирүен Болгар биләмәләренә түгел, ә менә моннан, Хәзәр диңгезенең түбән очыннан, Фарсы дәүләте аша Рум[4] җирләренә җибәрер. Әгәр дә ул шулай эшләсә, әфәнделәр, язмыш безнең Болгар йортына беркадәр вакыт бирә. Сугыш кануннары һәм яса[5] кертергә, азгын морзаларның юлларын кисәргә, мукшы, чирмеш, суар, ар һәм башка халыклардан атлы гаскәр тупларга тәкъдим генә түгел, ә боерык бирергә кирәк булыр. Уйларга вакыт калмаган. Шулай әзерләнә алган очракта гына, Бөек Болгарны, берләшкән көчле бер дәүләткә әверелдереп, үз көчен күрсәтә алырлык итәргә мөмкин булачак...

– Дөресен генә әйткәндә, Җик остаз, фикерең минем фикерем белән дә тәңгәл килә, – диде аны игътибар белән тыңлап торган әмир, – тик моны нинди рәвештә тормышка ашырырга? Ничек итеп тормышка ашырырга??? Нинди алымнар кул-

---

[4] Рум –Төркия җирләре.
[5] Яса – акчалата һәм натураль бурычлар.

Р.Заһидуллин рәсеме

ланырга күзаллыйсың, нинди киңәш бирер идең син ерткыч дошман гаскәрләрен үз күзләрең белән күргән кеше буларак?

– Шәригатьне бозып, дәүләтебездә борынгы мәҗүси ясасын кертү ислам кануннарына туры килми! – диде Гали сәет, караңгы чырай белән.

Аңа кушылып, кайбер башка түрәләр дә авыз эченнән генә мыгырданып, хупламауларын белдерде.

– Ислам кабул иткән борынгы бабаларыбыз юлыннан тайпылу булыр иде бу, – диештеләр алар.

– Тагын шул сүз көрәштерү! – диде әмир канәгатьсезлек белән. – Сине тыңлыйбыз, Җик әфәнде.

– Шәригать кануннарына беркем дә тел тидерми, әфәнделәр. Алар үз урынында кала. Шәригать буенча иң югары җәза чарасы булып, уйнашчылык иткән өчен ирсәк хатыннарны таш орып үтерү тора. Үзегез беләсез, анысы да әле берничә шаһит үз күзе белән күргән очракта гына. Ә азгын һәм сатлык болгарлар яки дошман шымчылары белән нинди чара кылырга? Минемчә, бу кануннар бер-берсенә каршы килми. Кануннар дошманга сатылган, үз иленә турыдан-туры хыянәт иткән морзаларның муенын чабарга, хәрбиләр арасында, гаскәрдә тәртип һәм тарбус сакларга ярдәм итәчәк...

Хаҗи тархан, кылычтан саклангандай, калын муенын сыйпап куйды. Диван әһелләре гүләшеп үзара сөйләшә башлады. Әмир кулын күтәрде һәм тынычлык таләп итеп, сүз алды:

– Җик әфәнде, – диде ул җитди тавыш белән, – мин синең сәяхәтнамәңне укып чыгып, үз фикеремне әйткән идем инде. Күрәм ки, бу мактау урынсыз түгел.

Җәмәгать белән киңәшеп, без сиңа вәзирлек вазифасын тапшырырга булдык. Сүз, әлбәттә, вәзир Батталдан үзгә буларак, хәрби оештыручы-вәзир турында бара.

Гали сәет һәм Хаҗи тархан, гаҗәпләнешеп, бер-берсенә карашып алдылар. «Киңәш» дигәне диван әһелләре белән түгел, үзара гына булган, күрәсең...

– Мондый зур һәм җаваплы эш каурый каләмне корыч кылычка алыштыру, дигән сүз. Гомерең озын булсын, әмир, ни кызганыч, мин мондый олуг эшкә әзер түгел...

– Җик әфәнде! – дип сүз башлады әмир. Аның тавышы кырысланды. – Мин бу тәхеттә беренче ел гына утырмыйм. Илебез коточкыч куркыныч астында. Сүз борынгы бабаларыбыздан булган патшалар нәселе, Сөлек нәселен генә түгел, ә Бөек Болгар дәүләтенең яшәешен саклап калу турында, мондый авыр заманда илеңне кыен хәлгә калдырмау турында бара!

Җик, башта ук, болай диван утырышына чакырылуының берәр сәбәбе бардыр, дип уйлаган иде, әмма дә бу кадәр үк югары урын тәкъдим итәрләр, дип башына да китермәде.

– Яхшы, – диде ул беркадәр икеләнеп торганнан соң, төп фикергә килеп. – Тик бер шартым бар.

– Хуп.

– Заманалар чынлап та артык болгавыр. Вәзир булдым, дип башка кибән хәтле чалма урап йөрү генә түгел, миңа сәяси эшләр һәм тиз арада кораллы көчләр җыеп туплау, оештыру вазифасы да тапшырыла торгандыр, дип уйлыйм?

– Дөрес уйлыйсың, вәзир, әйт шартларыңны!

– Вәзир генә түгел, тамгачы да булырга тиеш мин! Кайбер ашыгыч хәл итәргә кирәк булган эшләрне мөһер сугып җиренә җиткерү өчен һәрдаим шәһри Болгарга атчабар юлласак, эшләнеп бетмәгән эшләребез еллар буена сузылачак. Ә безнең вакытыбыз юк!

Диван әһелләре, тын да алмыйча, шаккатып калды. Ләкин беркем дә сүз әйтергә җөрьәт итмәде. Әмир тамгасы әмирнең үзенә биргән кебек үк ирек бирә: теләсәң – ас, теләсәң – кис!

– Бу дөньяны тетрәткән куркыныч заманда тамгага карап кына, аны оядагы каз йомыркасы кебек саклап утырып булмас бит. Риза. Яхшы, – диде әмир. – Шартың кабул!

Җик остаз уң кулын әмиргә таба сузды һәм әмирнең аптырабрак карап торганын күреп:

– Тамга! – диде

– Китер мөһерне, вәзир, – диде әмир, Батталга карап.

– Чабатасын түргә эләчәк бу! – диде әкрен генә Гали сәет, ләкин кеше ишетерлек итеп.

– Элеп кенә куйса, яхшы булыр. Безгә элдермәсен! – диде күршесе шулай ук акрын гына.

Җик мөһерне Баттал кулыннан алып, аны югарыга күтәрде.

– Әфәнделәр, Болгар дәүләтенең иминлегенә моңа кадәр күрелмәгән куркыныч янаганлыгын барчагыз да белә, шушы мизгелдән башлап яса кертелгән, дип кабул итегез!

Әмиргә таба борылып, ул ихтирам белән башын иде һәм сүзен болай дип дәвам итте:

– Әмир галиҗанәпләре! Илтабар Сөлек – синең ерак бабаң, ул вакытта хәлиф булган Мөтәдидкә мөрәҗәгать итеп, бөек әмир атын (*титулын* – Ред.) кабул итеп, Бөек Болгарның данын бөтен дөньяга таратты, күтәрде. Мангуллар үзләренең хуралында Чыңгызханга каган, ягъни ханнар ханы дәрәҗәсе бирделәр. Шушы олуг

диван утырышыннан файдаланып, сиңа да Чыңгызныкыннан да ким булмаган олуг исем, солтан дәрәҗәсе бирүне тәкъдим итәм! – дип бетерде ул сүзен.

Бар да тәэсирләнеп һәм гаҗәпләнеп, нәрсә булачагын көтеп, тынып калдылар.

– Байчура бегич, Бортас инәл, Айпулат бий, – дип эндәште җилнең кайсы яктан искәнлеген сизенеп алган, күп еллар вәзирлектә хезмәт иткән гаять зур тәҗрибәле Баттал вәзир, алпавытларга һәм морзаларга карап, – бире килегез! Кулларыгызга менә бу тәхет алдына җәелгән келәмне алыгыз. Аннары, әмир галиҗәнапләрен келәмгә утыртып, күтәреп, тәхет тирәли җиде тапкыр әйләндерербез. Солтан дәрәҗәсе бирү җоласын башкарыйк!

Мондый йоланы ишетеп кенә белгән башка алпавытлар да, ярдәмләшеп, идәнгә җәелгән келәм өстенә әмирне күтәреп утырттылар.

– Ә син, Гали сәет, солтан Буян хөрмәтенә хөтбә укы!

Гали сәет, хәлне аңлап алганнан соң, каршы килергә базмыйча, кычкырып хөтбә укый башлады:

– Илаһем, әлмөлек, әссолтан Илһам бине әмир Сәлим, болгар мәлиген ярлыка...[6]

Алпавытлар, Гали сәет хөтбә укыган арада, келәмдә утырган әмирне тәхет тирәли җиде тапкыр әйләндергәннән соң, тәхеткә утырттылар. Җик вәзир, аның каршында бер тезенә чүгеп, диван әһелләренә борылып карады. Бар да тезләрен чүгеп йөгенде.

– Хөрмәтле әмир галиҗанәбләре! – диде Баян. – Шушы мизгелдән башлап, бар җиһанга без сине Бөек Болгар дәүләтенең алтын тәхетле солтаны, дип игълан итәбез!

– Тыңлыйм һәм буйсынам, вәзир Җик! – диде яңа гына солтан булып алган Илһам, вәзиренең кыюлыгыннан һәм тапкырлыгыннан канәгать булып:

– Әмир – ул бөтен мөселманнарның падишаһы булган хәлиф исеме, – диде ул. – Хәзер мөселман илләренең падишаһлары күптән үзләренә «солтан» исеме алып бетерделәр... Ә кыргый далалардан чыккан илбасар Чыңгыз үзенә борынгы төрки атамасы «каган» исеме алган бервакытта нигә безгә дә «солтан» исемен алмаска, әгәр ул безнең азатлыгыбызны саклап калырга да ярдәм итә торган булса! – дип өстәде солтан.

Шулвакыт тәхет залына 13-14 яшьләр тирәсендәге, калфагының кашына зур матур кәпрәбар[7] тагылган гүзәл бер кызыкай килеп керде. Бу – солтанның төпчеге Чәчәк иде. Аны күрү белән патшаның йөзе яктырып китте, ул әйтергә теләгән сүзен бүлеп, кызына карады. Кыз исә морзалар һәм алпавытлар яныннан үткәндә бик күркәм итеп башын иеп исәнләште дә, әтисе янына килеп җиткәч, аның янына тәхеткә менеп үк утырды. Сөйкемле йөзе белән әтисенә күтәрелеп карады һәм назлы тавыш белән:

– Әткәм, ә кем иртәнге ашны ашар? – дип сорады.

Илһам солтан, кызын алдыннан төшерде дә, диван әһелләренә карап елмайды һәм:

– Хөрмәтле вәзир, сәетләр, морзалар, тарханнар һәм алпаутлар! Ә кем яңа гына дөньяга пәйда булган солтан туена бармый калыр икән?! – дип сорады.

Дәвамы бар ■

---

[6] Илаһем, мәлик Сәлим улы солтан Илһамны, Болгар мәлиген ярлыка... Илһам – Буянның мөселман исеме.
[7] Кәпрәбар – янтарь.

Түбән Новгород татарлары

Ольга Сенюткина

Түбән Новгород татарлары, ягъни татар халкының аерылгысыз бер өлеше булган мишәрләрнең барлыкка килүе махсус өйрәнүне көтә. Мишәрләр, татарларның мөстәкыйль субэтник төркеме буларак, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең көньягында, көньяк-көнчыгышында, Мордовиядә, Рязань өлкәсенең көнчыгышында, шулай ук Пенза һәм Ульян өлкәләренең төньягында формалаша[1].

Мишәр халкының борынгыдан табигый яшәү урыны – дала һәм урман-дала. Түбән Новгород өлкәсенең көньяк һәм көньяк-көнчыгыш җирләре – төркиләргә яшәү өчен иң кулай булган табигый тирәлек. Озак вакытлар бернинди кырыс сәяси күзәтчелек булмау сәбәпле, кеше саны да аз булган бу җирләрдә күчмә төркиләр иркенләп үтеп керә, мал-туар асрый алган. Аз сандагы төрки халыклар яшәгән бу җирләргә заманында, мөгаен, хәзәрләрнең һәм Идел буе болгарларының да йогынтысы булгандыр. Күчмә кыпчаклар да Түбән Новгород өлкәсенең көньяк мәйданнарына кадәр килеп җиткән һәм хәзер татарлар күпләп урнашкан җирләрдә яшәгән булса кирәк. Бортасларның да җирләре күршедә генә булган. Мишәрләрнең борынгы бабалары төрки булмаган халыклар, фин-угор һәм славян кабиләләре белән дә тыгыз элемтә урнаштырган. Күршедәге Идел буе Болгарстаны һәм Русь дәүләте, алар арасындагы тыгыз сәяси-икътисади бәйләнешләр да ике арада яшәүче халыкларга йогынты ясамый калмагандыр.

Мишәр татарлары субэтносы формалашуга болгар, бортас, кыпчак ыруг-кабиләләре вәкилләреннән кала, мажарлар да тәэсир иткән. Түбән Новгород татарларының үзатамаларын санап китик: «татар», «мишәр», «алатор», «мөселман». Хәзерге заманда исә алар үзләрен кайчакта «нижгарлар» дип кенә атый.

Мишәр татарлары барлыкка килүнең беренче чоры дип XIII гасырга чаклы, ягъни Бату хан җайдаклары Көнчыгыш Европа яссылыгына аяк басканчыга кадәрге дәверне атарга мөмкин. Түбән Новгород җирләрендә яшәүче төркиләр белән бергә фин-угор һәм славян кабиләләре дә монгол яуларына каршы аяусыз көрәшкән.

Урдалыларның мәшһүр ханы Үзбәк сигез ел дәвамында Җучи Олысының бер биләмәсе булган Мухшы каласында (хәзерге Мордовиядәге Наровчат шәһәре) яшәгән. Мухшы районы тирәсендәге Мишәр йортының

[1] Зариф Бәширинең 1912 елда язылган «Мишәрләр» исемле әсәрен журналыбызның сайтыннан укырга мөмкин http://beznenmiras.ru/misherler/



Ярминкә күпере яныннан бер күренеш. В.Рыбинский рәсеме. 1857 ел

бу җирләре тарихка Алтын Урданың Наровчат өязе буларак кереп калган. Мишәр йорты җучи баскаклары һәм Русьтан салым җыючыларының тупланган урыны, плацдармы булган. Безгә тыл биләмәле өч урда баскакының исеме билгеле: Тёша һәм Пьяна, Итәк елгалары арасындагы җирләргә ия булган Алач; Мишәр йортының Итәк шәһәрлеге хуҗасы Итәк һәмҮзбәк хан тарафыннан ясак җыяр өчен куелган Сарык (Чарык). Галимнәр Сараклыч шәһәрлегенең башлангыч тарихын Сарык исеме белән бәйлиләр.

Кайбер урда аксөякләренең язмышы Түбән Новгород тарихы белән тыгыз бәйләнгән. 1360 елларда, Алтын Урдада кризис шактый көчәеп киткән дәвердә, Сигез бәй Азов диңгезе ярыннан Пьяна буена күченә һәм үзенә җирле халыкны буйсындырып крепость төзи. Түбән Новгород өлкәсе Сеченов районында Мурзицы авылының тарихы 1361 елда төзелгән шушы шәһәрлеккә барып тоташа. Ул чыганакларда «Грозная крепость» дип теркәлгән. 2008 елда биредә Татарстан һәм Түбән Новгород археологларының берләштерелгән экспедициясе казу эшләре башкарды. Бу тикшеренүләр мондагы халыкның этник составы байлыгын – төркиләр, угро-фин һәм славян кабиләләренең бергә яшәгәнлеген дәлилләде.

1446 елда Алтын Урданың ханы Олуг Мөхәммәтнең улы Касыйм хан Мәскәү кенәзе Василий II тарафына күчә. Василийга ярдәме өчен Касыйм 1450 елларда «Городец Мещерский» (Касыйм, Ханкирмән) һәм аның әйләнә-тирәсендәге җирләр белән бүләкләнә, Касыйм ханлыгы барлыкка килә. Шул дәвердән, Алтын Урда таркалган вакытта, тарихка йомышлы татарлар буларак кереп калган төрки-татарларның күбесе көчәеп килүче Мәскәү кенәзлегенә хезмәт итә башлый.

XVI гасырга мишәр татарларының этник бергәлеге бортас-мажар-кыпчаклар һәм соңрак күченеп килгән Алтын Урда кабиләләреннән хасил була. Арзамас һәм Алатырь төбәгендә татарлар иркен көн күргән, алар бу

җирләрнең беркемнеке дә булмаудан ирекле файдаланган, ягъни әле бу вакытта Мәскәү тарафыннан күзәтчелек булмый. XVI гасыр урталарында Сабачай (Сафаҗай) (Пильна районы), шул гасырның икенче яртысыннан Рыбушкино (Рбишча) авылының тарихы башлана. Соңрак исә Петриякс авылына нигез салына.

Шулай итеп, XVI гасыр азагында биредә йомышлы татарларның авыллары барлыкка килә. Алар Түбән Новгород җирләрендә әүвәлге кебек шәхси яки аерым төркемнәрнең мәнфәгате белән түгел, ә үз чикләрен сакларга омтылган Мәскәү дәүләте кушуы буенча яши башлый. Ә бу чорда Мәскәү дәүләте чигенең бер өлеше Түбән Новгород җирләренең көньягыннан узган.

Түбән Новгород татарлары тарихы авыллардан башлана. Озак еллар дәвамында аларның 1221 елда нигез салынган Түбән Новгород шәһәре белән нык бәйләнеше булмый диярлек.

1560 елда Арзамас, соңрак Алатырь һәм Курмыш өязләре оештырыла. Ичалов һәм Иржин станнарында Явыз Иванга хезмәт итә торган йомышлы кешеләр барлыкка килә. Алар, кагыйдә буларак, Мишәр йортындагы аксөякләрнең нәселеннән булып, тора-бара Алтын Урдадагы кризис вакытында Мәскәү кенәзләренә хезмәткә күчә. Иван IV Арзамас морзаларына ата-бабаларының әүвәлге җирләрен юридик яктан беркетә, алар исә моның өчен дәүләт чикләрендә каравыл хезмәтен башкарырга тиеш була. Йомышлы татарларның авыллары хәзерге Сатис авылыннан алып, Арзамаска кадәр, дәүләтнең дошманнардан саклану чиге буларак, тезелеп киткән. 1570 еллардан Арзамас янында Томаев, Шехаев, Салтаганов, Бигатов, Акчурин һәм башка унлап йомышлы татар авылы барлыкка килә.

Аннары йомышлы татарлар көнбатыштан көнчыгышка күчерелә башлый. 1570-1590 елларда даладан күчмәннәр һөҗүме сәбәпле, хакимият беренче чиратта Арзамас өязенең көнчыгыш чикләрен ныгыткан. Чик буе заставасы төньяк-көнчыгышка таба сузылган. 20 ел эчендә, ягъни 1586-1606 елларда Арзамастан төньяк-көнчыгыш юнәлештә йомышлы татарлардан торган уннан артык авыл барлыкка килә: Яңа Усад, Усад Кутлеяр, Бараш Усад, Чекеев, Лукьян, Ботюк, Алтыш, Камка, Пица, Кучкай-Пожары һәм башкалар. Бу авыллардан бүген бары тик Пица, Камкинов һәм Кучкай-Пожар исемлеләре генә сакланып калган. Йомышлы татарларның бер өлеше тагын да көнчыгышкарак күчерелә, ә бер өлеше XVII гасырның 20-80 елларында чукындырыла. Түбән Новгород җирләрендә йомышлы татарлар авыллары барлыкка килү дәвере XVI гасырның соңгы чирегеннән XVII йөзнең азагына кадәрге вакытны, ягъни тулы бер гасырны иңли. Бүгенге Түбән Новгород татарлары – Мәскәү дәүләтенә тугры хезмәт иткән йомышлы каһарманнарның оныклары.

Түбән Новгород татарларының Россия тарихындагы иң авыр дәвер – Болгавыр замандагы мөһим роле турында да искәртергә кирәк. Йомышлыларның төп казанышы шуннан гыйбарәт: алар Россиянең чик буендагы куркынычсызлыгын тәэмин итәләр. К.Минин һәм Д.Пожарский җитәкчелегендәге халык ополчениесе Мәскәүдән поляк баскыннарын куып чыгара, Түбән Новгород татарлары Алатырь җирләрендә нугай яугирләренә дә каршы көрәшә. Дала яугирләре Арзамасны алырга һәм Россиянең үзәк территориясенә таба хәрәкәтләнергә тели, әмма морза Баюш Разгилдиев җитәкчелегендәге Алатырь һәм Арзамас йомышлы татар-

Ярминкә мәчете су басу вакытында

лары баскыннарның һөҗүмен туктата. Шуның өчен алар 1618 елда дәүләт тарафыннан грамота белән бүләкләнә.

XVII гасырның беренче яртысында Алатырь төбәгендә борынгы Пары авылы халкы күчереп таратылу нәтиҗәсендә, йомышлы татарларның тугыз яңа авылы барлыкка килә: Уразова, Ендовище, Триазер, Кадомка, Кузьминка, Антяровка, Красный Яр, Ключищи, Актук. Курмыш җирләрендә дә йомышлы татар авыллары: Базлово, Ишеево, Парша, Андреевка, Татар Моклокасы, Анда, Вакай (хәзер Урга) барлыкка килә. Иң азактан гына, 1674 елда Татар Мәдәнәсе авылына нигез салына. Алда искә алынган авылларга йомышлы татарлар Кадом, Темников һәм башка өязләрдән күчерелгән. Бу җирләр аларга патшага тугры, намуслы хезмәт иткәннәре өчен бүләк итеп бирелгән.

Арзамас, Алатырь, Курмыш өязләрендә яшәүче йомышлы татарлар Россия дәүләте оештырган бихисап сугышларда катнашкан. Иң соңгы мәртәбә алар 1708 елда хәрби хезмәткә каралып, яуга озатыла. Бу вакытта Алатырь өязендәге 28 авылдан 555 кеше сугышка алына.

Петр I заманыннан Түбән Новгород татарларының статусы үзгәрә. Алар йомышлы татар-җирбиләүче, алпавытлардан дәүләт крестьянына – «чабаталы морзалар»га әверелә. Бу чорда татарлар Россия хәрби флоты төзелешендә зур эшләр башкара. Лашман, кораб төзү, урман кисү һәм салны верфьләргә агызу кебек авыр эшләрнең һәммәсе алар җилкәсенә төшә. Керәшен конторының көчле йогынтысына, XVIII гасырда көчләп чукындырырга омтылуларына да карамастан, Түбән Новгород татарларының

традицион исламны сакларга омтылышы – зур рухи батырлык. Алар бар көч-куәт белән христиан миссионерларына каршылык күрсәткән, мәчетләр төзегән. 1898 елда Түбән Новгород губернасында 63 мәчет теркәлгән (хәзер безнең өлкәгә, элегрәк Сембер губернасына кергән мәчетләрне исәпкә алмыйча). Мәчет янында мәктәп һәм мәдрәсә эшләгән. Күп кенә имам-хәлфәләр, мөдәррисләр Казан губернасы мәдрәсәләрендә белем эстәп, туган җирләрендә балалар тәрбияләгән. Белем бирү кадими булып, ара-тирә җәдитче хәлфәләр дә күренгәләгән, алар уку-укыту процессын яңартырга омтылган. Икенче чакырылыш Дәүләт Думасында Түбән Новгород депутатлары арасыннан берденбер татар – Габдулла Нәҗметдинов та булган. Ул имам гаиләсендә туган, үзе дә мулла вазифасын башкарган. Татар авылларында хәйрия җәмгыятьләре дә колач җәйгән, хәлле кешеләр фәкыйрь-мескеннәрнең язмышына битараф калмаган.

Түбән Новгород татарлары, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнү өстенә бик оста сәүдәгәр дә булган. Сәүдә үсешенә Мәкәрҗә ярминкәсе аеруча зур йогынты ясаган. Капитализм үсеше шартларында биредәге татарларның сәүдәсе бөтен Россия империясен, көнчыгыштан-көнбатышка сузылган киң мәйданны колачлый. Бүген Финляндиядә яшәүче татарларның нәсел-тамыры Түбән Новгород өлкәсендәге Актук, Рыбушкино кебек авылларга барып тоташуы һич кенә дә гаҗәп түгел. Заманында Актук халкы Финляндиянең Гельсингфорс, Тампере, Турку һәм башка шәһәр-бистәләренә сәүдә эшләре белән күпләп күченгән.

Түбән Новгород татарлары арасында төбәктә генә түгел, исеме чит җирләргә дә мәшһүр шәхесләр байтак. Садыйк Абдулҗәлилов (1835-1886) – Куй суы авылы мөдәррисе; Хәбибулла Әлмөхәммәтов (1840 еллар уртасы-1896) – ишан, имам-хатыйп, Сафаҗай авылы мәдрәсәсенә нигез салучы; Хәмидулла Алмышев (1855-1929) – мәгърифәтче, «Хаҗнамә» юлъязмасының авторы, Петриякс авылының имам-хатыйбы; Хөсәен Фәезханов (1823-1866) – галим-шәркыятьче, тел белгече, Санкт-Петербург университетында төрки һәм гарәп телләре укытучысы, Россия мөселманнары мәгарифен үзгәртеп кору турындагы проект авторы, аның энесе – Габделгалләм Фәезханов (1850-1920) – икътисадчы һәм мәгърифәтче.

Ука елгасының Иделгә койган урынында урнашкан Түбән Новгород ярминкә мәчете (1817-1926) бер гасыр дәвамында халыкка хезмәт итә. Бу мәчет гади гыйбадәтханә генә түгел, ә Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән биргә килгән мөселманнар өчен иҗтимагый-сәяси үзәк тә булган. Түбән Новгородта Россия мөселманнарының Беренче (1905) һәм Өченче (1906) корылтае уза. Анда татар халкы, мөселманнар тормышындагы мөһим мәсьәләләр тикшерелә, җитди карарлар кабул ителә. 1911 елда, мәчетне бинасы нык таушалу сәбәпле, капиталь төзекләндерү яки шул ук урында яңасын салу мәсьәләсе кузгатыла. Әмма бу эш кичектерелә һәм Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында гамәлгә ашырылмый кала. Мәчетне төзекләндерү өчен соңгы талпыныш 1926 елның сентябрендә ясала. СССР мөселманнары һәм чит ил (Иран, Кытай, Төркия) сәүдәгәр мөселманнары киңәшмәсендә әлеге бина турында да сөйләнелә.1920 еллар азагында, совет хакимиятенең мөселманнарга каршы алып барган сәясәте нәтиҗәсендә, әлбәттә, гыйбадәтханәнең дә язмышы

күләгәдә кала. Бүген исә Түбән Новгород мөселманнары Канаван районында Ярминкә мәчетен яңадан төзү турында уйлый.

Түбән Новгород шәһәренә килгәндә, Д.Хәйретдинов тикшерүләренә караганда, анда кайбер төрки топонимнар очраштыргалый. Әйтик, «Балчуг» – Почаин чокырының түбән өлеше, «Хан ставкасы» – Ильин тауларының тарихи атамасы һ.б. Түбән Новгород шәһәрендә татарларның электән үк булганлыгы 1622 елгы теркәү кенәгәсе, 1630 еллардагы Адам Олеари язмалары һәм башка документлар белән раслана. Аларның саны күп булмаган: 1896 елда 142 татар яшәгәнлеге теркәлгән. Әмма 1912 елга губерна үзәгенә күпләп күчену нәтиҗәсендә татарларның саны 1415кә җитә. Түбән Новгород татарлары Санкт-Петербург һәм Мәскәү кебек калаларның да халык санын шактый арттыра. Түбән Новгород, Сембер губерналары авылларыннан килгән татарлар бу шәһәрләрдә сәүдә иткән, сәнәгать оешмаларында, Иделдәге судно һәм баржаларда эшләгән, халыкка атлы хезмәт күрсәткән, ямщик булганнар. Шул чор чыганакларында татарларның оста, тырыш һәм эшчән булганлыклары теркәлеп калган.

Түбән Новгород җамигъ мәчете 1915 елдан башлап совет хакимияте 1938 елда эшчәнлеген туктатканчы татарларның дини-мәдәни үзәге булган. Бу мәчет татарларның биредә иң борынгыдан яшәү урыны – Иске солдат бистәсендә, Печән мәйданы белән янәшә төзелгән.

Түбән Новгород татарлары төбәк һәм Россия тарихында җитди өйрәнелгән, дип әйтергә мөмкин. Татар халкы, аларның бай рухи дөньясы Түбән Новгород өлкәсе һәм шәһәрендәге социомәдәни тирәлекнең аерылгысыз өлеше булып тора.

Түбән Новгород җамигъ мәчете

Урысчадан Ленар Гобәйдуллин тәрҗемәсе

Әдәбият:

1. Сенюткин С.Б. История татар нижегородского Поволжья с последней трети XVI до начала XX вв. – Нижний Новгород: Издательство Нижегородского государственного университета, 2001.
2. Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть – центр общения российских и зарубежных мусульман (XIX – начало XX вв. Нижний Новгород: Изд-во Нижегородского исламского медресе «Махинур», 2006. – 182 с.
3. Мухетдинов Д.В. Азан над Волгой: к 90-летию основания Нижегородской Соборной мечети и 15-летию ее возрождения. – Нижний Новгород: Изд-во Нижегородского исламского медресе «Махинур», 2006 – 112с. ■

Керәшеннәрнең ислам дине изгеләренә гыйбадәте

Радик Исхаков

Идел-Җаек буендагы урыс булмаган халыкларның традицион мәдәниятенә мөселманнар белән гасырлар дәвамында бергә яшәү шактый йогынты ясаган. Әйтик, мари, чуаш, көньяк удмуртларның теленә ислам тәгълиматы тәэсирендә кергән гарәп-фарсы алынмалары байтак [1, с.4-125]. Җомга көнне бәйрәм итү, дини йолаларны башкарыр алдыннан мунчада юынуны (госел коену), ислам руханиларына охшарга тырышу (чалма кию, дога укыганда билдән бөгелү), корбан чалганда һәм башка эшкә керешер алдыннан «Бисмилла» («Писмилла») дип әйтү кебек мөселман гореф-гадәтләре болын һәм көнчыгыш мариларында, урта (анатри) чуашларда сакланып калган.

Керәшен кызлары. Вятка губернасы Алабуга өязе. XX гасыр башы

Ислам тәгълиматы чалымнарын чуашларның мифологиясендә аеруча күп очратырга була. Әйтик, аларда Пәйгамбәр – бүреләр иясе, Фәрештә – кешеләр белән Тура (югары илаһ) арасындагы илаһи зат; Шуйтан – явыз зат; Эсреле – үлем фәрештәсе; Кирәмәт – кодрәтле рух һәм башкалар булган. Әлеге күренешләр 1906-1908 елларда Казан һәм Сембер губерналары буенча сәяхәт итеп, чуашларның телен, традицион мәдәниятен киң кырлы өйрәнгән танылган мажар этнографы һәм фольклорчысы Д.Мессарошка: *«Халыкның күп өлеше кайчандыр мөселман булган, әмма соңрак уңайсыз сәяси шартларда мөселман дөньясы белән алар (чуашлар) арасындагы мөнәсәбәт өзелә, ә халыкның рухында ислам гадәтләре тәңречелек белән бергә сакланып кала. Бүгенге чуашларның дини ышанулары шушы ике катламнан тора»*, – дип җитди рәвештә фикер йөртергә мөмкинлек биргән [9, с.20].

Мондый күренешләр керәшеннәрдә дә күзәтелә. Аларда исламның аеруча сизелерлек борынгы эзләре ата-бабаларны искә алу белән бәйле йолаларда сакланып калган. Керәшеннәрнең мөселман изгеләренә гыйбадәтен ике төп фактор белән аңлатырга мөмкин: 1) аларда җирле мөселман татарларда да изге саналган затлар, пәйгамбәрләр һәм каһарманнар белән тарихи бәйләнешләр, борынгы ата-бабалар турындагы риваятьләр саклану; 2) изгеләрне һәм гайре табигый көчләргә, әүлияларга, әрвахларга гыйбадәт кылу урыннарын мөселманнар белән бүлешү.

Урта Идел буенда мөселман изгеләре культы барлыкка килү бирегә суфичылык идеологиясе үтеп керү белән бәйле. Танылган археолог А.Х.Халиков фикеренчә, безнең төбәктә суфичылык XIII-XIV гасырларда актив үсеш ала башлый [15, с.114]. Суфичылык традициясендә ата-баба, изгеләр (әүлиялар) рухын хөрмәтләү, гыйбадәт кылу урыннары булу (каберлекләр, төрбәләр) халыкка борынгы, тәңречелектән килгән ышануларны саклап калырга мөмкинлек биргән. Шул рәвешчә, Урта Идел буенда мөселман изгеләренең культы, Урта Азиядәге төрки халыклардагы кебек үк, әүвәлге йолалар белән үрелеп синкретик характер ала.

Мөселман изгеләрен хөрмәтләүгә бәйле йолалар керәшен традицион мәдәниятендә чиркәү әһелләреннән яшереп башкарыла торган гореф-гадәтләрнең берсе булган. Ул православие чиркәвенең һәм җирле мәхәллә түрәләренең иске йолаларга, аеруча ислам дине мирасына карата кырыс мөнәсәбәтенә дучар ителгән. Озак вакытлар халыктагы төрле ышануларга «күз йомарга» мәҗбүр булган православие дине әһелләре XIX гасырда керәшеннәрдәге исламга бәйле теләсә нинди йола һәм бәйрәмнәрне катгый рәвештә тыя башлый. Шул сәбәпле дә бу культны беренче мәртәбә тасвирлау 1840 елларга нисбәтле. 1848 елда Казан руханилар академиясенең бакалавры Н.И.Ильминский, Казан архиепископы Георгий Постниковның мөрәҗәгате буенча, Казан губернасының Лаеш һәм Мамадыш өязләрендәге җирле керәшен халкының дини-әхлакый тормышына анализ ясар өчен озак вакытлы сәфәргә чыгып китә. Фәнни командировка вакытында аның тарафыннан кайбер керәшен татарларының авылында Казан ханлыгы дәверенә нисбәтле мөселман зираты барлыгы ачыклана [6, с.114-118]. Җирле халык бу зиратта үзләренең борынгы бабалары җирләнгән дип санап, каберлекләрне чистартып-карап торган, ата-бабалары рухына багышлап дога кылган. Н.И.Ильминскийның

юлъязмаларында Лаеш өязе Тәмте авылында яшәүчеләрнең мөселман изгесе җирләнгән кабердә башкара торган йолалалары турында кызыклы мәгълүмат сакланган: *«Ташка якынлашып, ул* (Н.И. Ильминскийны озатып йөрүче авыл карты – чукынган татар морзасы) *аны* (ягъни бабасын) *хөрмәтләгәннәрен, мулла чакырып бу таш янында дога кылганлыкларын, узган елны яшь бозауны корбан иткәнлекләрен әйтә»* [11, с.84]. Бу йолада ата-бабаны яд кылу, хөрмәтләү кебек борынгы гадәтнең мөселман традицияләре белән кушылганлыгы күренә. Алар, ислам дине тәгълиматы буенча ныклы күзаллау-белемгә ия булмыйча да, үзләренең мәшһүр, кайчандыр дан-шөһрәт казанган ата-бабаларын искә алганда мөселман йолаларына һәм муллага мөрәҗәгать иткән. Керәшеннәр фикеренчә, аларның борынгы бабалары мөселман булган, шул сәбәпле әрвахларга багышланган дога һәм йолалар да ислам дине кануннары буенча башкарылырга тиеш. Җирле халыкта үз ата-бабаларының шанлы үткәне турында шактый күп санда риваятьләр дә сакланып калган [11, с.84].

1864 елда керәшеннәрнең тагын бер мәшһүр мәгърифәтчесе В.Т.Тимофеев Мамадыш өязе Владимир авылы халкының мөселман изгеләрен хөрмәтләүләре турында искәртә. Бу авылдан ерак түгел, зур булмаган курган бар, риваятьләргә ышансаң, анда ишан (әүлия) җирләнгән. Аның каберендә керәшеннәр ел саен гыйбадәт кылу мәҗлесе үткәрә – ак төстәге үгезне чалып, аның ите һәм борай ярмасы белән корбан боткасы пешерәләр. Бирегә ел саен гыйбадәт кылырга тирә-як авылларда яшәүче мөселман татарлары да килгән, алар да дога кылган һәм корбан чалган. Керәшеннәрдә дә, мөселманнарда да бу урынга бәйле риваятьләр күп. Каберлек яныннан агып чыккан чишмә дә изге саналган, суы да шифалы, иляһи куәткә ия. Җирле халык чишмә турында: *«Аллаһ җирне япатканда, ул әлбелхәят чишмәсен дә бар кылган, әгәр дә без аны эчсәк, мәңге үлмәс идек. Әмма аны* (суны) *безгә кадәр иблис эчкән һәм без инде эчә алмыйбыз, шул сәбәпле үләбез дә»,* – дип сөйләгән [13, с.143]. Бу хикәятнең нигезендә ислам диненә мөнәсәбәтле һәм шул ук вакытта борынгы төрки мифология белән дә бәйләнешле сюжет ята. Мөгаен, бу урын тәңречелек заманыннан ук ата-бабаны хөрмәтли, алар рухына дога кыла торган изге җир булып, соңрак, халык ислам динен кабул иткәннән соң, биредә дога кылу, борынгыларны яд итү мәрасиме мөселман гореф-гадәтләре белән чуарланган булса кирәк.

Чистай өязе керәшеннәрендә мөселман изгесе – «Хуҗа Насретдин» культы белән дә шундый ук күренеш. Бу культ җирле халыкның үз авыллары барлыкка килү һәм ата-бабалары тарихы турындагы риваятьләр белән тыгыз бәйләнгән. Аларның берсендә Югары һәм Түбән Никитино авыллары тирәсендә элек ниндидер патшабикәнең сарае – кыз-патша каласы булганлыгы әйтелә. Шунда ук, курганда аның кабере дә бар. Риваять буенча, керәшеннәрнең бабалары патшабикәнең Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгы яулап алынган вакытта камалышта калган, аннары «урыс динен» кабул итәргә мәҗбүр булган яраннары һәм гаскәреннән барлыкка килгән [12, с.6-7]. Бу гаскәрнең башында Насретдин булып, ул кайчандыр мәшһүр хәлфәнең шәкерте дә икән. Озын-озак гомер сөргән Насретдин Биләр авылы тирәсендәге калкулыкка җирләнгән, шуннан соң бу урын «Хуҗалар тавы» дип атала башлаган. Дөрес, әлеге риваятьнең сюжеты бу-

ТАССРның Теләче районы Янсуар авылы керәшеннәренең гыйбадәте. Һарун Йосыпов фотосы, 1949 ел

талчык, реаль чынбарлыктан шактый ук ерак булса да, җирле халык өчен ул тарихи хәтернең аерылгысыз өлеше – бер ядкяр булып тора. Шул сәбәпле керәшеннәр, мөселман татарлары кебек үк, ел саен әлеге изге урынга гыйбадәт кылыр өчен бара. Мөселманнар корбанны үзләре чалып, чалынган хайван итеннән азыкны үзләре әзерләсә, керәшеннәр исә корбан малын муллага тапшыра. Имам, үз чиратында, изге йоланы керәшеннәргә ислам дине кануны буенча башкарырга ярдәм иткән. Корбан чалу йоласы аларда «куҗа келәве», «куҗа кирәмәте» дип аталган [12, с.8].

Казан губернасы Лаеш өзендәге Ташкирмән авылы керәшеннәренең дә рухи тормышында мөселманнарның изге урыннарына гыйбадәт кылу мөһим урын алып тора. Авылдан ерак түгел, Казан ханлыгыннан калган зур шәһәрлек – Калатау (Ханкирмән) булган. Андагы курганның барлыкка килүе турында җирле халыкта төрле риваять саклана. Аның берсенә ышансаң, борынгы заманда биредә татар ханының Мишә елгасы аркылы һәм Нугай даругасы буенча хәрәкәтне күзәтеп торучы кешеләре, шунда ук крепостьсарае булган. Башка риваять буенча, бу креспостька Казан яулап алынганнан соң яшеренгән баш күтәрүче татар яугирләре нигез салган [5, с.37]. Керәшеннәр биредә ел саен дога кылган, үгез келәве корбан чалу йоласын башкарган. Кар эрү белән курган янына авылның яшьләре җыелган, әйләнбәйлән уйнаганнар, җырлап биегәннәр [5, с.36]. Шунда ук ел саен бирегә атабабаларын яд итәр, рухына дога кылыр өчен күрше-тирә авыллардан һәм Казаннан да бихисап татар-мөселман «хаҗи»лары килгән. XIX гасыр уртасына кадәр бу урында гарәби язулы кабер ташы белән борынгы кабер булган, гадәттә аның янында дога кылганнар. 1870 елда мәшһүр Казан археологы А.Н.Стоянов җитәкчелегендәге экспедиция Ташкирмәнне өйрәнә. Борынгы шәһәрлекне казыганда Казаннан килгән татар «хаҗи»лары белән җирле керәшеннәр галимнәргә каршылык күрсәтә, аларны изгеләрне мәсхәрә кылуда гаепли [4, с.12-13].

XX гасыр башына кадәр Мамадыш өязенең Шоморбаш авылы һәм тирә-юньдәге керәшеннәрдә Чаллы авылыннан ерак түгел генә

җирләнгән Идрис хәлфә культы булган. Керәшеннәр аны үзләренең борынгы бабасы дип санамаган, шулай да аның рухына ирешкән дога һәм ялварулар зур кодрәткә ия, авырусырхаулардан савыктыра, йортка бәрәкәт китерә, дип ышанганнар. Шул чор кешеләре әйтүенчә, бу ишанның каберенә керәшеннәр дә шактый агылган, аның туган-тумачаларына төрле бүләкләр илткән. Бу турыда 1870 елларда студент, соңрак Казан руханилар академиясенең миссионеры, профессор М.А.Машанов менәниләр яза: *«Керәшеннәр һәм мөселманнар бу авылның янында үтеп киткәндә изге гаиләгә кереп чыгу (хәлфә оныкларына) мөмкинлеген кулдан ычкындырмый, аларга төрле бүләк: кемдер сарык, кемдер тавык яки каз китергән»* [8, с.56].

Җирле халыкта бу культ XIX гасыр-XX йөз башында – православиенең көчле йогынтысы тәэсирендә дә сакланып калган. Гаиләдә нинди дә булса бәхетсезлек килеп чыкса, йорт хуҗасы, бар да яхшы тәмамлана калса, шунда «хаҗ кылам» һәм изге рух өчен корбан чалам, дип нәзер әйткән. Керәшеннәр дә, мөселманнардан үрнәк алып, чалыначак корбан малы белән нәзер әйткән, җирле имамга бүләк (сәдака) китергән [16, с.113-114].

XX гасыр урталарына кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Мәләкәс авылында яшәүчеләр дә авылга нигез салучы Искәндәр картны изгеләштергән. Аның кабере авылдагы ташландык татар зиратында булган. Керәшеннәр бу каберлеккә күмелгән мәрхүмнәрне үз ата-бабалары дип санамаган (алар Урта Мәләкәстән күчеп килгән). Шулай да зират изгеләштерелгән, аның туфрагына иген чәчәргә, анда җир казырга рөхсәт ителмәгән. Әлеге табу 1946 елда мәшһүр Казан этнографы Н.И.Воробьев язып алган риваятьтә дә теркәлеп калган: *«Көннәрдән беркөнне бу каберлектә җир йорты (землянка) казый башлыйлар, шулвакыт көчле өермә күтәрелә һәм бу фикердән кире кайталар, чокырны күмеп куялар»* [3, л.60 об.].

Моңа охшашлы күренеш Ләке авылында да күзәтелгән. Авыл территориясендә борынгы татар зираты урнашкан, анда да изге җирне казу-эшкәртү тыелган. Керәшеннәр мал-туарлары чирләп китсә, бирегә дәваларга алып килгәннәр [2, л.62].

Мөселманнарның изге урыннарын хөрмәтләү һәм ата-баба культы арасындагы үтә дә тыгыз бәйләнеш Казан губернасының Тәтеш һәм Цивиль өязе керәшен татарларында (мәлки керәшеннәрендә) да күзәтелә. Шактый соң чукындырылу сәбәпле (XVIII гасыр), җирле халык хәтерендә ата-бабаларының мөселманлыгы турында истәлекләр күп сакланган. Г.Филиппов язып алган риваятькә караганда, *«бу керәшеннәрнең «атакай»лары чукындырылу вакыйгасы күптән түгел генә булган. Алар хәтта мәчет булган урынны да яхшы хәтерли, чукынмый калганнарының исемнәрен атый. Иске Кырбашы авылында XIX йөздә вафат булган Калмат турында сөйлиләр, җирле халыкны чукындырган вакытта ул 18-20 яшьлек үсмер булган һәм миссионерлардан Самарага качкан. Шулай ук Иске Тәберде авылы халкы «Үти» турында сөйли, ул да чукындырудан качып киткән. Аларның икесе дә, миссионерларның йогынтысы кимегәннән соң гына, кире үз өйләренә әйләнеп кайткан»* [14, с.1039]. Кайбер мәлки керәшеннәренең авылында мөселман зираты булган, риваятьләр буенча, анда шул авылга нигез салган ата-баба җирләнгән һәм аларның кабере гыйбадәт, борынгылар рухына дога кылу урыны булган. Керәшеннәрдә, шулай ук җирле татар-мөселманнарда

да Хуҗа Хәсән һәм Мәлки (Мәлик) бабаларның кабере мәшһүр булган, изгеләштерелгән [10, л.98]. Керәшеннәр, мосафир мөселманнар белән бу каберләрне зиярәт кылган, анда дога укыган һәм корбан бугазлаган вакытта муллага мөрәҗәгать иткән [14, с.1038].

Керәшеннәрнең мөселман изгеләренә итагатен күзәтеп, аларда ата-баба культы һәм аның мәҗүсилектән калган борынгы гореф-гадәтләр белән тыгыз бәйләнеше булганын әйтергә мөмкин. Ата-бабаларга хөрмәт, аларның рухын шат итү керәшен мәдәниятендә мөһим урын алган. Бу аларга үткән заманнар турындагы хәтерне сакларга, үзләрен төбәктәге бай тарихның аерылгысыз өлеше икәнлеген аңларга ярдәм иткән. Ата-баба культы, аңа бәйле йолалар, күпсанлы риваять һәм хикәятләр керәшеннәргә мөселман татарлары белән уртак тарихи бергәлекне, туганлыкны сакларга мөмкинлек биргән. Моны америка галиме А.Кефели-Клай болай дип аңлата: *«Мөселман татарлар һәм керәшеннәр бер үк изгеләргә итәгать кылган. Риваятьләргә ышансаң, каберлектәгеләрнең иң изгесе галим яки дәрвиш булган, аның эшгамәлләре турында зур ихтирам белән сөйләгәннәр, ә гайре табигый көче, кодрәте ул вафат булганнан соң да яшәвен дәвам иткән»* [7, с.554].

Бу күзаллау һәм йолалар формалашуга ислам идеологиясе дә нык йогынты ясаган. Бездә булган тарихи-этнографик материаллар да керәшеннәрнең ышанулары күпмедер дәрәҗәдә ислам диненә нигезләнә, ә мөселман изгеләре аларның күзаллауларында яңа төсмерләр ала, дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Әдәбият һәм чыганаклар

1. Ахметьянов Р.Г. Общая лексика духовной культуры народов Среднего Поволжья. – М., 1981. – 200 с.
2. Воробьев Н.И. Село Ляки (Ляке) (кряшены) // Центр письменного и материального наследия Институт языка, литературы и искусств им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан (ЦПиМН ИЯЛИ). Ф.77. Оп. Д.34.
3. Воробьев Н.И. Село Мелекес Челнинского района (кряшены) // ЦПиМН ИЯЛИ. Ф.77. Оп. Д.34.
4. Износков И.А. Материалы для истории христианского просвещения инородцев Казанского края. Вып. 1. – Казань, 1893. – 32 с.
5. Износков И.А. Список населенных мест Казанской губернии, с кратким описанием их. Лаишевский уезд. Выпуск 2. – Казань, 1895. – 80 с.
6. Ильминский Н.И. Татарские надписи из времен Казанского ханства в Лаишевском уезде // Записки Археологического общества. – М., 1851. – Т.3. – С.114-118.
7. Кефели-Клай А. Народный ислам у крещеных православных татар в XIX веке // Российская империя в зарубежной историографии. Работы последних лет: Антология. – М., 2005. – С.539-569.
8. Машанов М.А. Заметка о религиозно-нравственном состоянии крещеных татар Казанской губернии Мамадышского уезда. – Казань, 1875. – 70 с.
9. Месарош Д. Памятники старой чувашской веры. – Чебоксары, 2000. – 360 с.
10. Осипова Л. Моя деревня (с. Молькеево Цивильского уезда Чувашской автономной области) (13 июня 1921 г.) // Научный архив Чувашского государственного института гуманитарных наук. Отд.1. Ф. Н.В.Никольского. Д.309.
11. Отчет бакалавра Казанской духовной академии Н.Ильминского о путешествии по татарским селениям в августе-октябре 1848 г. // Христианское просвещение и религиозные движения (реисламизация) крещеных татар в XIX - начале XX вв. Сборник материалов и документов / сост., авт. вступительной статьи, примечаний, научно-справочного аппарата Р.Р.Исхаков. – Казань, 2011. – С.71-96.
12. Софийский И.М. О киреметях крещеных татар из деревни Тавель, Чистопольского уезда Казанской губернии. Объяснительная записка. Отдельный оттиск из Трудов Четвертого археологического съезда в России. – Казань, 1891. – 18 с.
13. Тимофеев В.Т. Мое воспитание (рассказ старокрещеного татарина) // Казанская центральная крещено-татарская школа. – Казань, 1887. – С.136-154.
14. Филиппов Г. Из истории христианского просвещения крещеных татар-мещеряков Тетюшского и Цивильского уездов Казанской губернии // Известия по Казанской епархии. – 1915. – №37. – С.1036-1043.
15. Халиков А.Х. Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария – Казань, 1994. –168 с.
16. Чичерина С.В. У приволжских инородцев. Путевые заметки. – СПб., 1906. – 410 с. ■

Керәшен авыллары тарихын өйрәнү тәҗрибәсе

Владимир чиркәвенең беренче настоятеле Симеон Гаврилов (2 нче рәттә сулдан икенче). 1890 нчы еллар

Лидия Константинова[1]

Авыл тарихы турында сөйләүчеләрнең беренче җөмләсен мин яттан беләм: ***«Безнең авылга нигез салучылар, чукындырудан качып, шушы матур җирләргә килеп урнашкан»****. Алар һәрвакыт өчәү була, сирәк кенә дүрт. Бу кешеләр каян качып килгән? Аңа кадәр кайда булган? Билгесез. Казан ханлыгы чорыннан ук мәшһүр авылларыбыз да бар бит безнең. Мәсәлән, күршедәге Бөрсет-Сукачы авылы. Ә без аны Владимир авылыннан чукындырудан качып түбәнгә төшеп утырган кешеләр нигез салган, дип өйрәндек. Бактың исә, тарихи чыганаклардан күренгәнчә, ул Казан ханлыгы чорында ук барлыкка килгән авыл, күрше-тирәдәгеләр арасында да иң борынгысы икән ләбаса!*

Керәшен авыллары тарихын өйрәнү мәсьәләсен: «Анда чукындырылган татарлар яши», – дигән фараз катлауландыра шикелле. Мәктәбебездә Владимир, Албай, Югары Әрнәш исемле керәшен авылларыннан укучылар укый. Укучыларны күбрәк шушы авылларның тарихы кызыксындыра. Әлбәттә, без әле авыл тарихын язмыйбыз. Язылганнарны өйрәнәбез, материаллар туплыйбыз, чагыштырып карыйбыз, үзебезчә дөреслеген тикшерергә тырышабыз.

Соңгы елларда авыллар тарихын өйрәнүчеләр саны артуы бик күңелле күренеш. Аларның тарихи чыганаклар нигезендә язылганнары белән бергә камил булмаганнары, ялган, уйдыр-

[1] Мәкалә Мамадыш районы Усали урта мәктәбенең тарих укытучысы, «Туган якны өйрәнү» түгәрәге җитәкчесе Лидия Константинованың Республикакүләм татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр (краеведлар) җыенында

малары да шактый. Бу керәшен авыллары тарихына да кагыла. Әйтик, Владимир авылы тарихы бар. Аның минем кулга килеп кергән вариантын Владимир мәктәбенең татар теле укытучысы Габдрафикова Алсу язган[2].

Анда: *«XVIII йөз башында Маленков фамилияле кеше Бөрсет суы ярында бакыр таба, аны эшкәртү өчен завод сала. Әлеге авылда яшәүчеләр бакыр чыгару заводында эшләп көн иткән»*, – дип язылa. Бу дөреслеккә туры килеп бетми. Кече Бөрсет исемле авыл безнең тирәдә ике була. Аның берсе – Владимирның элеккеге исеме булса, икенчесе, хәзерге Урманчы янындагысы – нәкъ менә бакыр заводы итеп төзелгән. Мин моны каян белдем соң? Шулай бервакыт чиркәү метрикә кенәгәләренә юлыктым. Владимирның элекке исеме урысча «Малый Берсут» икәнен беләм. Ә метрика кенәгәсендә Кече Бөрсет кешеләренә Владимировка священнигы Александр Миропольский кәбен кыйдыра, ягъни венчание уздыра, никах укыта, дип язылган. Аптырап калдым: әллә Владимир бөтенләй «Малый Берсут» булмаганмы? Эзләнә башладым... Таптым бит җавапны. Җавап тарихи чыганакларда бар икән бит!

Чыганаклар буенча «Малый Берсут» – Владимировка, икенче «Малый Берсут» – «Медный завод» булган. «Медный завод» дигәнендә руслар яшәгән булып чыкты. Авыл тарихының авторы: *«Авыл территориясенә беренче килеп урнашкан кешеләр кем булган – татармы, христиан динен кабул иткән кешеләрме – билгесез, – ди һәм дәвам итә, – Марсель Әхмәтҗанов бу хакта: Кече Бөрсет авылы Болгар шәһәреннән килгән мукшылар авылы булган. Бу бик кызыклы мәгълүмат, чөнки бүгенге Шәһре Болгарда сакланган XIX гасыр татар төрбәсендә мукшы хатыны күмелү факты археологларга мәгълүм»*, – дип яза. Җавапны Марсель Әхмәтҗанов үзе үк биргән булып чыга түгелме инде? Шунда ук Владимир авылы тарихының авторы үз фикерен дә өсти: *«Авылны беренче оештыручыларның татарлар булуы турында да фикер йөртә алабыз. Бу хакта аларның фамилияләре дә сөйли: Мукиев – Мокый (Мөкатдисә исемен Усалида Мокый дип кенә җибәрәләр иде), Пасыев – Фәсхетдин, Бахров – Бәкер исемнәреннән ясалганнар. Авылда татар зиратының булмавы (яки аның урынын белмәвебез) безгә бу фактны тулысынча расларга мөмкинлек бирми. Билгеле булган өч зиратта да христиан дине гореф-гадәтләре буенча күмелгәннәр»*. Тагын бер мәгълүмат: хәзерге кибеткә фундамент казыганда кеше сөякләре чыга. Ләкин мәрхүмнәрнең мәҗүсилек йолалары буенча күмелгәнлеге ачыклана.

Бу тарихны укыгач, миңа бик кызык булып тоелды. Пасыева – минем кыз фамилиям. Пасый – минем ерак әбием исеме. Безнең нәсел агачын бабамның энесе, укытучы булып эшләгән Пасыев Николай Владимирович ясап калдыра. Пасый әби миңа алтынчы буын булса, аңа дүртенче буын әби генә була әле. Әбине «Пасый түти» дип йөрткәннәр. Кушаматтан фамилия барлыкка килгән, анда Фәсхетдиннең бер катнашы да юк. (Пасый исеме безнең

сөйләгән докладны нигезендә әзерләнде.

[2] Мәкалә һәм аңа комментарийлар белән бирердә танышырга мөмкин: http://beznenmiras.ru/vladimir-avyly-tarikhy/

Владимирның Биек тау чишмәсе. Монда Владимир керәшеннәре мәҗүсилек йолаларын уздыра

якта очрамый, ләкин керәшен авылларында очратканым бар.) Мукеевлар да Пасыевлардан чыккан нәсел. Шәҗәрә буенча без монысын да ачыкладык. Мокай, Микай – Михаилның керәшенчә варианты. Мокайның фамилиясе Пасыев булган. Укытучы булып эшләгән бабам калдырган нәсел агачын өйрәнеп, авылдагы Малов, Костин, Мукеев, Петров фамилияләренең нәкъ менә Пасыевлардан чыкканлыгын дәлилләдек инде. Нигезендә татар исемнәре булган шактый гына фамилияләрнең дә кушаматтан ясалганлыгы ачыкланды.

Авыл тарихын язучы: «*Кече Бөрсет кайчан Владимир дип атала башлый – бу турыда төгәл мәгълүмат юк. Бары тик беренче буларак христиан динен кабул итүче кеше хөрмәтенә шулай атала башлавы гына билгеле*», – дип яза. Монысы әлегә документлар белән расланмаган. Шулай булуы мөмкин, дип кенә фаразлана.

Ярар, Владимирда чукындырылган татарлар яшәсен дә ди. Әмма авылда кайчандыр ислам дине тоткан халык яшәгәнлеге билгеле түгел. Алда әйтелгәнчә, ислам дине кануннары буенча күмелгән зират та юк. Авыл кешеләре бүген дә мәҗүсилек йолаларын онытмый: корбан ашы үткәреп, яңгыр чакыра, үләләр мунчасы яга, ризыктан тәберсе итә (ризык кабып, үләләрне искә ала, «тәберсе» – «Тәңре бирсен» дигән сүз), йорт ияләренә ботка пешерә... Болар барысы да, минемчә, керәшеннәрнең христиан динен кабул иткәч тә мәҗүсилек йолаларын онытып бетермәүләре турында сөйли.

Менә шулай итеп, укучыларымны төбәк тарихын өйрәнгәндә дә тәнкыйди фикерләргә өйрәтергә тырышам. Аларга: истәлекләр, легендалар нигезендә генә авыл тарихын язып булмый, иң беренче чиратта, әлбәттә, тарихи фактларга һәм тарихи чыганакларга таянырга кирәк, дип аңлатам. ■

Чыганаклар:

1. Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. Вып. 6: г. Мамадыш и Мамадышский уезд. – Казань, 1904. – С.61,68.
2. Списки населенных мест Российской империи, составленные и издаваемые Центральным статистическим комитетом Министерства внутренних дел. – СПб.: изд. Центр. стат. ком. Мин. внутр. дел, 1861-1885. [Вып.14]: Казанская губерния: ... по сведениям 1859 года / обраб. А. Артемьевым. – 866. – LXXIX, 237 с. – С.68,73.
3. Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке.- под ред. проф. Д.А.Корсакова. – Казань, 1908. – С.243.
4. Износков И.А. Два реферата, читанные на IV Археологическом съезде в Казани в 1877 году. – Казань,1882. – С.24,35.

Уртада –
И.М.Егоров
һәм Мамадыш
муниципаль
районы башлыгы
А.П.Иванов

ПИТРАУ
мизгелләре

Бәйрәмнең мәртәбәле
кунагы – Татарстанның
Дәүләт Советы Рәисе
Фәрит Мөхәммәтшин

КЕРӘШЕН СӘРДӘСЕ:
авыл тарихы, халык язмышы, әүвәлге документлар (1490-1900)

Николай Петров-Текин

Керәшен Сәрдәсе – Татарстанның Питрәч районында, Мишә елгасы бассейнында урнашкан бик борынгы керәшен авылларының берсе. Бу мәкаләдә авылның бай тарихы, халкының катлаулы язмышы турында сүз бара. Мишәгә кушыла торган Сәрдә елгасы буенда, Казан шәһәреннән 60 километр көнчыгышта урнашкан Керәшен Сәрдәсе авылының тарихы һәм халкының язмышына кагылышлы документлар Россия дәүләт борынгы актлар һәм Татарстан Милли архивларында саклана.

Мишә елгасы

Шул документларның берсе, бүгенге көндә безгә билгеле булганыннан иң «борынгысы» – Казан ханлыгы басып алынганнан соң 13 ел узгач, 1565-1568 елларда патша Явыз Иван түрәләре Никита Васильевич Борисов белән Кикин Андрей улы Дмитрий төзегән җир биләмәләрен теркәү кенәгәсе – «Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565-1568 годов». Бу документта Сәрдә елгасы буендагы Иске Сәрдә авылы рус бояры Матвей Кузьминский уллары Семенка белән Рахман биләмәсе итеп күрсәтелә. Авылда биш йорт барлыгы, ул йортларның буш, ташландык хәлдә булулары да әйтелгән. Шул ук документта Матвей Кузьминскийның өченче улы Ивашконың Иске Сәрдәдән күчеп, Сәрдә елгасы Мишәгә кушылган җирдә Яңа Сәрдә исемле яңа авыл нигезләгәне дә теркәлгән. Биредә бүген инде буш урыны гына торып калган Рус Сәрдәсе авылы турында сүз бара.

Казан ханлыгы заманыннан ук калган 700дән артык авыл исемлегендә Мишә буендагы Нырсы-Варзи (Нырсывар), Таутермень (Тегермән Тавы), Толкиш, Югары, Урта, Түбән Казы (Керәшен Казысы, Рус Казысы) авыллары, шулай ук Пимәр, Әлбәден, Юныс, Әтрәч, Чыты, Кибәч, Кәүәл авыллары белән беррәттән Иске Сәрдә авылы да исәпкә алына. Сәрдәгә күрше булган Көлкәмәр авылы, бераз соңрак, 1647 елгы җир теркәү кенәгәләрендә чагыла башлый.

Ревизия документында Текиннар гаиләсе. 1720 ел



Җир биләү турында патша грамотасы

ГОСУДАРЕВА ГРАМОТА

По Государеву цареву и Великого князя Василия Ивановича (Шуйский) всея Руси Указу от боярина и воевод от Василия Петровича Морозова да от Богдана Яковлевича Бельского да от дьяков Никанора Шульгина да от Степана Дичкова в Казанском уезде по Нагайской дороге в Старом сельце Серде- половину поместья, что бывало за Семенкою да за Рахманом за Матвеевыми детьми Кузьминского, а после Семенки Кузьминского было за Истомою за Борисова сына Глухова и отписную землю- что отписано было на Государя что остального за их окладом с крестьянами пожаловал Государь царь и Великий князь Василий Иванович всея Руси помещика новокрещена Андрея Володимирова сына Текина ко старому его поместью- что за ним в деревне Шуманех к сорока двум четвертям в додачею, а в отдельной книге Никиты Пелепелицына с товарищи 78 го году (1567) написано отдельно в сельце Старой Серде за Семенкою да за Рахманом за Матвеевым детям Кузьминского в их окладе в триста четвертей (четей) в два по тому ж. Пашни паханые и перелоги и зарослей сто пятьдесят семь четвертей в поле а в дву по тому ж. Сена им обоим вопче по шестьсот копен. Лесу пашенного и не пашенного около поль по смете в длину на три версты и поперек от поль в лес на версту. В том в Старом сельце Серде отписано на государя что осталось за оклады перелогу восемьдесят четвертей с полосминою да зарослей четырнадцать десятин с четвертью десятиной и всего половина Семенковского и Рахманинского поместья Кузьминских и отписной земли сто тридцать восемь четвертей без четвертью в поле а в дву по тому ж. Сена двести пятьдесят копен.

И вы бы все крестьяня, которые ныне в том в Старом сельце Серде в половине Семенковском да Рахманском жеребье и в отписной земле живут и вперед учнут жити помещика Андрея Володимировича сына Текина слушали, пашню на него пахали и доход ему помещиков платили, чем он вас пооброчит до техмест, как за ним то поместье опишут и измерят государевы большие писцы и мерщики и учинят за ним пашни по государеву указу.

К подлинной указной грамоте Государеву и Великого князя Василия Ивановича всея Руси печать царства Казанского приложили бояре и воеводы Василий Петрович Морозов, Богдан Яковлевич Бельской, подъячие Никанор Шульгин да Степан Дичков лета 7118 го (1609) Августа 20 дня.

Указанной грамоте печать черного воску, на обороте посклейками скреплено. Подписал дьяк Степан Дичков, Справил подьячий Ивашко Урусов.

Архивтагы документларда теркәлгән авылларда, шул исәптән Иске Сәрдә авылында да, 1565 елда рус түрәләре хуҗалык итә. Руслар килгәнче анда нинди халык яшәгәнлеге, төп халыкның кайларга күчеп китүе яисә ничек юкка чыгуы (һәлак булуы?) турында бернинди хәбәр сакланмаган. Казан ханлыгы җиңелгәннән соң Мәскәү тарафыннан яңа оештырылган хәрби хакимлекнең җирле халыкка карата бу елларда тоткан үтә дә кырыс алымнарын искә алсак, бу бичараларның авыр язмышы турында җәлләп уйланырга гына кала.

Керәшен Сәрдәсе авылында Казан ханлыгы заманында яшәгән халыклардан истәлек булып калган, Сәрдә елгасы буенда үскән берничә изге чыршы агачы (аның янына ерактагы мөселман авылларыннан гыйбадәт кылырга киләләр иде) һәм Олы елга (халык телендә «Җыланлы җылга») буенда яше мең ярым елдан артып киткән «Берле нарат», «Икеле нарат» агачлар юкка чыкты. «Берле нарат» агачы янындагы 9-10 метрлы ике курган бүген дә үзләренең шомлы серләрен саклап, борынгы халыкларның язмышын искә төшереп тора. Ул балалар ышануында сакланып калган сүзләрдә: «Нарат әбигә шәрә тәнне, бигрәк тә чөмәгеңне күрсәтергә ярамый – кутыр чыга, үләсең»; курганнар турында исә: «Алып бабай чабатасын каккан, шуннан өелгән балчык тавы», – дип сөйләнелә. Аларның төп аңлатмасы авылның яңа хуҗалары Кузьминскийларга да, алардан соң килгән

керәшен алпавытлары, хәрби йомышлы керәшеннәр – Текиневлар, Резяповларга да инде билгеле булмаган.

Казан тарихчысы И.Износковның 1895 елда Казанда басылган «Список населенных мест Лаишевского уезда Казанской губернии с кратким описанием их» исемле китабында Мишә елгасы янындагы Түбән Сәрдә (Рус Сәрдәсе) авылының чиркәвеннән көньяк юнәлештә, 150 сажин арырак, басу кырында борынгы кабер ташлары сакланганлыгы әйтелә. Алар ул вакытта ук инде бик тузып-җимерелеп беткән була. Гарәп графикасында уеп язылган текст калдыклары каберлекнең бу авылларда яшәүче борынгы халыктан калганын күрсәтә. Бүген инде ул ташлар бөтенләй юкка чыккан.

1870 елны Казан университеты профессоры А.Н.Стоянов җитәкчелегендә башкарылган археологик тикшеренүләр вакытында, җирле полиция хезмәткәре күрсәтүе буенча, Югары Сәрдә (Керәшен Сәрдәсе) авылында иске каберлекләр эзләнгән. Бәлки дөрес эзләмәгәннәрдер, тапмаганнар. Аларның кайсы урыннарда эзләүләрен экспедиция хисапларыннан ачыклап булмады. Авыл эчендә, Сәрдә суы буенда бик борынгы, ташландык иске зират-каберлек булганлыгын авыл бабайлары әле 1950 елларда да сөйли иде. Бу каберлекләр, һичшиксез, авылда Казан ханлыгы заманында яшәгән халыктан калган. Күрше Чыты авылы янында А.Н.Стоянов тарафыннан тикшерелгән һәм өйрәнелгән борынгы мөселман каберлеге бүген дә саклана. Чыты авылы халкы бу каберлекне «иске авыл кешеләренеке» дип аңлата. Үзләре турында алар 1610 еллардан соң Арча районы Венета һәм Казан янындагы, инде шәһәр эченә кереп калган Вознесенское авылыннан күчерелдек, дип әйтә. Бу эшләр рус хәрби идарәләре тарафыннан Казан әйләнә-тирәсендә 40 чакрымлык «куркынычсызлык арасы» оештырылган вакытта башкарылган булса кирәк. Бу Керәшен Сәрдәсе авылына яңа хуҗалар булып Текиннар һәм Резяповларның Алат шәһәрчеге (Алат крепосте, Биектау районы) янындагы Шуман һәм Чуаш Иле авылларыннан килүләренең дә төп сәбәбе шул булырга тиеш.

Тарихчы галимнәр фикеренчә, Мишә буе җирләренә Болгар патшалыгы кешеләре XI гасыр башында ук күчеп утырган. Алар килгәнче дә урман-болынлы, чиста суга бай җирләр буш ятмаган билгеле.

Арча районы Сәрдә авылларына да халыкның Мишә буендагы Сәрдәдән аерылып килгәнлеге бик мөмкин. Питрәч, Әтнә, Арча, Балтач, Кукмара районнарындагы Сәрдә яисә исеменә Сәрдә сүзе катнашкан авылларның барысының да (Иске Сәрдә (Керәшен Сәрдәсе), Югары Сәрдә, Урта Сәрдә, Яңа Сәрдә, Сәрдәбаш, Сәрдегән, Сәрдек, Югары Сәрдек, Зур Сәрдек, Яңа Сәрдек, Сәрдегән, Сөрде, Сәрдәүч, Сәрдекбаш) Болгар патшалыгының бер төбәгеннән чыккан, бер нәсел-ыру кешеләре булуы ихтимал.

«Сәрдә» сүзе борынгы нугай-кыпчаклар теленнән алынган. Халкыбызның 1350-1450 елларда иҗат ителгән атаклы «Идегәй» дастанына «сәрдә» сүзе үлән исеме буларак кереп калган. Дастанда менә шундый юллар бар:

«Сәрдә дигән салт үлән –
Аны тапсак утлаек,
Әттек дигән тамыр бар,
Аны да тапсак юшыек».

Биредә сүз Идегәйнең сугышчан иптәшләре белән Туктамыш ханнан качып «шәһре Сарайдан» далага чыгуы, ял иткән урында атларын утлату, туйдыруы турында бара. Мөмкинлектән

Утын юлы тыкрыгы

файдаланып, шуны да әйтергә кирәк, «Идегәй» дастанында керәшеннәрдә генә сакланып калган һәм әле бүген дә гади халык телендә кулланыла торган сүзләр байтак очрый. Академиябезнең телне өйрәнүче галимнәре ул сүзләрне аңлатма белән бирә. Белгечләр өчен инде ул сүзләр аңлашылмый, искергән, бик борынгы кыпчак теленнән калган сүзләр булып санала (мәс.: яренге, җәринкә, чонтык, чүмәк һәм башкалар).

Сәрдә үләне халыкта бүген дә шул исемдә атала (русча: сныть, подагричник). Язын, кар эри башлау белән сәрдә үләне беренчеләрдән булып, дымлы үзәнлектә, урман буендагы ачыклыкта үсә башлый. Элек бу язгы үлән белән атларны кышкы витамин җитмәү авыруыннын (авитаминоз) коткарганнар. Үләннең яшь сабаклары кешеләр өчен дә бик файдалы. Кычытканнан да иртәрәк үскәнлектән, сәрдә үләне авыл халкын язгы ачлыктан коткарган. Дастанда искә алынган «эттек» дигән тамырны – керәшеннәрдә бүген «ирен яргыч үләне» дип йөртәләр. Иске исемен инде бары без генә, карт бабайлар гына беләбез.

1602-1603 елларда Иван Болтин җитәкчелегендә төзелгән Казан өязендәге җир биләмәләрен теркәү кенәгәсендә («Писцовая книга Казанского уезда 1603-1605 годов») Иске Сәрдә авылы телгә алынмаган. Моның төп сәбәбе – ул елларда авылның әле урыс боярлары кулында булуы. Ә искә алынган кенәгәдә сүз «урыс булмаган» хәрби йомышлы керәшеннәр һәм татарлар турында бара.

Шул ук кенәгәләрдә Кече Сәрдә авылы (Рус Сәрдәсе) «пустошь», ягъни буш, ташланган авыл дип теркәлгән. Бу вакытта авылның хуҗалары инде керәшен кенәзләре, бик борынгы нәсел – Асанмурзиннар (Асановлар) булган.

Безнең бабаларыбыз, хәрби йомышлы төрки-нугайлар, 1600 елларга кадәр, Ашыт елгасы буенда Болгар патшалыгы заманында ук корылган Алат крепосте тирәсендәге авылларда, үз җирләрендә иген игеп яшәгән, дәүләт биләмәләренең төньяк чикләрен саклап хезмәт иткән.

1590 елда дәһшәтле Мәскәү патшасы Иван Грозный боерыгы белән хәрби йомышлы Текей бабайга (Текей Азин

1530-1595) Казан өязендәге «Чюваш» авылы (Биектау районы, Чуаш Иле авылы) шәхси биләмә итеп бирелгән. 1609 елда Иске Сәрдә авылы (Керәшен Сәрдәсе) барлык җир һәм урман-сулары белән Алат юлындагы Шуман авылы хәрби йомышлы керәшен алпавытлары Текей Азинның оныклары Текиннар (Текеневлар) һәм Резеповлар кулына тапшырыла. Шул елда ук алар яңа урынга, Сәрдә авылына күченә.

Мәскәү патшасы Василий Иванович Шуйскийның боерыгы буенча, 1609 елның 20 августында Шуман авылы алпавыты, хәрби йомышлы керәшен Ондрей Володимирович Текинга (Андрей Владимирович Текин) бирелгән Грамота аның варисларының берсе булган Яков Егорович Текин (Токиновлар нәсел язуы) кулында 1800 елларда да сакланганлыгы турында Мәскәү архивында документлар бар.

Патша Грамотасы хәрби йомышлы керәшен алпавыты Ондрей Володимирович Текинга Шуман авылындагы җир биләмәләренә өстәмә итеп, Иске Сәрдә авылындагы басу һәм урманболын җирләрнең яртысын бүлеп бирү турында боера. Авылда булган җирләренең икенче яртысы башка грамота белән хәрби йомышлы керәшен алпавыты Семен Лукич Резеповка (Арезепов) бирелә.

Шул көннәрдән башлап, Текиннарның һәм Резеповларның берничә оныгы, аларга 30-40 ел узгач килеп кушылган Филипповлар (Максимовлар, Никитиннар, Казаковлар, Николаевлар) һәм Багишевлар (Постниковлар) нәселләре белән бергә Керәшен Сәрдәсе авылы халкы барлыкка килә. 1647-1656 елгы җир биләмәләрен теркәү кенәгәләрендә алар инде авылның төп хуҗалары итеп күрсәтелгән.

Керәшен Сәрдәсе авылының тарихы 1719, 1748 елларда уздырылган халык исәбен алу документларында да (Ландратские книги, Ревизские сказки) сакланган. Шулай ук 1835, 1850 елларда уздырылган исәпкә алу документларында, 1724 елдан башлап Рус Казысы һәм 1744 елдан соң Рус Сәрдәсе авыллары чиркәүләрендә алып барылган метрикә кенәгәләрендә дә авылда яшәгән кешеләр турында бик җентекле хәбәрләр бар.

1719 елда авылда 12 хуҗалык булган, 49 ир-ат хәрби йомышлы керәшен-җирбиләүче алпавыт яши, дип язылган. 1748 елда йортлар саны – 15, ирләр саны – 46, ә халык инде «йомышлы дәүләт крестьяннары сословиесе»нә күчерелгән. 1795 елда авылда 27 йорт, 92 ир кеше теркәлгән. Бу еллардан башлап халык ясаклы керәшеннәр дип атала. 1834 елда – 46 йорт, 191 ир кеше, 215 хатын-кыз яши. 1850 елда авылда – 49 йорт, 240 ир кеше, 263 хатын-кыз яши. Соңрак уздырылган халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча Керәшен Сәрдәсе авылына кагылышлы документлар архивларда сакланмаган.

Әйтеп үтелгән документлардан авылда борынгыдан ук үзара туган булган дүрт һәм аларга өстәлгән берничә нәсел-ыру кешеләре яшәгәнлеге аңлашыла.

1. Текиннар: Токинов, Александров, Семенов, Овчинников, Михайлов, Карташов, Егоров , Конашев, Киселев, Фадеев, Гаврилов, Малов, Романов, Шалямов, Федоров, Тимофеев, Круглов, Никитин, (Гүрди, Гәңки, Сәтлек), Данилов, Денисов, Топьянов, Никифоров, Сидуков, Цепов, Анисимов, Мойсеевлар;

2. Резеповлар: Владимиров (Бүре), Волков (Бүре), Мухин, Анисимов, Иванов (Башмаков), Цыганов, Кузнецов, Попов, Сергеев, Яковлев (Чтапан, Апач), Калашников, Макашов, Быкеевлар;

3. Филипповлар: Максимов, Сер-

Чишмә янында часовниклар

динский, Никитин (Шайхи), Казаков, Кузьмин, Морозов, Яковлев (Гөркә), Николаев, Чукин, Ворожейкин, Федоров (Пешәү), Вараксин, Ермолаев, Дементьев, Лягушкин, Иванов (Бәтер), Трофимов, Полевой, Трифонов, Афанасьев;

4. Багишлар, Постниковлар.

5. Скворцовлар – 1870 елларда авыл мәктәбенә укытучы булып килгән Николай Федорович нәселе.

6. Белугиннар – 1890 елларда бертуган агалы-энеле Степан Филиппович белән Ефрем Филиппович (Җәпүк) Лаеш районындагы Ташкирмән авылыннан күчеп, авыл мәктәбенә укытучы булып килгәннәр.

Архив документларында теркәлеп калган исемнәреннән күренгәнчә, бүгенге Мишә елгасы буенда урнашкан керәшен авыллары халкының 1600 елларга хәтле Алат юлында (даруга) яшәгән бабалары Бөек Кодрәтле Тәңрегә ышанучылар булган. Гази, Текей, Янсара, Дәүләткилде, Янклыч, Айтуган, Шалкей, Ишбулат, Ногай, Шәмәрдән, Хуҗабирде һәм башкалар. Бу исемнәрдә ислам дине йогынтысы бөтенләй юк диярлек.

Җирле халыкта христиан диненең йогынтысын көчәйтү өчен 1731 елны Зөядәге Богородицкий монастырьда Новокрещенская контора оештырыла. 1740 елны Императрица Анна Иоановнаның 11 сентябрьдәге Указы нигезендә авылларда чиркәүләр төзелә башлый. 1741 елда Рус Казысы авылында таштан Благовещение чиркәве төзелә. Моңарчы анда агач чиркәү булган. 1744 елда Рус Сәрдәсе авылында Преображение Господня чиркәве салынып бетә. Бу чиркәүгә Керәшен Сәрдәсе, Көлкәмәр, Кибәч, Әтрәч, Рус Сәрдәсе кешеләре языла (приход).

Керәшен Сәрдәсендә 1870 нче елларда «школа» ачыла, анда, төп фәннәрдән тыш, өстәмә итеп төрле кул эшләренә өйрәнү түгәрәкләре дә оештырылган була. Беренче укытучылар һәм тәрбиячеләр булып Казандагы үзәк керәшен-татар мәктәбен бетергән, авыл укытучылары династиясенә нигез салган Николай Максимович, Антон Максимович, Петр Максимович, Егор Петрович, Гурий Николаевич Максимовлар-Сердинскийлар, Федор Никитович Никитин, Ташкирмән авылыннан килгән агалы-энеле Никита Филиппович белән Степан Филиппович Белугиннар, шулай ук

Сәрдә авылының хөрмәтле кешеләре

башка авылдан килгән Захар Федорович белән Василий Захарович Скворцовлар эшли. Субаш авылы кешесе, укытучы Гаврила Григорьевның һәм Урахчи авылыннан килгән укытучы Василий Фотеевның исемнәре дә мәгълүм. «Школа»да шулай ук төрле елларда Казан укытучылар семинариясен, укытучылар курсларын бетергән ир һәм хатын-кыз укытучылар да эшләгән. Сәрдә халкы үзенең беренче укытучыларын бүген дә онытмый, зур хөрмәт белән искә ала.

1887 елда И.А.Износков чыгарган белешмәдә («Список населенных мест Казанской губернии с кратким описанием их. Лаишевский уезд» за 1887 год): «Югары Сәрдә авылы исемсез чишмә янында, Нугай сәүдә юлыннан сул якта урнашкан. Шәһәрдән 39 чакрым, волость идарәсе 6 чакрым (Рус Казысы авылы). Авыл 2 чакрым ераклыкта урнашкан Түбән Сәрдә авылы чиркәве приходына беркетелгән. Авылдагы 118 хуҗалыкта 438 ир-ат һәм 452 хатын-кыз яши. Халкы керәшеннәр. Жир биләмәләре 1864 дисәтинә...», – дип язылган.

Архивта сакланган материалларга караганда, 1860 елларга кадәр авыл Олы урамның «Югары оч күпере» белән «Түбән оч күпере» арасындагы мәйдан белән чикләнгән булган. Авылның Югары очы (күпердән югары ягы) – «Түбән оч», «Атау», «Арт урам» дип йөртелгән урыннары башлыча 1860-1890 елларда, хәзерге «Ышна юлы», «Утын юлы» кырларындагы урманнарны арчып, ышна кырын ачканда киселгән агач-бүрәнәләрдән төзелгән.

1900 елны авыл инде хәзерге чикләренә таралып каршы алган. Шул елдан авыл халкы өчен иксезчиксез бәла-каза, рәхимсез ачлык, сугыш кайгы-хәсрәтләре алып килгән дәһшәтле XX гасыр башлана. Бу инде моңарчы күрелмәгән башка тормыш, бөтен ил белән бергә кичергән яңа тарих. Анысы турында журналда аерым язма булыр, дип өметләник. ■

Казан керәшен татарлары мәктәбе укытучысы Семён Максимовның 1876 елда Казан Император университеты типографиясендә рус телендә басылган «Остатки язычества в современных верованиях крещенных татар Казанской губернии» исемле китабы – мифик затлар турындагы җыентыгы бу өлкәдә иң яхшы һәм тәфсилле хезмәт, дип әйтергә була. Татар халкының академик героена, милли философик категориясенә әверелеп барган шүрәле, өй, абзар, су, урман ияләре, албасты, пәриләр беренче мәртәбә матбугатта шул китап битләрендә дөнья күргән булса кирәк.

Кызганычка каршы, китапның авторы, аның тормыш юлы һәм иҗаты турында без бик аз беләбез. Уйлавыбызча, Семён Максимов Лаеш өязе Пановка волостеның Кәвәл авылы (хәзер Питрәч районы) кешесе булырга тиеш. Ул, Казандагы керәшен татарлары школын тәмамлагач, шунда ук учитель булып эшләгән.

Китапның оригиналы белән таныштырган өчен Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе хезмәткәрләренә зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Тексттагы кайбер сүзләрне керәшеннәрнең сөйләш-диалект үзенчәлекләрен саклап тәрҗемә итәргә булдык.

Николай ПЕТРОВ-TEKIN

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ КЕРӘШЕННӘРЕ

ышануларында мәҗүсилек күренешләре

Семён Максимов[1]

Өй иясе. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов

Борынгы заманда бүгенге керәшен татарлары мәҗүсилектә булган. XIV гасыр башында алар ислам диненә кергән, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң кайберләре христиан диненең православие тармагына кереп, чукындырылган. Ике йөз елдан кимрәк арада, яшәү рәвешләренә җайсыз булган ислам дине, һичшиксез, керәшен татарларының рухи дөньясына тирән сеңеп өлгермәгән. Аларда шулай ук христианлык та ныклы урын алмаган. Шунлыктан керәшен татарларының бүгенге ышанулары борынгы мәҗүсилек, ислам һәм христиан диннәре карашлары катнашмасы булып тора.

Керәшен татарларында, соңгы унъеллыкта христиан дини белеме таратылу нәтиҗәсендә, борынгы мәҗүсилек ышанулары акрынлап онытыла бара һәм йолалары да кулланылыштан чыга. Шуңа күрә бүгенге керәшен барлык борынгы ышануларны җентекләп сөйләп бирә алмый. Бу ышанулардан соңгы вакытта кушылган рус халкы һәм ислам карашларын аеру бигрәк тә кыен. Шундыйларның берсе – ислам динендәге Аллаһ һәм христиан тәгълиматы дәлилләгән Өчле Алла – дөньяны бар кылучы төшенчәләр катнашып, татарларда бүгенге көнгәчә сакланган Аллага борынгы мәҗүси караш. Китерелгән язмаларда үземә таныш булган һәм әби-бабалардан ишеткән кайбер борынгы татар ышанулары бирелә.

АЛЛА-БАБАЙ. КҮКТӘГЕ ИҢ ОЛЫ ЗАТ (ТӘҢРЕ-БАБАЙ)

Алла-Бабай дип, бүген инде сирәк булса да, керәшен татарлары Күкне һәм Җирне булдырган Олы затны әйтәләр. Керәшен татарлары аны бүген күбесенчә ислам-гарәпчә Алла дип атыйлар. Тәңре-Бабай – Алла-Бабай дип әйтү башлыча ислам диненең йогынтысы зур булмаган керәшен татарлары, «руслашкан» керәшеннәрдә сакланган. Руслар белән бергә яшәгән урыннардагы керәшен татарларында иске «Тәңре», «Тәңре-Бабай» атамалары бигрәк нык сакланган. «Алла» дип әйткәнгә алар бик нык үпкәли, хәтерләре кала. Аларда әүвәлге Алла-Бабай турында шул исемнән башка бик аз нәрсә сакланган. Гомуми әйткәндә, керәшен татарлар Алла-Бабай исемендә күзгә күренмәгән Алланы һәм үзләренә ислам, христиан диннәреннән кергән барлык ишеткән-белгәннәрен кушып аңлый. Асылда, «Тәңре» – борынгы мәҗүси татарларда Аллага саналган Күк исеме. Христианлыкка кергәннән соң керәшен татарлары «Тәңре»дән Тәре сүзен ясаган, алар христиан иконаларын шулай исемли. Керәшеннәр телендә «Бабай» карт кешене күздә тота. Шунлыктан керәшеннәр Алла-Бабай ак сакаллы карт зат, дип уйлый. Алар аңлавынча, нәкъ менә шул Алла дөньяны, җирне яраткан. Ул барысына да җитешүче, ул булмаган урын юк, аның торган урыны биек күктә санала, исеме дә шуны раслый. Ул барлык кешеләрнең дә гаделлектә, тәкъва яшәүләрен тели һәм гөнаһлылардан тәүбә көтә, тәүбәсезләргә авыр җәзалар юллый. Шуларга өстәп, керәшеннәр әйтүенчә, Алла-Бабай күкне күкрәтә, җиргә яңгыр яудырып үсемлекләрне, игеннәрне уңдыра, бозык-гөнаһлыларның чәчкән игеннәрен боз яудырып кырып бетерә.

Алла-Бабайның күкне ничек күкрәтүе турында керәшеннәр болай сөйли. Шайтанны куркытырга кирәк булганда ул бик зур арбаларга яхшы юртаклар җигә дә, арбаның түренә уты-

---

[1] Максимов С. Остатки язычества в современных верованиях крещенных татар Казанской губернии. – Казань: Типография Императорского университета, 1876.

рып, күктә шайтанны куып йөри, бер кулына дилбегә, икенчесенә озын чыбыркы алып атын куалый; зур арба тиз чабудан күк тетри, безгә күк күкрәве ишетелә. Аның чыбыркысы шартлаудан яшен яшьни, утлар күренә. Башкачарак аңлаулар да бар: Алла-Бабай, үзенең бик зур арбасына арканнар белән күп итеп гер сыман авыр түгәрәк әйберләр бәйләп, күк буйлап чабып йөри. Шунлыктан, арба артына тагылган герләр сикерешеп күкне күкрәтә. Һәрхәлдә, татарлар аңлавынча, күкне Алла-Бабай күкрәтә. Мондый вакытта алар балаларына: «Әнә, Тәңре-Бабаң җөри!» Яисә: «Тәңре-Бабаң күкрәтә! Ул яңгыр яудыра, сиңа дәү булырга икмәк үстерә», – дип әйтә.

Шуннан аңлашылганча, күк күкрәү вакытында керәшеннәр арулана, күктә йөрүче Алла-Бабай алдында үзләрен тыйнак тотарга тырыша. Балаларына бер урында хәрәкәтсез, тыныч утырырга кушалар, өйдән чыгып йөрергә, икмәк ашарга да ярамый. Керәшен гаиләсе белән өстәл артында ашап утырган вакытта күк күкри башласа, ашау-эчү туктатыла, табын җыештырыла. Сөйләшү, көлешү, бигрәк тә сүгенү зур әдәпсезлек санала. Ышанучы керәшеннәр күк күкрәгәндә чукына, ә ислам йогынтысындагылары «бисмилла»ларын кабатлый.

Алла-Бабай хөрмәтенә керәшен татарлары әле дә төрле корман китерә: көз көне быел туган сарык яисә каз, үрдәк чала. Кайберәүләр корман урынына тәре алдында шәм яндыра, ярлыларга яңа үскән уңыштан сәдака өләшә. Бу – корманнар Алла-Бабайга иген уңышы, йорт хайваны, кош-кортлар үрчүе өчен рәхмәт белдерү рәвеше. Моннан тыш яз, җәй көннәрендә Алла-Бабай хөрмәтенә яңгыр явып, игеннәр уңуын теләп башка корман йолалары да уздырыла (сыер, сарык, тавык, балык һәм ботка).

Керәшен татарларның ышануыннан күренгәнчә, Алла-Бабай Күк Алласы итеп хөрмәтләнә, җир уңдырышлыгы, кеше, мал-туар иминлеге аның карамагында. Күк Алласына өстәп керәшеннәр тагын берничә түбәнрәк дәрәҗәле җир аллаларын да беләләр. Алар төрле урында күзәтү алып бара, җирнең төрле урыннарында хакимлек итә. Өй иясе, Абзар иясе, Су иясе, Урман иясе, Шүрәле, Пәри шундыйлардан.

ӨЙ ИЯСЕ

Өй иясе, керәшен татарлары ышануынча, үзе торган өйдәге гаиләне яклаучы рух. Өй иясе, инде исеменнән дә күренгәнчә, йортта иң олы хуҗа. Олы йорт хуҗасы буларак, Өй иясе, яшь кеше булып, беркайчан да күзгә чагылмыйча олы яшьтәге ир яисә хатын-кыз рәвешендә күренә. Һәр йортта да, һичшиксез, үзенең Өй иясе бар, ул мич башында, мич астында яисә йортның идән астында була. Керәшен татарлары әйтүенчә, Өй иясе йортның төрле почмакларында яши, ләкин кайда икәнен төгәл күрсәтмиләр.

Керәшеннәр Өй иясенең йортта уңышлы тормыш иминлеге өчен кирәк булуына шиксез ышана. Шунлыктан һәр йорт хуҗасы йорт нигезен алыштырганда аны үзе белән алып китәргә тырыша. Бу максатта алар хатыны белән төнлә иске өйгә бара да зур хөрмәт белән Өй иясен чакырып, аның ияреп килүенә шикләнмичә, яңа өйләренә кайта. Тик юлда кеше очрамаска тиеш. Бу очракта Өй иясе юлдан борылып иске өенә кайтып китә. Ул вакытта, кире барып, Өй иясен зур хөрмәт белән яңадан чакырырга мәҗбүр булалар...

Йорттан берничә гаилә аерылганда Өй ияләре ничек барысына да җитә торгандыр – әйтү бик кыен. Башка

чыгучы һәр угыл, әтисе рөхсәте белән, Өй иясен үзенә чакырып алып китә, шул ук вакытта иске йорт та Өй иясез калмый.

Йорт хуҗалары белән шулай яшәп Өй иясе төрле эшләр башкара: тегә, эрли һ.б. Мин үзем әби-бабайлардан берничә мәртәбә: «Фәлән кеше Өй иясенең эшләгәнен күргән, аның йөргәндә аяк тавышларын ишеткән, имеш», – дип ишеттем...

Өй иясенең эшчәнлеге төнлә генә мөмкин, көндез аны берәү дә күрми. Әле школада укыган вакытымда мин боларның барысына да ышанып, үзем бер дә күрмәгәнлектән: «Нигә мин бер дә күрмим соң Өй иясен, башкалар күрә, нишләп соң мин күрмим?» – дип уйлый идем. Шулай уйлап, мин бервакыт арыганчы эшләдем дә кичтән иртә ятып йокладым. Бераз йоклаганнан соң уянып киттем дә, нәрсәдер уйлый гына башлаган идем, кинәт җеп эрләгәндәге орчык тавышын ишеттем... Ничек безнекеләр шулай иртә торып эрли дә башлаган, дип бик аптырадым. Күзләремне ачып карый башлагач, мин тагын да хәйранга калдым, чөнки өйдә ут алынмаган, ә орчык тавышы ишетелә бирә... Орчык тавышы килгән урынга бик озак дикъкатьләп караганнан соң, миңа сәке өстендәге тәрәзә янында кемнеңдер орчык эрләве күренде. Шул өрәктән куркып мин баштан ары бөркәнеп яттым, тиздән йокыга да киттем. Иртәгесен мин өйдәгеләргә төнлә нәрсә күргәнемне сөйләдем. Алар миңа Өй иясен күргәнлегемне әйтте. Шуннан соң мин Өй иясенең барлыгына, аның төннәрен орчык эрләвенә чынлап ышандым. Соңыннан миңа Өй иясе кешеләр эшләгән барлык эшләрне дә эшли, дигәнне ишеткәләргә дә туры килде...

Өй иясенең холкы турында керәшеннәр: ул кешегә усаллык теләми, яхшылык теләп йортка уңыш китерә, диләр. Хуҗаларның сәламәтлеге хакында кайгырта, аларның байлыкларын арттырырга булыша һ.б.

Өй иясенең хөрмәтсезлеккә ачуланып кешегә җәза китерүе дә бар. Өй иясенең үченнән куркып, керәшен татарлары аны онытмыйча хөрмәт күрсәтергә тырышалар. Өй иясенә яхшы мөнәсәбәтләрен күрсәтү өчен аның хөрмәтенә ботка пешерәләр, кайберләре каз да чала, йорт җекләренә тимер ватыклары куялар (корыч кыстыралар), чорма өстенә бәләкәй янчыкларга акча салып эләләр. Йортта берәрсе авырып китсә яисә тормыш көйсезләнә башласа, керәшеннәр: «Искә алмаган өчен, аның хөрмәтенә корман уздырмаганга безгә Өй иясе ачуланган», – диләр. Ачулы үчен искәртү өчен керәшеннәр еш кына хатыннарын күремче карчыкка Өй иясенең ниятләрен белергә җибәрәләр. Күремче, боларның Өй иясеннән курыкканнарын аңлап, акча күбрәк алу өчен аларны ялганлап, белгән кеше булып кыланып: «Әйе, әйе, сезгә Өй иясе ачуланган, берәр төрле корман бирергә кирәк», – дип тегеләрне тагын да куркыта. Керәшен хатыны, күремче сүзләренә ышанып, тизрәк корман уздыруны кайгырта башлый. Андый вакытта керәшеннәр күпчелек очракта «җорт урынын уздыруы» корманын бирәләр. Моның өчен керәшеннәр казан тулы борай боткасы пешерә, аны өч яисә дүрт табакка салып эскәтерле өстәлгә куя. Өстәлгә, шулай ук чүмеч белән су (мөмкинлек булса су урынына чүмечкә сыра яисә шәраб салалар), берничә кашык һәм җиз акчалар куялар. Өстәл янындагы тар сәкеләр өстенә киез җәяләр, киез өстенә мендәрләр куялар. Бар да әзерләнеп беткәч, олылар – ирле-хатынлы (ата-ана яисә хатыны белән олы дәдәй) кулларына ботка салган табаклар алып, тәреләр (иконалар) каршына басалар да, нәрсәдер пышылдап, Өй иясенә келәү итәргә то-

тыналар... Аларның төп келәү уйлары йортның иминлегенә, җәмәгатьләрнең исән-саулыгына юнәлгән. Тәреләр (иконалар) каршында Өй иясенә әйтелгән теләү сүзләренә баш орулар кушыла, ләкин гадәттәге чукынулар юк. Келәү беткәннән соң хуҗалар боткалы табакларны өстәлгә куялар, үзләре идән астына төшеп (түбән өй) бер почмакка тимер кисәге куялар (корыч кыстыралар). Минем уйлавымча, «корыч кыстыру» Өй иясе хөрмәтенә башкарыла, тик мин аның мәгънәсен аңлата алмыйм.

Йорт хуҗалары идән астыннан чыккач, ике табак ботканы, кашыклар салып, сәке астына, Өй иясенә куялар. Өстәлдәге вак җиз акчаларны җыеп кечкенә янчыкка салалар да, чормага меңгереп элләр. Бу янчыкка берәү дә тими, акчалары да тотылмый. Ел саен янәшә эленгән янчыкларда Өй иясе «кулында» вак җиз акчалардан зур капитал җыела... Чормадан төшкәч, бөтен гаилә, өстәл янына утырып, калган чашкалардагы ботканы ашыйлар. Сәке астындагы чашкаларны икенче көнне иртән алып, боткасын ашыйлар. Еш кына сәке астындагы корман боткасын тычкан-күселәр хуҗалардан алдан ашап өлгерә...

Иркен тормышлырак керәшеннәр, байлыклары тагы да арта башласа, Өй иясе хөрмәтенә, баерга булышканы өчен сарык яисә сыер чалалар, ботканы ит белән алыштыралар. Бу эшләр ике-өч елга бер башкарыла. Мал-туар чалу – Өй иясен аеруча хөрмәтләү билгесе. Гадәттә, ботка белән корман китерү һәр ел саен көз көне оештырыла.

АБЗАР ИЯСЕ

Керәшен татарлар Өй иясеннән башка тагын Абзар иясе дә барлыгын беләләр. Абзар иясе – йорт хайваннарын, мал-туарны яклаучы үзенә башка рух. Ул абзарда яши, абзар хуҗасы булып санала. Аның нинди рәвештә йөргәнен керәшеннәр бик төгәл белеп бетерми. Байтак бабай-әбиләрдән аның эт сурәтендә йөргәнлеген ишеткәнем бар... «Фәлән кеше Абзар иясенең абзарда атларның ялларын тарап-үреп утырганын күргән», – дип сөйләүчеләр дә бар. Абзар иясен күрүчеләр әйтүенчә, атларның ялларын тарап-үреп утырганда ул ут кебек ялтырап, анык сурәтсез булып күренә.

Һәрвакыт абзарда яшәгәнлектән, Абзар иясе күбесенчә үзенең яраткан атлары турында кайгырта, ашарына бетсә, аларга печән сала, ялларын чишмәслек итеп чуалта. Абзарда ике ат булып, аларның берсен Абзар иясе яратмаса, ул төнлә гел ашамлыксыз кала. Кешеләр йоклагач, Абзар иясе аның ашамлыгын алып, үзенең яраткан атына сала. Шулай эшләп ул яраткан атын көрләндерә, ә яратмаганын бөтенләй арыкландырып, йөнтәйтеп бетерә. Шуның өстенә Абзар иясе яратмаган атын газаплап төн буе абзарда куып йөртә, хәтта атланып та чаба. Кайвакытта иртән ат тирләгән булса, хуҗа атымны Абзар иясе яратмый, төнлә абзарда ул атланып йөргән, дип уйлый. Шул сәбәпле, яңа ат сатып алганнан соң керәшеннәр аны яхшы ашатып, көрләнүен күзәтәләр. Әгәр дә, яхшы ашатуга да карамастан, ат яхшы көрләнмәсә керәшеннәр атны Абзар иясе яратмаганлыгын аңлыйлар һәм аны тизрәк сатып җибәрү юлын эзлиләр. Атның арыклыгына башка сәбәпләр эзләп тормыйча, аны саталар...

Беркөн шулай мин күрше керәшенгә кердем. Ишегалдында яхшы гына ат йөри иде. Күршенең улы, минем иптәшем, атка карап миңа: «Кара әле, Семён, менә бит бу атны Абзар иясе бик ярата... Әнә, кара, ялларын ничек чуалтып бетергән, үзе дә шундый шома, ә без бит аны аерым туйдырмыйбыз», – диде. Мин аңар: «Нишләп инде Абзар иясе аның ялла-

Абзар иясе. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов

рын чуалтып торсын! Атыгыз каядыр ышкынгандыр, шуннан аның яллары чуалган...» – дидем. Иптәшем миңа яңадан: «Юк, атның яллары нигә алай үзенә-үзе чуалсын? Атның куллары юк ич... Менә, кара, бүген мин синең алда атның ялларын сүтәм, ә иртәнгә алар тагын чуалган булырлар», – диде. Мин аңар каршы: «Бик шулай булуы бар! Сез бит атыгызның ялларын бервакытта да яхшылап юып-чистартып тарамыйсыз, атыгыз ышкына да аның яллары искечә чуала», – дидем. Мин уйдырмаларга каршы тагын күп сүзләр әйттем, ләкин ул миңа ышанмады, үз уенда, атның ялларын Абзар иясе чуалта, дигән ышануында калды.

Керәшеннәр уйлавынча, Абзар иясе дә, Өй иясе кебек, аны онытмаган хуҗаның мал-туарына зыян китерми. Әгәр дә йорт хуҗасы Абзар иясенә хөрмәт күрсәтергә онытa икән, ул хайваннарга төрле зыян китерә: үләт җибәрә, кысыр калдыра һ.б. Абзар иясенең ачуын китермәс өчен керәшеннәр ел саен «Абзар урынын уздыруы» корманын оештыралар.

Бу корман алдан ук тамгалап куелган берьеллык бәрән чалудан тора. Гадәттә, һәр хуҗа Абзар иясенә корманга беришле төстәге бәрәнне чала, мәсәлән, караны. Шуннан соң инде хуҗа ел саен кара бәрән чалырга тиеш була – башка төстәге корман бәрәнен Абзар иясе кабул итми. Әгәр дә хуҗаның берәр елда кара бәрәннәре булмый икән, ул елны корман китерелми, каралар туган елга калдырыла.

Абзар иясе хөрмәтенә корман чалуның керәшеннәрдә төгәл билгеләнгән көне юк. Гадәттә, ул көз көне, кыр эшләре беткәч, түбәндәгечә башкарыла: кояш баеп, караңгы төшкәч, тамгалап куелган бәрәнне абзарга кертеп, дүрт аягын бергә бәйлиләр дә чалалар. Чалучы йортта иң олы ир кеше булырга һәм ул башына бүрек кияргә тиеш. Чалынган малның эчке әгъзаларын шунда ук абзарда күмәләр, итен пешерергә өйгә

алып керәләр. Йорттагы иң олы хатын-кыз бу итне төн уртасы җиткәнче пешереп өлгертергә тырыша. Төн урталары җиткәч, пешкән ит казаннан табакка салына. Йорт хуҗасы белән хатыны табакны кулларына тотып абзарга чыгалар да билгеләнгән җирдә Абзар иясенә мал-туарлар файдасына келәү итәләр. Келәүдән соң йорт хуҗалары корман итен күтәреп өйгә керәләр, барысы да өстәл артына утырып корман итен ашый. Бу итне шул ук төнне ашап бетерү тиеш. Корман бирүче йорт хуҗасының гаиләсе аз булса, ул вакытта чалынган бәрәнне пешерергә салганчы буйга – башыннан койрыккача урталай кисеп казанга салалар, икенче яртысын калдыралар. Керәшеннәр уйлавынча, бәрәннең пешерелгән яртысы бөтен бәрәнне алмаштыра. Бәрәннән калган сөякләрне хуҗалар, корман ашыннан соң, шунда ук абзарга алып чыгып, чалынган бәрәннең эчке әгъзалары янына күмәләр.

Абзар иясенә корман багышланган көнне керәшеннәр өйләренә чит кешене кертмиләр, ишегалдына да уздырмыйлар. Бу көнне килгән кунакларга алар: «Бүген без сине каршы ала алмыйбыз, иртәгә килерсең», – диләр. Килгән кунак борылып китә.

СУ ИЯСЕ

Керәшен татарларында, Өй иясе һәм Абзар иясеннән кала, тагын Су иясе исемле суда яшәүче рух бар. Өй иясе һәм Абзар иясеннән аермалы буларак, ул кешегә зарарлы, усал рух булып исәпләнә: керәшеннәр аннан бик куркалар. Керәшеннәр су буена ялгыз барырга куркалар, бигрәк тә кич белән кояш баеган вакытта. Керәшеннәр, үзе генә су буенда йөргән кешене Су иясе тотып үзе белән суга алып кереп китә, дип ышыналар, кич белән су буенда басып торырга да куркалар. Суга батулар саксызлыктан түгел, Су иясе тотып алганлыктан, дип ышаналар. Су иясе ел саен бер кешене корманга алган шикелле алып тора. Су иясе суда, аерым яхшы йортта яши. Вакыты белән ул торган урыныннан корыга чыгып йә кеше, йә дуңгыз һ.б. булып йөри. Ул ешрак кеше рәвешендә. Су иясенең йөзе гаҗәеп матур: нәзек сызылган кара кашлары астында кара күзләре бигрәк күңелгә ятышлы булалар, ә иңбашларын каплаган дулкынлы озын кара чәчләре аның башын бизи. Ул ирләр, хатыннар, картлар, карчыклар, яшь егетләр яисә кызлар булып та йөри ала. Кайсы вакытта ул, яр буена чыгып, кешеләр арасында танылмыйча йөри. Базарда ул үзенә кирәк-ягакларны сатып ала. Түбәндәге сөйләмнәрдән аның чагылышларын күрергә була.

Безнең күрше кызы инешкә суга төшкәндә басмада утыручы яшь хатынны күргән... Кыз бала: «Бу яшь хатын нишләп утыра монда?» – дип уйлаган да, су ала башлаган. Шул арада яшь хатын суга чума да юкка чыга. Күрше кызы, куркуыннан чиләк-көянтәләрен калдырып, өнсез булып чабып кайтып, күргәннәрен өйдәгеләргә сөйли. Барысы җыелышып елгага төшәләр, ләкин берни дә күрмиләр.

Тагын бер кыз шулай ук суга барган да елга буйлап (сай инеш) зур дуңгызның мыркылдап йөргәнен күрә... Аңа игътибар бирмичә су ала башлый. Шулвакыт кыз суның икегә аерылганын, дуңгызның су астына кереп югалганын күрә. Кыз куркуыннан өенә чаба, күргәннәрен туганнарына сөйли. Шунда ук халык җыелып су буена дуңгызны кыйнарга йөгерә, ләкин бернәрсә дә тапмыйлар. Сөйләүләре буенча, бер керәшен эңгер-меңгердә бөя буйлап, тегермән яныннан барганда, тегермән бөясендә кемнеңдер коенуын һәм чәчен таравын күргән. Коенучы йөзгә бик матур, бик ак, чиста

Су иясе. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов

тәнле, озын кара чәчле булган. Керәшен якыная башлагач, коенучы суга чумып югалган. Керәшен кыю кеше булган, яр буендагы коенучы чумган урынга килгән. Яр буенда керәшен бик зур алтын тарак табып алган да өенә кайтып киткән. Бик кыйбатлы әйбер итеп алтын таракны сандыкка салып, йозакка бикләп куйган. Ачыкланганча, бу тарак Су иясенеке булган, ул таракны керәшен алганны күргәч, аны өенә хәтле озата барган. Керәшен өенә кергәч, аның кайда торганын белеп, кире кайтып киткән. Икенче көнне төнлә Су иясе керәшеннең йортына килеп, стенага кагып керәшенне уяткан, аңа бик кырыс итеп: «Китер минем таракны! Бар, алган урыныңа илтеп куй!» – дип кычкырган.

Керәшен Су иясенең сүзен нинди кырыс-катгый булса да тыңламаган, тарак анда калган. Өченче төнне Су иясе тагын килгән дә: «Китер минем таракны! Бар, алган урыныңа илтеп куй! Алып барып куймасаң, мин сине үтерәм яисә йортыңны өстеңә ишәм!» – дип кычкырган. Керәшен курыккан, икенче көнне иртүк торып, таракны алган да тегермән бөясенә килеп, алган урынына куйган. Шуннан соң, читкә качып, Су иясе ни эшләр, дип карап тора башлаган. Керәшен таракны урынына кую белән Су иясе судан чыгып, таракны алган да суга чумган.

Керәшеннәр әйтүенчә, берәр кеше кайсыдыр урынга беренче мәртәбә тегермән кора икән, бөя астына нинди булса да хайванны салып калдырырга тиеш була. Бу хайван Су иясенә багышланган була. Кайберәүләр, тегермән корганда, керәшеннәр ышануынча, Су иясенә корманга дуңгыз баласын яисә эт баласын салалар, ә кайберәүләр хәтта балаларны да... Һәрхәлдә, керәшеннәр шулай уйлый. Су иясе, шул беренче корманнан соң, тегермәнчедән шундый ук багышлауны көтә, тегермәнче ел саен бөя астында салган кебек хайванны капчыкка салып суга батыра. Тегермәнче шулай

итеп Су иясенә килешенгән корманны китермәсә, аның тегермән бөясе тормый – Су иясе җимерә. Сөйләүләренчә, бер тегермәнче, берничә ел корман китергәннән соң, бер елны корман бирми калдырган. Бу хәбәр Су иясенә җиткәч, ул төннәрен тегермәнгә килеп ишек шакый, тегермәнчегә: «Ник син миңа корман китермисең? Мин синең тегермәнеңне сакламам, ә үзеңне үтерермен!» – дип кычкыра.

Тегермәнче, шулай озак куркытып йөрүгә дә карамастан, Су иясенең сүзен тыңламаган. Шуннан соң Су иясе, кичләрен тегермән астына төшеп, су кулисаларын урыннарыннан кузгата башлаган, тегермәнчегә аларны озак көйләргә туры килгән – тегермән озаклап эшли алмаган. Тегермәнче Су иясенә корман китерергә мәҗбүр булган – суга елдагы билгеле хайванны салган, Су иясе аны борчуын туктаткан.

Керәшеннәр Су иясе турында тагын менә нәрсәләр сөйлиләр. Бер карчык онықасы белән күрше авылга бара икән. Оныкасы авырлы була. Юлда аларга зур күпер аркылы чыгарга кирәк була да алар шунда утырып ял итәргә туктый. Күпер зур елга аркылы салынган була. Оныка сүз арасында әбисенә тиздән бәби тудырасын әйтә. Бу сүзгә әбисе: «Оныкам! Кендек әбисе үзем булырмын, вакытында мине дәшәрсең!» – ди. Оныка, моны теләмәгәнлектән, әбисенә әйткән: «Кендек әбисе итеп сине дәшкәнче мин Су иясен чакыртам», – дигән... Вакыт җиткәч, яшь хатынга кендек әбисен чакырталар, ләкин ул булыша алмый. Икенче, өченче әбиләрне дәшәләр – алар да булыша алмый. Бала тудыручы хатын бик җәфалана башлагач, священникны чакыралар. Священник: «Нигә шулай газапланасың? Үтәлмәгән адарынуларың юкмы?» – дип сораштыра башлый. Шунда бала тудыручы хатынның исенә төшә: «Мин бервакыт кендек әбисе булырга теләгән әбиемә ялгыш сүзләр әйткән идем, сине дәшкәнче мин Су иясен чакыртам, дигән идем», – ди. Священник (сөйләүче уенча, ул адарыну сүзен үтәп, Су иясен чакыртырга киңәш биргән) кайтып киткән. Аннан соң кендек әбисе Су иясен чакыртырга булган. Бер бик таза ир-ат, оныканың адарыну сүзләрен әйткән урынына, Су иясен чакырырга күпергә киткән. Өченче тапкыр чакырганнан соң, су икегә ярылып, Су иясе чыккан да булышырга барырга күнгән. Тудыручы хатын янына килеп, ул аңа кендек әбисе булып булыша башлаган. Бала тудыру уңышлы узганнан соң, исем кушарга священникны чакыралар. Священник килеп тиешле келәүне укыган. Келәү укыганда Су иясе кендек әбисе сурәтендә басып торган, келәүдән соң үзенең су патшалыгына кайтып киткән. Соңгы хикәя барлык керәшен татарларында да сөйләнелә. Тик кайбер урыннарда сөйләмдә священник турында сүз юк. Священник турындагы сүзләрнең хикәягә соңыннан, керәшеннәр христианлыкка кергәч өстәлгәне ачык күренеп тора, чөнки алар мәҗүсилектә вакытта священникларның да, аруландыру келәүләренең дә булуы мөмкин түгел. Искиткеч гаҗәп: риваять буенча, Су иясен кендек әбисе итеп чакырырга кешеләргә священник киңәш биргән. Ләкин бу христианча түгел, шунлыктан Су иясенең кендек әбисе булуына ышану мәҗүсилектән калганын күрсәтә.

Урысчадан ***Николай ПЕТРОВ-ТЕКIN*** *тәрҗемәсе.*

Ахыры бар ■

Тирән тарихлы Азнакай

(Азнакай районының үткәне турында яңа мәгълүматлар)

2009 елдан башлап Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Альберт Борһанов җитәкчелек иткән Алтын Урда комплекслы тарих-археология экспедициясенең фәнни-эзләнү эшләре нәтиҗәсендә республикабызның көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш төбәгендә, шул исәптән Азнакай районында да яңа ачышлар ясалды. Тарихчы-археологлар алдагы еллар һәм башка төбәкләр белән чагыштырганда, Татарстанның көнчыгыш районнарында фәнни-тикшеренү эшләрен комплекслы алып бара башлады. Элек мәгълүм һәм яңа табылган археологик, эпиграфик, архитектура-сәнәгать объектларын өйрәнү белән бергә архив, музей материалларын һәм торак-пунктлар тарихы буенча да мәгълүматларны тупладылар. Экспедиция эшчәнлеге нәтиҗәсендә табылган, тикшерелгән археологик һәм нумизматик материаллар Азнакайның төбәкне өйрәнү музеена тапшырылды. Шунысын да искәртик: Азнакай шәһәренең бу бай музее күптән түгел генә ике катлы яңа агач бинага күчерелде, аны рәсми рәвештә ачу тантанасы ошбу елның август аенда булыр, дип көтелә.

2014 елның 22-23 май көннәрендә Азнакай шәһәрендә район хакимияте башлыгы М.З.Шәйдуллин ярдәме белән «Татарстанның көнчыгышында кеше һәм җәмгыять. Азнакай төбәге: тарих һәм мәдәният мәсьәләләре» дигән беренче халыкара фәнни-гамәли конференция оештырылган иде. Анда Молдавия (Гагаузия), Төрекмәнстан, Украина,

Белоруссия, Кырым, Мәскәү, Уфа, Октябрь, Самара, Казан һәм башка шәһәрләрдән галимнәр, укытучылар, музей хезмәткәрләре, төбәкне өйрәнүчеләр катнашты. Әлеге гыйльми чара башланганчы ук кунакларга конференциядә укылган фәнни докладларның җыентыгы һәм А.Борһанов, Җ.Мөхәммәтшин язган «Древности Азнакаевского региона», «Очерки истории Юго-Восточного Татарстана» исемле монографияләр таратылды.

Азнакай районындагы археология һәм эпиграфик ядкярләрне өйрәнүнең кайбер нәтиҗәләре турында сөйләргә сүзне әлеге җыентыкларның авторы, ТРФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының татар-болгар цивилизациясе бүлеге мөдире, ТРның атказанган фән эшлеклесе, тарихчы-археолог, шәркыятьче ***Альберт Әхмәтҗан улы БОРҺАНОВ****ка бирик.*

Азнакай районы археология, эпиграфик, мәдәният һәм архитектура тарихы җәһәтеннән аз өйрәнелгән, бирегә максатчан экспедицияләр дә күптән оештырылмаган. Археологлар исә Азнакай районының Ык елгасы буе, Татарстан һәм Башкортстан чиген, анысын да разведка рәвешендә генә өйрәнгән иде. Биредә бронза чорына (б.э.к. II меңеллык) кадәрге ядкярләр табылган. Районның төньяк өлешендә Алтын Урда дәверенә (XIII-XIV гасырлар) нисбәтле Чиялек культурасына караган һәйкәлләр булуы теркәлгән. «ТАССРның археологик истәлекләре» исемле җыентыкта Азнакай районында 7 археологик объект булуы әйтелә. Әмма биредә урта гасырларга нисбәтле бер генә эпиграфик һәйкәл дә искә алынмаган.

Безнең эзләнүләр нәтиҗәсендә бүген Азнакай районында 51 археологик объект булуы ачыкланды һәм тагын 30 борынгы зиратта 200ләп эпитафия өйрәнелде. Археологик объектларның 27се вакытлыча кешеләр яшәгән җир, 4се каберлек һәм 3 курган, 11 авыл һәм 7 борынгы предметлар табыла торган урын тәшкил итә. Бу саннар тагын да күбрәк булырга мөмкин, аны без төгәл итеп киләчәктә, киң масштаблы археологик тикшеренүләр үткәреп кенә ачыклый алабыз.

Азнакай районындагы, гомумән Татарстанның көнчыгышындагы иң борынгы археологик һәйкәл таш гасырга нисбәтле. 1997-1998 елларда Ык ярларын ныгыту буенча барган төзелеш вакытында борынгы хайваннарның казылмалары – мамонт, йонлач мөгезборын сөякләре табылган. Хәзерге вакытта Урсай авылының мәктәп музеенда 10 кг авырлыктагы бәрмә теш һәм 8 данә мамонт теше, мөгезборын сөякләре саклана. Шунда ук чакматаш кораллар һәм казылма ташлар бар... 1986 елда Эстәрле елгасы буендагы Митрәй авылы зиратында неолит дәверенә караган кара чакматаштан эшләнгән калып рәвешендәге табылдыкка юлыгалар.

Неолит (яңа таш дәвер) чорына нисбәтле археологик табылдыклар биредә хуҗалык итү рәвеше әзер, табигать биргәнне файдаланудан (аучылык, җиләк-җимеш җыю) җитештерүчәнлеккә (игенчелек, терлекчелек) күчкәнен күрсәтә. Шул ук вакытта йон эрләү, туку, керамик савыт-саба ясау, шомартылган таштан эшләнгән кораллар барлыкка килә. Орнаментлы, түгәрәк яки очланган төпле савыт кисәкләре – неолит дәвере катламында иң еш очрый торган табышлар. Археологик казылмалар төбәктә неолит дәверендә Ык, Зәй, Агыйдел буйларында төньяк боланы, аю, кабан, байбак, күптөрле су җанварлары үрчегәнлеген күрсәтә.

Б.э.к. II гасырда Татарстанның көнчыгыш һәм Башкортстанның көнбатыш районнарында металл эшлән-

Азнакай районында экспедиция вакытында. Уртада – А.Борһанов. 2013 ел

мәләр тарала. Бакыр эретмәләрен файлана башлау кешелек тарихының яңа этабы – бронза чоры үсешенә юл ача. Бронза гасыры башланганлыкның төп билгесе – мәрхүмнәрне курган астына җирләү. Моны Евразия регионнарында, Урал һәм Кубань буйларында киң таралган Бура һәм Андронов культурасы ядкярләре дәлилли. Татарстанда 500гә якын Бура культурасына нисбәтле каберлек барлыгы ачыкланган. Аларның күбесе Кама аръягында, шул исәптән 34е Азнакай районында урнашкан. Урсай, Татар Шуганы, Тымытык, Күктәкә, Сарлы, Сөендек, Сасыкүл (Бүләк), Түбән Эстәрле, Югары Эстәрле, Урманай, Чекан, Константиновка авыллары һәм Җиңү бистәсендәге табышлар Бура культурасына карый.

Күптән түгел генә ачылган, урта гасырларга нисбәтле археологик объектлар аеруча зур кызыксыну уята. Татар Шуганы, Сарлы, Сөендек, Түбән Эстәрле, Константиновка, Урсай, Тымытык, Митрәй, Әсәй һәм Чалпы авылларында урта гасыр торулыклары саклана.

2010 елда Ык елгасының уң як яры буенда, Урсай авылыннан 4 чакрым, иске зираттан төньяк-көнчыгыш юнәлештә 200 метр ераклыкта, Ык елгасының борынгы үзәнлегендәге торфлыкта янгын сүндергән вакытта Иске Урсай торулыгының калдыклары табылды.

2010 һәм 2013 еллардагы тикшерүләр күрсәткәнчә, бу торулык турыпочмак рәвешендә, көньяк-көнчыгыштан төньяк-көнбатышка юнәлгән 5,4 га мәйданда урнашкан. Стратиграфик өйрәнү мәдәни катламның 35 см.дан 95 см.га кадәр җиткәнен күрсәтте. Торулык җирләрен Ык елгасы күтәрелгәндә су баскан. Казу эшләре вакытында таш, кирпечтән төзелгән янган мич калдыклары табылды. Кызыл һәм көрән балчыктан әвәләп эшләнгән, орнаментлы яки орнаментлары аз булган «чиялек» тибындагы савытлар Алтын Урдадагы чүлмәк ясау традицияләренә хас.

Табылдыклар тимер, известь, таш (тегермән) кисәкләреннән гыйбарәт. Тимердән ясалган әйберләрдән урак, дага, пычак, казанның 2 кисәге, керамик орчык башлары, бронза төстәге

Иске Урсай шәһәрлеген казу вакытында. 2013 ел

керамик һәм кара төстәге таш төймә, кайрак таш бар. Табышларның бер өлешен ашханә калдыклары тәшкил итә. Бу вак һәм мөгезле эре терлек, кыргый җәнлекләрнең сөякләре. Топографик һәм стратиграфик тикшеренүләр нигезендә торулыкны XIV-XV гасырларга нисбәтле, дип әйтергә мөмкин.

Шуны да искәртик, Ык елгасының уң ярындагы төрле җирләрдә, Урсай авылынан ерак түгел, су баса торган үзәнлектә төбәкне өйрәнүче Р.Зарипов һәм җирле халык тарафыннан археологик предметлар җыелды. Урта гасырларга караган әлеге табышлар бүген авыл музеенда саклана. Алар арасында Алтын Урда керамикасыннан эшләнгән чүлмәк кисәкләре, тимер әйберләр, авыл хуҗалыгы кораллары, тоткалар, кадаклар бар.

2013 елдагы эзләнүләр нәтиҗәсендә Урсай авылының үзәк өлешендә, бакчаларда XVII-XIX гасырларга нисбәтле коллекцияләр табылды. Болар кызыл балчыктан шомартып ясалган куе яшел һәм көрән төсле керамика калдыклары, тимердән эшләнгән әйберләр – дага, йозак, бөҗра, соскыч, коелган кадаклар һ.б. Безнең тарафтан Азнакай туган якны өйрәнү музеена тапшырылган әлеге предметлар Урсай авылына XVII гасырда нигез салынганлыгын күрсәтә, моны язма чыганаклар да исбатлый.

Археологик һәм язма чыганаклардан кала, Урсай авылының һәм күрше-тирә торак пунктларның тарихи үткәне авыл читендәге өч иске зиратның XVII гасыр-XVIII йөз башына нисбәтле кабер ташларында да чагыла.

Урсай, Тымытык, Сарлы, Чалпы, Татар Шуганы, Азнакай, Сәпәй, Митрәй, Әсәй, Уразай, Урманай, Кәкре Елга һәм башка авыллардагы борынгы зиратларда да гарәби язулы, орнаментлы татар эпиграфик ядкярләре саклана. Шулай ук Бөгелмә, Әлмәт, Мөслим, Лениногорск, Ютазы районнары зиратларындагы кабер ташлары да фотога төшерелде, җентекләп өйрәнелде.

Татарстанның көнчыгыш һәм Башкортстанның көнбатыш районнарындагы иске зиратларда сакланучы эпиграфик истәлекләрнең 1960 елларда ук Һ.Йосыпов, 1980-1990 елларда М.Әхмәтҗанов, Җ.Мөхәммәтшин

Иске Урсай шәһәрлеге янындагы борынгы зират

һәм Г.Хисамиева тарафыннан өлешчә өйрәнелгәнен дә әйтергә кирәк.

Татарстанның көнчыгышындагы аеруча әһәмиятле ядкярләрдән Иске Урсай каберлегенә аеруча игътибарны юнәлтәсе килә. Ул Урсай авылыннан 4 чакрым ераклыкта, Ык елгасының уң ярындагы борынга урнашкан. Биредә ике дистәгә якын гарәби язулы татар кабер ташы бар, шуның 15е яхшы сакланган. Бер ташның артына баш рәвешендәге кояш сыман түгәрәк баш (күзе, борыны да бар) сурәтләнгән. Баштан ике якка, түбәнгә ике елан төшеп китә. Иске Урсай зиратындагы кабер ташларының төп үзенчәлеге – тамгаларда һәм алар безгә рун алфавитындагы хәрефләрне хәтерләтә.

Борынгы төрки мәдәнияттән үк килгән тамгалар тәңречелек традицияләренең ислам сәнгате белән кушылып яшәгәнлеген күрсәтә. Бу тамгалар Татарстанның көнчыгышындагы татарлар тарихына үзенчәлекле төсмер бирә, аларның мәдәниятендә борынгы төрки катламның нык сакланганлыгын дәлилли.

Әүвәлге төрки бабаларыбызның традицияләре Азнакай төбәгенә күчмә дала кабиләләре кыпчаклар һәм нугайлар, ә ислам диненә мөнәсәбәтлеләре Идел-Урал буенда яшәүче мөселманнар белән үтеп кергән. Барлык бу мәгълүматлар Татарстанның көнчыгышы, Башкортстанның көнбатышы һәм көньягында, Казакъстанның төньяк-көнбатышында Идел-Урал буеның бердәм халкы формалашуда Алтын Урдадагы, соңгырак Нугай Урдасындагы этник төркемнәрнең ролен тагын бер мәртәбә ассызыклый. Археологик, этнографик материаллар, комплекслы эзләнүләр дә моны дәлилли.

РЕДАКЦИЯДӘН: күренекле археолог-галим, «Безнең мирас» журналының редколлегия әгъзасы, актив авторыбыз **Альберт Әхмәтҗан улы Борһановка** *12 июльдә 60 яшь тула. Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар, яңа тарихи ачышлар телибез.*

ҖӨРИ ДАРУГАСЫ

Рәдиф Сәгъди,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Мамадыш төбәге Татарстан Республикасының иң гүзәл табигатьле урынында урнашкан. Елга-күлләргә, урман-чытырманнарга, тау-калкулыкларга бай, халкыбызга Шәйхи Маннур, Рәис Даутов, Миңгол Галиев, Әхмәт Гадел, Зиннур Мансуров, Анатолий Иванов, Валерий белән Иван Егоровлар, Шаһинур Мостафин, Марат Закирларны биргән мәртәбәле як!

Үткән гасырның туксанынчы елларында, безгә – күчмә театр (хәзерге Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры) артистларына бу искитмәле матур якларга бик еш, елына кимендә икеөч мәртәбә гастрольгә чыгарга туры килә иде. Кешеләре – ачык йөзле, кунакчыл. Якын туганнарын көтеп алгандай каршы алалар, кунак итәләр. Килгән-килгән, барлык авылларга да керергә, шул исәптән тау астында, үзәнлектә урнашкан салаларыбызны да калдырмаска тырышабыз. Яңгырфәлән яуса, ул таулардан төшүләре бер бәла булса, менүләре мең бәла иде! Ярый әле күмәк хуҗалыкларның бар чагы, олы юлга кадәр тарттырып чыгарырга тракторын алдан ук әзерләп куялар. Шыгрым тулы заллар, көчле алкышлар, кыр чәчәкләре... Авыллар гөрләп яшәгән вакыт. Яшьләрнең бер өлеше туган җирендә калып иген игә, мал үрчетә, гаилә кора, дәвам үстерә. Урамнарда чыр-пыр килеп уйнаган балалар авызында – җанга рәхәтлек биргән татар телебез.

Җөри авылы да тау астына, сихри табигать кочагына сыенган гүзәл, кадерле авылларыбызның берсе. Чана шуарга таулар кирәк, дисәң – таулары бар, терлек асрыйм, дисәң – мул үләнле елгасы, үзәннәре җәйрәп ята! Мондагы Җөри, Уткина (Ылыя), Юкәче, Кумырык салаларында күп еллар буе татар-керәшеннәр гомер сөрә. Җөринең тарихы Казан ханлыгы чорына – XIV йөзгә үк барып тоташа. Биредә сәүдә юлы да үткән булырга тиеш, күрше-күлән халыклар да бирегә алыш-биреш ясарга килгәндер. XIX йөздә җирле халыкның курыс-мунчала төшерү кәсепчелеге дә мәгълүм. Нәтиҗәдә, сату-алу эшләре белән йөрүчеләр телендә әлеге тарафка илткән юл «Җөри даругасы» дип атала башлый.

Кемнәр соң алар – татар керәшеннәре?

Энеле-абыйлы Валерий (сулда) һәм Иван Егоровлар

Ургый гына, ургый урак урдым –
Ата-бабаларның кәсебе.
Керәшеннәр кемнәр, дип сорасаң,
Болгарлардан килә нәселе! –

дип борынгы җырга салынгандыр аның тарихы, тарихи асылы. Шунысы да җанга якын, татар керәшеннәренең теле мин уйнап үскән тау ягы сөйләменә тач тәңгәл килә: бездә дә бит «яфрак»ны – «япрак», «ярату»ны – «җарату», «Фәридә»не – «Пәридә» һ.б. диләр. Күренә ки, ислам, нәсара диннәре килеп кергәнче, безнең яшәү рәвешебез охшаш, хәтта берүк булган. Ләкин, Аллага шөкер, язмыш нинди генә сынаулар бирмәсен, барыбер бер милләт булып, кунакларга йөрешеп, җырлар җырлашып яшәргә мөмкинлек калдырган!

Керәшеннәр белән иң беренче тапкыр Казан театр училищесына укырга кергәч танышкан идем. Вера Минкинаның туганнан туган энесе Сергей Пашин, Аграфена Васильевалар белән бергә укыдык. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә, Балык Бистәсе районы җегете Степан Михайлов (үзебезчә Чтапан) җан дусларымның берсе иде. Сирәк очрашкаласак та, әле дә араларыбыз өзелгәне юк. Ә менә Җөри авылы җегете Иван Михайлович Егоров белән мин тәүге кабат 1988 елда очраштым. Бу вакытта ул сәүдә һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә хезмәт куя иде. Безне мөхтәрәм җитәкченең урынбасары, авылдашым Илһам Әсхәт улы Шиһапов таныштырды. Тәкъдиргә язылып куелган булган, күрәсең, тормыш тыкрыкларында Иван Михаил улы белән шактый еш күрешкәләргә туры килде миңа... Аның Әфганстан сугышында катнашуын белгәч, яшь язучы буларак, бу хакта төпченеп тә караган идем, вәләкин әллә ни мәгълүмат ала алмадым. Хәвефле елларга әйләнеп кайтасы килми иде аның...

***

Алты баланы (шул исәптән Ваняны да) якты дөньяга китергән Аграфена түтәй белән Михаил дәдәй, бик яшьли әти-әнисез калып, ятимлекнең ачысын да, төчесен дә татый.

«Минем әти 1939 елда хезмәткә алына, кайтыр вакыты җиткәч, алман сугышы башланып китә. Кайта алмый кала әткәй. Ул хезмәткә киткәндә миңа дүрт ай гына тулган була. Бабай кулында үстем. Бик иртә кул астына керергә туры килде. Авыл җирлегендә нинди хезмәт бар, барысын да өйрәнергә туры килде. Хәзер генә авыл кешесенең кадере бетте. Эше юк, эше булса, акчасы юк», – дип хәтерен яңарта Михаил Василий улы. Ул Ишки мәктәбенә йөреп укый, җиде сыйныф белем алгач, урманын да кисә, комбайнчы ярдәмчесе булып та эшли, көчен сыный, тәҗрибә туплый. Махсус курсларда укымаса да, кызыксынучан үсмер тракторын да, комбайнын да йөртергә өйрәнә һәм... гомер буе шулардан аерылмый.

Аграфена ханым да әнисенең вафатыннан соң әбисе янында кала. Матрена Максимовна аны йорт эшләренә өйрәтә. Кыз, дүртенче сыйныфны тәмамлауга, терлек карарга фермага йөри башлый, орчык кадәр булуына карамастан, өлкәннәргә ярдәм итеп үсә. Пенсиягә чыкканчы фермадан китми. Үзләре ятимлектә иза чиккән Михаил белән Аграфена балаларын – йөрәк майларын – бар күңел җылысын салып, кадерләп, хезмәт сөючән оланнар итеп тәрбиялиләр.

Аграфена түтәй: «Балаларны да эшләтеп үстердек, яратсак та, иркәләмәдек, – дип ассызыклый. – Иван дүрт-биш яшьтән атасына ияреп йөрде. Әтисе Микай куа тора, ул, киреләнеп, иярә тора. Трактор арбасына менеп кача, утырып китә. Балаларны эшсез тотмадык без! Өйдәге сыерларны да үзләре чиратлашып сава иде. Унынчы сыйныфны бетергәч, «физкультура укытучысы булам», диеп, Ваня югары уку йортына документларын тапшырып кайткан. Шуны белгәч: «Улым, печәнне кем җыяр соң, син дә булмагач», – дигән идем, аптырап тормады,

Туган нигез

Аграфена түтәй белән Михаил дәдәй

аттестатын кире алып кайтты да, печән чабарга чыгып китте... Армиядән соң гына: «Үпкәләмәгез, мин укырга керәм, печәнен-утынын каникулда җыярбыз», – диде. Һәм Казанга юл тотты.

Гаять мөһим урынны «Армиядән соң...» диеп җиңел генә узып киттем кебек. Әйе, көннәрдән беркөнне ата-ананың уң кулы, иң зур терәге, энесеңелләренә үрнәк булган олы уллары Ваняга Совет армиясе сафларына китәргә вакыт җитә. Әфганстанда канкоеш барган чор. Ул вакытта баласын хәрби хезмәткә озаткан һәрбер ана «сугышка гына эләгә күрмәсен», дип теләгәндер. Сугыш ул, нинди генә булмасын – «салкын»мы, «локальный»мы, «кайнар»мы – барыбер коточкыч күп кан, корбан сорый торган «ерткыч». Сугыш барыбер сугыш ул!

Ваняны Совет Армиясе сафларына туган-тумачалары гына түгел, авылдашларының шактые озатырга җыела. Йоласы шул. Хезмәт иткәннәргә кызлар да башкача карый, ил картлары да ихтирам итә...

Өйдән чыгып китәр алдыннан әбисе аңа изге теләкләрен, изге догаларын сеңдергән кызыл тукыма кисәге бүләк итә:

– Исән-сау гына йөреп кайта күр, Ваня, улым, Ходай Тәгалә сине мәрхәмәтеннән ташламасын! – ди.

– Рәхмәт, әбекәй, күкрәгем түрендә саклармын, – дип, яшь солдат бүләкне комсомол билеты эченә тыгып, түш кесәсенә урнаштыра.

– Кире әйләнеп кайтуыңны да күрергә язсын иде, – дип, күз яшьләрен сөртә әбисе. Күңеле тулган чак булса да, егет аны-моны сиздермәскә тырыша, шаярткан-көлгән итә:

– Борчылма, әбием, әле без синең белән Кала тавына җиләк җыярга да йөрербез, Тәпи чишмәсенә суга да барырбыз!

Туган авылын, Нократ елгасының яшел үзәнлекләрен, газиз туганнарын ике елга калдырып китүе җиңелләрдән булмагандыр аңа. Әле кая эләгәсен дә белгән юк бит. Дөрес, бераздан вакыт үзе бу сорауга төгәл җавап таба: Әфганстан... Ике тапкыр яралана, үлем белән һәрдаим «качышлы уй-

Дуслар җыелган җирдә...

ный», ләкин әбисе талисман-бөти итеп җибәргән кызыл тукыма кисәге булышкандырмы, шәхси батырлыгы өчен бирелгән «Кызыл Йолдыз» орденын күкрәгенә тагып, Иван туган нигезенә исән-сау әйләнеп кайтып төшә.

Аграфена түтәй: «Иван сугышка эләккәч, әй, бетерде инде мине... Урысча да белмәгәч, бик кайгырдым инде аның өчен. Дүрт ай хаты килмәде бит, дүрт ай! Аны уйлап кайгырулар нык бетерде, – дип искә ала, аннары дәвам итә: – Ул армиядә чакта:

Һавалардан очкан аккошларның
Каурыйлары җиргә ташлана.
Өмет итәм, балам, өмет итәм, балам,
Гомереңдә мине ташлама! –

диеп, елый-елый җырлый идем. Аллага шөкер, исән-сау әйләнеп кайтты балакаем. Ташламый! Хәзер сәламәтлегебез нык какшады. Ул ярдәм итеп тормаса бетәр идек. Сугышта орден алгач, отпускага кайтардылар аны, шатланып туймадык инде Микай белән...»

Илгә бик күп батырлар биргән татар-керәшен халкының батыр ул-кызлары, саный китсәң, дистәләгән, йөзләгән! Советлар Союзы каһарманнары майор Петр Михайлович Гаврилов, генерал-лейтенант Дмитрий Михайлович Карбышев, армия генералы Алексей Иннокентьевич Антоновлар – барысы да татар милләтеннән, үзебезнең керәшен егетләре. Ничек алар белән горурланмыйсың?!

***

Питрау җыены – татар-керәшеннәрнең иң зур бәйрәме. Ул һәр елны июльдә, җәйнең кыл уртасында үткәрелә. Питрауда кәләш сайлыйлар, Пакрауда туй үткәрәләр. Бу көнне яшьләр өлкәннәрнең күзенә чалынмаска тырыша, җыелышып кырга чыга. Төне буе җырлап-биеп, уеннар уйнап таң аттыралар. Шуңа күрә Питрау халыкта кояш бәйрәме булып та санала.

Питрау бәйрәмендә

***

Иван вакытын бушка үткәрми, Казан дәүләт педагогика институтына укырга керә. 1987 елда аны уңышлы тәмамлап, сәүдә өлкәсендә хезмәт итә башлый. Тырыш, сүзендә тора белүче, өлгер егетне күрмичә калмыйлар, әлбәттә...

Аграфена түтәй: «Кешегә эш кирәк. Эшсез кеше – кеше түгел ул! Менә без, Микай дәдәгез белән, гомер буе эштә булдык. Башта юклык дип тырыштык, аннан балаларны үстерергә дип тырыштык. Хәзер инде тырышып та булмый, картаеп киттек. Гомер үтә дә китә икән! Аллага шөкер, Лиза белән Вася үзебезнең янда. Иван белән Валерий да, Зоя белән Люба да гел кайтып тора. Ташламадылар», – дип куана.

Директор итеп билгеләнгәч, Иван Михаилович Усад спирт заводын яңа бер югарылыкка күтәрде, техник мөмкинлекләрен яңартты, җитештерелгән тауарның затлылыгына, сыйфатына зур игътибар бирде.

И.М.Егоров 2002 елдан башлап «Ак Барс» холдинг компаниясенең генераль директоры, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты. Әлбәттә, аның эшчәнлеген ил агалары күрмичә калмады: 2006 елда «Ел җитәкчесе» дигән Россия күләмендәге премия белән бүләкләнде, 2007 елда аңа «Татарстан Республикасының атказанган азык-төлек сәнәгате хезмәткәре» мактаулы исеме, 2008 елда «Россиянең агросәнәгать комплексы үсешенә керткән хезмәтләре өчен» алтын медале, 2009 елда II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» медале бирелде, шул ук 2009 елда Россия Президентының Рәхмәт хатына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Тугрылык өчен» билгесенә дә лаек булды.

Бертуган Егоровларның барысы да бу тормышта лаеклы урыннарын тапкан. Елизавета – Җөри авылында җирле үзидарә җитәкчесе. Яшьтән үк мәдәният-сәнгать тормышында кайнап үскән кыз соңгы елларда Питрау

бәйрәмен оештыруда зур тырышлык куя. Валерий Шәдче урта мәктәбен тәмамалагач, Иван абыйсы юлыннан китә – Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый, аннан соң Шәмәк мәктәбендә укытучы булып эшли. Соңрак Иван Михайлович җитәкчелек иткән заводка тәэминат инженеры булып эшкә урнаша, биредә һөнәри тәҗрибә туплый. 1998-1999 елларда Мамадыш районының Тәкәнеш сәүдә оешмасын, 1999-2002 елларда «Татпотребсоюз»ның Түбән Кама районындагы сәүдә оешмасын җитәкли. 2002-2003 елларда «Ак Барс» холдинг компаниясенең Әлмәт шәһәрендәге «Предторг» сәүдә оешмасының генераль директоры вазифаларын башкара. 2003-2004 елларда «Транснефтепродукт» җәмгыятендә вице-президент, 2005-2007 елларда «Ак Барс Торг» җәмгыятенең генераль директоры, 2007-2012 елларда «Хитон» ачык акционерлык җәмгыятенең җитәкчесе булып эшли, 2013 елдан кабат «Татспиртпром» оешмасына әйләнеп кайта. Спорт белән ныклап шөгыльләнә. Татар көрәше буенча спорт остасы! Бүгенге көндә әле Республикадагы ирекле көрәш федерациясенең әйдаманы, Мамадыш якташлар җәмгыятенең рәисе дә.

Икътисад фәннәре кандидаты Василий исә Җөридә, төп йортта кала, Аграфена апа белән Михаил ага – аның тәрбиясендә. Күмәк хуҗалыклар бетерелгәч, бизнеска кереп китә. Бүгенге көндә туган йортның утын сүндерми саклаучы, абый-сеңел-апаларын һәрдаим көтеп яшәүче, якты йөз белән каршы алучы да ул.

Зоя Михаил кызы, ун сыйныф белем алгач, 1981 елда үзләреннән ерак булмаган Нократ Аланы шәһәрендәге (Киров өлкәсе) механика техникумына укырга керә, 1984 елда тәмамлый. Озак еллар буе «Түбән Кама-Нефтехим» оешмасында көч түгә, 2008 елда Казанга күчеп «Хитон» заводында, аннары Усад спирт заводында эшли. Ире Борис белән ике бала – Валентин һәм Оксананы тәрбиялиләр.

Кече сеңелләре Любовь исә урта белемне Шәдче урта мәктәбендә ала, Түбән Кама шәһәрендәге 66 нчы һөнәри училищены тәмамлаганнан соң шин заводында эшли башлый. 2007 елдан Казанда яши, әүвәл «Хитон»да, 2013 елдан ипи заводында (архивта) хезмәт куя. Җәмәгате Григорий белән ике бала – Игорь белән Кристинаны үстерәләр.

Ата-ана өчен иң зур куанычларның берсе – бәйрәмнәрдә балаларның төп нигездә җыелуы. Читкә китеп бәхет, шөгыль тапканнарны, елына бер генә тапкыр булса да, Төнге Сабан туе, ягъни, икенче төрле әйткәндә Җыен – Питрау үзенә тартып кайтара, үзенә җыя...

Сәнгать фәннәре кандидаты Геннадий Макаров сүзләрен искә төшерик әле: *«Җыеннар уздыру – барлык төрки-кыпчак халыкларында борынгыдан килгән гадәт. Аны татарлар гына түгел, тугандаш карачай-балкарлар да, хакаслар да «Җыен» дип атый. Керәшеннәр исә, нәсара динен кабул иткәннән соң, зур авылларда чиркәүләрнең престол бәйрәмнәрен җыеннар белән бергә туры китереп уздыра башлаган. Бәйрәмгә барлык туганнар, күршеләр, туганлык җепләрен ныгытыр өчен ерак араларны якынайтып туган авылларына, ыру нигезләренә, бабаларының каберләренә зиярәт итәргә кайта. Җөри авылының Тырлау аланында үткәрелә торган Питрау бәйрәме дә керәшеннәр арасында борынгы заманнан сакланып килгән туганнар, ырулар очрашуы урынына әверелде».* Әлбәттә, район җитәкчесе Анатолий Петрович Иванов, Җөридә

Валерий Егоровның гаиләсе: Хатыны Римма ханым, кызлары Диана һәм Стелла

туып, Тәпи чишмәләренең шифалы суларын эчеп, Сәрдә, Кала тауларына күтәрелеп дөньяга караш ташлаган Иван, Валерий, Василий кебек егетләребез булмаса, Җөри җыены бу кадәр зәвык белән, мондый югарылыкта үткәрелә алмас иде...

Үзем шуларны уйлыйм, үзем «Бәрмәнчек» ансамбле җырлый торган «Нарасый бала» җырын күңелдән кичерәм:

Бергә чаклар, бергә чаклар
Бергә чаклар була бер генә.
Әй, нарасый бала!
Җөргән юлларың кала.

Сезне көттек – җаннар атып,
Сез килдегез микән җаратып?
Әй, нарасый бала,
Сез киткәчтен кем кала?

Тиздән – яңа, быелгы Питрау җыены җитә. Әфганстан сугышында афәтләр, үлем-китемгә шаһитлек кылып та, сынмыйча, рухи ныгып кына кайткан, бүгенге көндә сугыш ветераннарына, татар-керәшен оешмаларына, татар милләтенә, республикабыз җирлегендә яшәгән башка милләт вәкилләренә дә даими ярдәм күрсәтеп яшәгән могтәбәр егетебез – Иван Михаил улы Егоров барлык дусларын да кендек каны тамган туфракка, Җөригә – Питрауга кунакка җыячак! Туганнар, кардәшләр көндәлек эшләрдән аерылып, бер генә көнгә булса да, Җөри хозурына, якыннары, әти-әниләре, дуслары янына кайтачак. Ә ул төбәккә, әлбәттә, Җөри даругасы илтәчәк аларны! Хәерле юл сезгә, туганнар!

Әйдәгез, туганнар, җырлашыек,
Җырлап җәшәүләре күңелле!
Уйнап кына, көлеп, тату җөреп,
Уздыраек әле лә гомерне! ■

Иске Кулаткы районы башлыгы Эдуард Ганиев (уңнан дүртенче) – кунаклары белән

Илдән килгән кунакны Кабул иттең, Кулаткы!

VII Бөтенроссия авыл Сабан туе кысаларында Ульяновск дәүләт архивы хезмәткәрләре XIX-XX гасырда Сембер-Ульяновск төбәгендә яшәгән татарларга кагылышлы архив документларының күчермәләре белән халыкны таныштырды

4 июньдә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы эшчеләр бистәсендә VII Бөтенроссия авыл Сабан туе булды. Анда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, өлкә губернаторы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Сергей Морозов, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле ярдәмчесе Алексей Симонов, РФ Дәүләт Думасы депутаты Владислав Третьяк, һәм башка мөхтәрәм кунаклар катнашты. Төп чаралар «Гөлчәчәк» балалар бакчасында оештырылган Төбәкара балалар Сабан туе белән башланып китте.

Иске Кулаткы районының туган якны өйрәнү музее

Ак юл сиңа, «Мирас»ыбыз!

«Безнең мирас» журналы иң әүвәл «Мирас» (баш редакторы – Флүн Мусин), аннары «Чын мирас» (баш редакторы – Илфак Ибраһимов) исемнәре белән дөнья күрде. Басма тәүге адымнарын ясаган вакытта киң катлау укучылар игътибарына «Яңа чыга башлаган «Мирас» журналына сезнең нинди теләкләрегез һәм тәкъдимнәрегез булыр?» дигән сорау һәм шуңа олпат шәхесләребезнең әтрафлы җавапларын тәкъдим итте. Шул җавапларның кайберләрен кабат искә төшерик әле.



Әмирхан Еники:

– Ниһаять, безнең кулыбызда «Мирас»! Күптән кирәклеген сизә идек, күптән көтә идек. Мирасыбыз таркау, җыелмаган, каралмаган... Хәер, бөтенләй үк игътибар итмәдек, дип әйтә алмыйбыз. Мираска багышланган аерым хезмәтләр һаман чыга торды, шуларның иң зурысы – татар халык иҗатын җыйган томнар. Ләкин мирас ул тирән катлаулы байлык, аның күз төшмәгән, кул җитмәгән катламнары бик күп. Шул ук вакытта мирас ул һаман өстәлә бара торган байлык та. Әйтик, совет дәверендә чыккан нәрсәләр дә хәзер мираска әйләнде.

Менә шушы гасырлар дәвамында җыела килгән мирасыбызны күздән кичерү, онытылганнарын табу, тикшерү, ниһаять, дөньяга чыгара бару өчен, әлбәттә,

даими бер журналыбыз булырга тиеш иде. Мин монда кайсы дәвер, нинди мирасларга игътибарны юнәлтү кирәклегенә тукталып тормыйм. Барысы да кирәк, берсен дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Билгеле, «Мирас»ның эше күп тә, бик кызыклы да булачак. Һәм халкыбызның аң, белем, культура дәрәҗәсен күтәрүдә дә ул, һичшиксез, зур роль уйнаячак.

Беренче үрнәк саны да (тышлык рәсеме!) без белмәгән яңа табышлар белән бай һәм бик матур чыккан. Тарихын онытырга теләмәгән, кем икәнлеген тирәнрәк аңлыйсы килгән һәр татар кешесе рухи байлыгыбызның көзгесе булган бу журналны тизрәк кулына «төшерергә» ашыгыр, дип ышанасы килә.

Озын, ак юл сиңа, «Мирас»ыбыз!



Мөхәммәт Мәһдиев:

– Француз язучысы Гюстав Флоберның «Хакыйкать лексиконы» исемле сүзлегендә ат турында болай диелә: «Ат, әгәр дә үзендә күпме көч барын белсә, үзен йөгәнләргә, йөгәндә йөртергә мөмкинлек бирмәс иде».

Татар халкы да шулай – үзенең тарихында күпме этик, эстетик, әхлакый байлык тупланганын белмичә гасырлар кичерә. Бу байлыкны оныттырыр өчен империячел сәясәт, большевизм идеологиясе байтак көч сарыф итте. «Мирас» журналының битләрендә мин әнә шул күмелеп яткан байлыгыбызның дөнья күрүен теләр идем. Болар: «Гасрел сәгадәт» (Шәһер Шәрәф әсәре), «Кыйссасел әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы» – Якуб Хәлили варианты), «Музыка вә ислам» (Һади Килдебәки), «Тормыш һәм дин» (авторы Шам әдибе Рәфикъ әл-Әгъзам, Казанда 1911 елда Закир Кадыйри тәрҗемәсендә чыккан), «Ислам философлары» (Мөхәммәд Габдеһү, Җамалетдин Әфгани һ. б. турында) 1905 елда Троицк шәһәрендә басылган.

«Мирас» журналының редакциясендә гарәп графикасыннан күчереп басучы машинистка штаты булырга тиеш. Югарыда телгә алынган китапларның берничәсенә мин махсус редактор була алыр идем. Кайберләренә сүз башы да язар идем.

Үткәннән хәбәр

«МИРАС» ЖУРНАЛЫ БӘЙРӘМЕ

1991 елның 30 сентябрендә Казан шәһәренең Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында «Мирас» журналының башлангыч саны чыгуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Бәйрәмдә Татарстан ССР вице-президенты Василий Лихачев, ТССР халык депутатлары Фәндәс Сафиуллин һәм Марат Мөлеков, профессор Миркасыйм Госманов, шагыйрь Әхмәт Рәшитов һәм башкалар чыгыш ясады.

«Мирас», №1, 1992 ел

عائله درسلری

Гаилә дәресләре

Фәхрелбәнат Сөләймания

ЧАМАЛАП ТОТМАК

Бер ханым өйнең идарәсендә исраф кылучы булса, ирен шатландырмаганы кеби, билегеле, үзе дә тарлыкка төшеп мәшәкать чигәр. Ир исраф кылучан булганда да хатын аны яхшы тота белергә үгрәтмәк, ашамлыкларны вә башка нәрсәләрне чамалап тотмак, нәрсә куела торган чоланны бикләп тотмак лязимдер. «Бик анасы егламас!» – диярләр.

Ирләренең акчаны никадәр мәшәкатьләр берлә тапканын уйлаган, исрафның хәрәм вә зарарлы булганын белгән ханымнар өй эчендәге нәрсәләрне чамалап тотарга карарлар.

Дөнья бу! Кайвакытта ирләрнең акчасы аз булыр да, ханымнарның сораган нәрсәләре алынмас. Бу вакытта ханымнар ачу-кычу чыгармый, чыдамлыкны кулга алып, сабырлы булырга тиеш. Берәүгә дә, икәүгә дә хәленнән яки иренең ярлылыгыннан зарланмак яки шуларны алмый калма, диеп ирен борчымак бик зур гаептер. Өйдә булган һәр эшкә түзәргә, гаиләгә караган мәсьәләләрдән читтә һичбер тын чыгармаска тиештер. Хәтта ирләренең дөнья тарлыгы өчен уйланганын күргән вакытта да, дөньяда һәрнәрсәнең башы салык булганын, тирән уйларның зарарларын, кулда бары берлә генә вакытны үткәрмәк мөмкин булганлыгын сөйләп, аларны юатмак, кайгыларын бетерергә тырышмак кирәк. Күркәм холык, яхшы тәрбия иясе булган ханымнар, юрганнарына күрә аяк сузмак, вакытына күрә икмәк, катык берлә дә көнне авыштырмак юлын бик яхшы белерләр. Мондый ханымнар бернәрсәдә кечкенә генә сүтек йә ертык күренү берлә ташламаслар, бәлки яхшылап ямап куярлар. Бер-ике көн кигән оекны тишелгән, дип чыгарып ташлауның исраф идекен бик ачык белгәннәреннән, аны тизрәк ямарга карарлар.

Ир мөсриф *(әрәм-шәрәм итүче)* вә эчкече яки отыш уены уйнаучы булса, аны бу эшләрен ташлатырлык рәвештә тәдбирләр кылырга тиештер. Юкса, ханым да усаллыкны алдына алып: «Әйдә, ул гүләйт иткәнне, мин дә итим!» – дип әйтсә, ахырында һәр икесе вә бөтен өй халкы харап булырлар.

ТУЙЛАР

Исрафның никадәр зарарлы вә чамалап тотуның ни дәрәҗәдә файдалы булганын уйлаганнар һич файдасыз күп мәшәкатьләргә сәбәп булган туйлардан саклану лязим идекен бик ачык белерләр. Баласын сөннәт иттерәчәк

---
* Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында.


اوتنه در لطف وكرم ايدوب
نكاح مجلسنه تشريف قدم بيورماقڭزنى كون
نچه ساعتده كيچكمايچه اما ساعت تولغانده نكاح اوقلوب دسترخانه
نعمت قويلور نچى سنه ١٩ ده
مطبعهٔ كريميه قزانده

Туйлар, никах мәҗлесенә чакыру кәгазе. XX йөз башы

яки өйләндерәчәк, йә кызларын кияүгә бирәчәк адәмнәрдән сый күрмәк хыялы берлә туйлар ясалганы вә моның өчен дә бер кирәкмәс расходларга дучар булганы һәр җирдә күренмәктәдер. Сый дигән булып, күп акчалар тотып, күп кешеләрне хозурландырмак бер гакыллының эше түгелдер.

Туй ясар өчен мәгыйшәт кылырга кирәкле булган бакчасын, игенлек җирен, кибетен сатканнарга вә бу эш өчен бурычка батканнарга чын күңелдән кайгырылыр. Һәм дә өенең җиһазлары була торып, туй сылтавы берлә артык расходлар тотып яңа җиһазлар алмак акчаны суга ташламак димәктер.

«Фәлән кеше туенда шулай эшләгән иде, без нишләп аннан калышыйк!» – дип тырышулар вә файдасыз уздырышлар гакыллы кешенең эше түгелдер.

Туйларда эчке эчү бәласеннән никадәр кызганыч вакыйгалар чыкканы һәркемнең мәгълүме булып, моннан сакланмак һәркемгә лязимдер. Бу начар эш мөселман туйларына килешә торган эш түгелдер. Туйга чакырылган адәмнәрне беркадәр расходларга дучар кылган туй бүләкләре дә һич тиешсез артык эшләрдер. Угылларыгызны сөннәткә биргән яки кызларыгызны кияүгә биргән вакытыгызда, хәлегез җитәрлек булса, кардәшләрегез вә дусларыгыз, вә мелла-мөәзин, вә фәкыйрьләрне чакырып аш ашатмак вә бер мәүлид шәриф укытмак, фәкыйрь адәмгә бер ширбәт ягъни бал суы берлә генә мәүлид шәриф укыту берлә әҗер вә савап алмак, бер изге эш кылмак җитәдер. Сөннәт[1] булган кыз бирү вә ир баланы сөннәткә бирүнең шәрәфе ясала торган зур туйларда түгел, аларның диянәт даирәсендә чама берлә эш кылып күркәм сурәттә булуында вә гаилә өчен һәрвакыт бәхет вә сәгадәтне тудыруындадыр.

КАЕНАНА ВӘ КИЛЕН

Каенана дип әйтелгәндә киленнәрнең, киленнәр дип сүз чыкканда каенаналарның йөзләрендә бер салкынлык әсәре, кызгангыч ки, һәр өйдә күренмәктәдер. Каенанасыннан мәмнүн *(канәгать)* килен яки киленнән разый булган каенаналар бик сирәктер. Бу ярамаган хәлләр, һичшөбһәсез, тәрбия кимлегеннән, наданлыктан туган бер нәрсәдер. Тәрбияле үскән бер ханым-кыз каенанасын олуглап, аңа хөрмәт берлә эш кылуны, каенана да киленен сөюне вә яхшы тотуны белер. «Килен берлә каенана бер казанда

[1] Бу очракта Мөхәммәт пәйгамбәр күрсәтмәләре нигезендә үтәлә торган йола мәгънәсендә.

кайнамас», – дигән сүзләр тәрбиясез хатыннарның дошманлыклары берлә сөйләгән буш сүзләреннән башка бернәрсә дә түгелдер.

Кияүгә барган кызлар бер мәртәбә уйлап карарга тиешледер ки, каенана дигән кеше рәфикъ хәятенең *(ире, тормыш иптәшенең)* анасыдыр. Ире әфәндесе аның тәненнән аерылган бер кисәктер. Бу хатын ул ирне дөньяга китермәгән булса иде, бу яхшы ирне таба алмас иде. Ул хатын аны теләмәгән булса иде, аны угылына алмас иде.

Хатыннар өчен иргә хөрмәт кылмак ничек бер дини эш булса, ирнең анасына вә якыннарына да тәгъзыйм *(хөрмәт)* вә ригаять *(кайгырту)* кылмак шулай ук бер бурычтыр. Каен аналы ханымнар белергә тиештер ки, өйнең иң зур ханымы – каенанасыдыр.

Киленнәр ирләреннән никадәр мәхәббәт әсәре күрсәләр дә, бу тугрыда азгынлык күрсәтеп, үзләрен бик зурга санап, өйгә үзләре хуҗа булып, хөкем кылмакчы булмасыннар, чөнки килен берлә каенана арасындагы тавышлар моның кеби эшләрдән башланыр.

Яшь зурлыгына, гаилә арасында гына түгел, һәр җирдә ригаять *(игътибар)* кылмак важибтер. Килен дә ханымдыр, ләкин ханымлыгын каенанасына вә аның якыннарына хөрмәт кылмак берлә күрсәтмәк лязимдер. Каенана өйнең эшләрен идарә кылучының иң зурыдыр.

Килен бүлмәсен, әрле-бирле нәрсәләрен пычрак тотса вә балаларын яхшы тәрбия итмәсә, ханымлылыкка килешерлек эшләр кылмаса, каенананың нәзакәт берлә аны өйрәтергә, үзенә тиеш булган эшләрен эшләргә кушарга, әлбәттә, хакы бардыр.

Бер каенананың, никадәр чая да булсын, усал да булсын, әгәр килене үзенә итагатьле булып, кадер-хөрмәт итсә, килешсез вә тиешсез эшләр эшләмәсә, килененә каршы сөйләргә сүзен таба алмас. Хаксыз була торып сөйләсә дә, килен аның яшенә, олуглыгына хөрмәт итәргә тиеш, иренең анасы булганын уйлап, җавап кайтармый сабыр итеп, аңа каршы йомшаклык берлә эш кылмак лязимдер. Юкса бөтен көн буена хаклы-хаксыз кычкырышуларда булмак вә иренә әләкләп зарланулар берлә ирне дә өзмәк, гаилә арасында тынычлык бетеп, салкынлык вә аерылышулар булуына сәбәпләр ясамак, бичара ананы ахыр гомерендә пәришан *(харап)* итмәк – бик зур тәрбиясезлек вә бик начар эш вә Хода каршында мәзмүм *(начар)* булган хәлләрдәндер.

Каенаналарга да артык зураюларны куеп, бу эштә тугрылыклы, мәхәббәтле вә җитди кыланып, киленнәрен татлы тел берлә яхшы идарә кылырга көчләрен сарыф кылмак лязимдер.

Килен – каенананың мәгънәви кызы, каенана да аның икенче анасы димәк булганнан, бер ананың кызына вә бер кызның анасына карашы ничек булса, болар арасындагы мөгамәләләр дә шулай яхшы йөрергә тиештер.

Килен каенанасының өйрәткән эшләренә ачуланмый рәхмәт әйтергә тиештер. Каенана да килененең бәндәлек сәбәпле бәгъзе бераз гына килешмәгән эшләрен күргән вакытта күрмәгәнгә салынып торырга, кимчелекләрен дә хәерхаһлык берлә төзәтергә тырышмак лязимдер.

Ике ягы да яхшы тәрбия күргән адәмнәрдән җыелган гаиләләрдә килен-каенана низаглары баш күтәрмәс. Тәрбиясезләрнең ярамаган эшләренә иярмәгез, каенсеңелләрегезне үз сеңелләрегез, каенаналарыгызны үз анагыз кеби сөегез, аларга тәмам хөрмәт вә ригаядә булып, хәер-догаларын алыгыз.

КҮРШЕЛӘРГӘ БАРУ ВӘ СӘЙРАННАР

Ханым-кызлар күршеләр арасында йөрешергә вә утырышырга яраклы гыйффәтле вә тәрбияле ханымнарны

ара-тирә барып хәлләрен беләләр вә зур яшьлеләренең кулларын үбеп, хәердогаларын алалар. Бер адәмнең холык вә гадәтләренең дәрәҗәсе йөрешә вә күрешә торган дусларының гадәт вә сыйфатларына карап беленер. Ошбу дөньяда яхшылар берлә дус вә иптәш булудан һичкем зарар күргәне юктыр. Әмма явыз холыклы вә начар кешеләр берлә йөрешелсә, ахырында бер зарар күрелми калмас.

Ханымнарга иң әүвәл үзләренә йөрешер өчен яхшы күрше сайларга кирәк. Шөбһәсез, яхшы дуслар вафасыз *(бурычны үтәмәүче)* карендәшләрдән әллә ничә өлеш артыклардыр. Иптәшләр һәрвакытта намус вә гыйффәт иясе, гакыллы, тәрбияле, эшлекле, күркәм холык иясе, үзен вә сүзен белүче вә халык каршында сүи зан *(начар уй)* казанмаган, яман исем күтәрмәгән такымнан булмак тиештер. Моны ничек белә алырбыз? Һәркемнең кем идекен тикшерү вә сорашу, сынау, ишетелгән сүзләр, аеруча ышанычлы җирләрдән таралган хәбәрләр бик ачык күрсәтер. Фәлән фәкыйрьдер, дуслыкка лаек түгел, менә монысы байдыр, хөрмәт кылырга лаектыр, дисәгез, зур хаксызлыкта булырсыз. Чөнки фазыйләт *(өстенлек)* байлыкта түгел, күркәм холыкларда вә вөҗдан пакьлегендәдер. Фәкыйрьлек вә мохтаҗлык фазыйләтне бетермәгән кеби, байлык та һичбер вакытта фазыйләтләрне арттыра алмас.

Ханымнарның артык биләмгә йөрүеннән төзеклеге җуелган, ир берлә хатын арасындагы мөхәббәт суынган, бу сәбәптән аерылышу фәлякәтенә *(фаҗигасенә)* очраган гаиләләр бик күптер.

ХАТЫННАР ӨЙДӘ УТЫРЫРГА МӘХКҮМНӘРМЕ?

Кызлар, хатыннар өйдә утырырга мәхкүмнәрмедер *(дучар ителгәнме)*? Юк! Алар да адәмнәр. Алар да күршекыланга барырлар. Һәр ханым атаанасыннан яки зәүҗеннән *(иреннән)* рөхсәт алмый һичбер җиргә бармаска шәригать йөзенән мәҗбүрдер.

Кешегә барганда килешле киемнәр илә барырга кирәк. Өй иясе дә үзенә килгәннәрне шулай каршы алырга тиеш. Чуалган сачләр, кара өсләр берлә кунак каршы алмак, вә шул хәл берлә кешегә бармак гаеп булган эшләрдәндер. Ерактан кунак килсә, мөмкин булган кадәр тизрәк ашатмак, хөрмәт итмәк мосафирпәрварлеккә лаек эштер. Кешегә барган вакытта ул өйнең ир кешесе өйдә очраса, өйгә кереп аны рәхәтсез итмәк мәгъкуль түгелдер. Өй иясе берәр сәбәптән кайгылы булса да, кунакларына караңгы чырай күрсәтми, даими көләр, йөзе якты чырай берлә килгәннәргә бик хуш күргәнлек әсәре күрсәтмәк лязимдер. Бер зур мәҗбүрият күренмәгәндә кунакка балалар алып бармак мәгъкуль түгелдер.

Сәйраннарга килсәк, хатыннар да вакытында кыр вә бакчаларга чыгып һава, кояш алмага, күңел ачмага мохтаҗлардыр. Ләкин бу сәйраннарга чыкмак ата-ана, ир яки башкаларның рөхсәте берлә вә тәрбияле рәвештә булмак кирәк. Ханымнарга кирәк кадәрле әдәп берлә йөрергә вә ирләр җыела торган җирләргә бармаска кирәктер.

Ислам ханымнарының вокзал алларында, пароход пристаньнарында, гостиница вә харчевня алларында йөрүләре дин вә тәрбия йөзеннән һич дөрес булмый, тугры ислам хатыннарының хатынлык шанына да муафыйк түгелдер. Бер хатын, никадәр гүзәл булса да, ачык-сачык булды исә ирләрнең вә һәркемнең карамагында гаепле саналыр. Гыйффәт берлә тугры юлда йөргән ханымнарга һичкем кырын бакмас. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Бу очракта инде нигә хат язу,
Сиңа ышанмыйча, ничә хат язу?

«Миңа килеп китсен, – димен, –
бер көнгә».
Кунакка чакыру була, төбендә,

Күр, җибәрәм сине кунак дәшәргә,
Көчләмичә чакыр, берни яшермә,

Киләлмәсә соңда, барам мин үзем,
Күреп кайтам изге кешенең йөзен.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – Һәр теләк
Үтәлә, Алладан бирелсә терәк.

Ә мин исә тагын катгыйланамын,
Теләгеңне үтәр өчен янамын,

Исән-тыныч булсын илбик алтуны[1],
Ходай бирсен ул ни сораса, шуны.

Торып чыкты, атка атланды, кайтты.
Төшеп, өйгә керде, киемен атты.

Кызыл кояш үнде, сары төс алды,
Дөньяга ягылды, гүяки, алтын.

Кояш ал йөзенә сөртте зәгъфран,
Үзен мәйнә[2] кебек бизәде җиһан.

Аннары күк кызы кашкара сөртте,
Зәңги, хәбәш кебек булды җир өсте.

Үгделмеш ашады һәм кылды намаз,
Түшәк сорап алды, йоклады бераз.

Сары сандугач бер сайрап җибәрде –
Уянды Үгделмеш, йокы килмәде.

Төне бик озайды – йокысы качты,
Кайда соң бу көне, кая адашты?

Ертылды да төннең кара күлмәге,
Күренде якты йөз – таңның иңнәре.

Көлә бакты, үрләп, түгәрәк йөз-кыз,
Яктырдылар үрләр, аннары уй – кыр.

Торды, юынды һәм киенде, төгәл
Намаз укып, кылды эшкә иге фал.

Атын менде, бергә-бер углан булды,
Кардәшенә бик шат тотты ул юлны.

Җилеп, кардәш торган җиргә җитеште,
Ашыкмыйча гына атыннан төште.

Шакыды, тоткасын тотып, ишекне,
Заһид кардәш килеп чыкты, ишетеп.

Күзе белән сөзеп бу Үгделмешне,
Диде: – Кардәш, нигә сузасың эшне?

**Һәрбер эшнең була чиге – бүлҗәле,
Бу эшнең дә, тыңлап, чиген бел, яме.**

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

[1] Алтун – аңлашылмаган сүз, «алтын» дип әйтү контекстка ярамый. Бәлки ал тун «монархлар кия торган кием», күчерелмә мәгънәдә «таҗ»дыр.

[2] Мәйнә – Урта Азиядә (гомумән көньякта) очрый торган матур сары каурыйлы кош төре, «купшы сыерчык».

Ник үзеңне болай имгәтәсең син,
Ябешәсең миңа бу көнгәчә син?

Кер инде, сүзеңнең тик каймагын әйт,
Кабат йөреп, нигә килдең тагын, әйт.

Шулай өйгә керде бу ике кардәш,
Заһит кардәшенә бакты төеп каш.

Һәм Үгделмеш әйтте: – Сабыр, кадерлем,
Кашыңны җыерма, сөйлим хәзер мин.

Син әйткән сүзләрне, хәтердә бикләп,
Бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем илбиккә.

Ул игътибар илә тыңлады, аннан
Синең сүзләреңнән калды таң-хәйран.

«Теләсә нишләсен», – диде соңында.
«Тик бер теләгем бар», – диде шунда.

Мине сүзче итте илбик бу эштә,
Оятлама мине, белсәң, ничек тә.

Һәрбер эшнең була чиге – бүлҗәле,
Бу эшнең дә, тыңлап, чиген бел, яме.

Ни ди, ишет, әнә ушлы кешеләр
(Сүзләре һәрнинди эшкә тап килә):

Үз теләге белән юл йөргән кеше
Аруын оныта, уң булса эше.

«Вактыннан уздырмый, эшне башла син,
Уздырсаң, ул эштән ераклашсың,

Һәрнәрсәнең була заңы-вакыты,
Вакытында эшләү – иң-иң яхшысы».

Миңа куйды илбик соңгы таләбен:
«Чакыр, кунак итеп. Һәм син килә бел».

Үзеңә бер яки килер ул монда.
Йөзең күрсен, булыр күңле урнында.

Сиңа юк, кардәшем, моның зарары,
Ышан миңа, зинһар, бәгъре яралым.

Илбигебез бик тә яхшы хөкемдар,
Ярлы, бай – һәркемгә ул сөеп карар.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – Ошбу сүз
Хакыйкатькә якын, айә, күңле төз.

Мөселман кардәшне мөселман кардәш
Зиярәт кылыр ул, и, күңле кояш.

**«Җаны теләгәнгә ерак җир якын:
Теләп барып йөрү аклый үз хакын:**

Бу сүзгә күнәмен һәм баш иямен,
Зиярәт кылырга бүген киләмен.

Моннан элек шуңа бармаган идем –
Чакыру тик аңа файдага иде.

Хәзерле чакыру – эчкерсезлектән,
«Вафалыга вафа», дип, вәгъдә итәм.

Мин барыйм илбиккә, миңа килмәсен,
Миңа тисен имгәк, аңар тимәсен.

Илбик – ил бийе ул, халаекка бер,
Аңарга тиешле хөрмәт вә кадер.

Ул заң-канун төзи, әйтә тугры сүз,
Ул арулый илне, булсын, дип, чүпсез.

Ни ди, әнә белкә (белеме – диңгез,
Гыйлеме зур, холкы-күңеле идез[3]):

«Ригая итү һәр хаким хөкемен –
Күңелеңдә булсын олы-кеченең.

Хөрмәтләгез бийнең үзен һәм сүзен
Булса да ул һинди – бәясе бер тин».

Хәзер мин, хөрмәтләп бийнең ярлыгын,
Зиярәт кылырмын, булырмын якын.

Йөре, бийгә җиткер инде сүземне,
«Әйтте, диген, – тиздән киләм үзем», дип.

Дөнья үз йөзенә япкач пәрдәсен,
Барам, очрашырга җай әзерләсен.

Кеше көндез күрсә, мине гаепләр,
Аңар дошман кемсә сөйләр гайбәтләр.

Инде кит, бара тор, үз өеңдә көт,
Сиңа төшәм – ятма, бераз сабыр ит.

Иң элек мин сиңа барып керим дә,
Аннары карармын – кая йөрергә.

[3]Идез – изге күңелле һәм кодрәтле.

Сөенде Үгделмеш һәм әйтте җавап:
Афәрин, зиярәт кылу ул – савап.

Йөгерәмен инде, илбиккә шундук
Хәбәрлим «килә», дип, торсын шат булып.

Син исә юанма, нык тор сүзеңдә –
Әйтелгән вакытка җитеш үзең дә.

Икесе, ниһаять, бер сүзгә килгәч,
Чыгып китте егет, канәгать, көләч.

Ләкин тагын кайтты, әйтте: – И, кардәш,
Сүзеңдә тор инде, и, күңле кояш.

Әйткәнеңә көтәм – кичен, эңгердә
Җир өсләре охшап калгач күмергә.

Көтим сине туктал өем янында,
Хәзерлек күвереп торырмын шунда.

Атын менде, кайтты сәрай ягына,
Изен сорап керде илбик янына.

Житкерде илбиккә әйтелгәннәрне,
Илбик кашын язды – көлеп җибәрде.

Әйтте: – Бик тә әйбәт булды бу эшем,
Әгәр дөрес булса аның әйтмеше.

Һәм сорады: өйгә ул кайчан килер
Һәм ничек очрашыйк, әйт миңа, белдер.

Җаваплап, Үгделмеш әйтте: – Иртәгә,
Дөнья йөзен пәрдә япкан кичәдә,

Минем өйгә килмәк ниятендә ул,
Син әйткән вакытны гына көтәр ул.

Илбик әйтте: – Михнәт чиктең, йөгердең,
Савабын Тәңребез Үзе бирер бер.

Шушы инде минем дәртем дәвасы,
Канәгатьләндерден күңлем һәвәсен.

Син өйдә көт аны, килгәч, әйт безгә,
Кеше җибәрермен сезне дәшәргә.

Кардәшеңне алып безгә килерсең,
Ниһаять, заһитнең йөзен күрербез.

Акылдарлар бер сүз әйтә бу хакта
(Ә бит алар дөрес әйтә чынлап та):

«Кеше күңле һәрчак нәрсәдер тели,
Булсаң да бик тыйнак, сузыла теми[4].

Ләкин теләгенә төгәл ирешсә,
Күңелен тынычлый акыллы кемсә».

— Ярый, – дип, Үгделмеш өйдән чыкты да,
Йокларга юнәлде, китте йортына.

Җиргә җитеп йөзен яшерде кояш.
Томан, төн дөньяны каралтты тоташ.

Тол тунын[5] киде җир, кашын җимереп,
Күк йөзе каралды кара җен кебек.

Йөгергән-йөргәннең күзе йомылды.
Шау-шулар тукталды, дөнья шил булды.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҮГДЕЛМЕШ ӨЕНӘ КИЛҮЕ

Ашыкмыйча, юлдан Уйгырмыш килде.
Аны көтеп торган Үгделмеш күрде.

Сәламләште болар, кул алыштылар,
Өй эченә шуннан кереп шылдылар.

Кунакка Үгделмеш тәгам-аш бирде,
Илбиккә хәбәрче кеше җибәрде.

Тора иде илбик хәбәрне көтеп,
Чакыртты боларны якын дус итеп.

КӨНТУГДЫ ИЛБИКНЕҢ УЙГЫРМЫШ БЕЛӘН КҮРЕШҮЕ

Болар икәү китте илбик катына,
Күреп алды илбик, чыкты каршыга.

Кеше барса сөре-сөме коелып,
Якын аралар да ерак тоелыр».

Килгәннәргә ул үзе сәлам бирде,
Заһит тәкәллефләп «Галәйкүм», диде.

Илбик Заһиткә кул биреп күреште,
Сөенеп, язылып, икәү көлеште.

Тәклиф итте илбик янынннан урын,
Күрсәтте белгәнен заһит кадерен.

— И, Уйгырмыш, – диде, –
мәшәккать чиктең,
Җәяүләп бу җиргә син килеп җиттең.

УЙГЫРМЫШНЫҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Уйгырмыш әйтте: – И, дустым,
Мәшәккатьне, сине күргәч, оныттым.

Катыңа бик теләп, шат булып килгәч,
Мәшәккать хакында хәтерләү нигә?

Үз теләге белән юл йөргән кеше
Аруын оныта, уң булса эше.

Бөкәләр ябгусы[6] әнә, ни дигән
(Аның зирәклеген бар дөнья белгән):

«Җаны теләгәнгә ерак җир якын:
Теләп барып йөрү аклый үз хакын:

Ихлас булса теләк һәм тик тормаса,
Инсан максатына тиз якынлаша.

Кеше барса сөре-сөме коелып,
Якын аралар да ерак тоелыр».

Аягың сау булса, йөрү нәрсә ул?
Тәнгә канат бирер теләкле күңел.

Күңел теләп килдем сиңа, илбигем,
Нинди мәшәккать, ди, син биргәч билге.

Дәвамы бар ■

[4] Теми – начар теләк, омтылыш
[5] Тол туны – тол калган кешеләр киеп утыра торган кара толып, траур билгесе.
[6] Бөкә – «дворян», ябгу – «идарәче чиновник» (ул реаль идарәне башкара»
[7] Шәрр – «явыз ният, явыз уй, каст» (бу сүз дини стильдә татар телендә дә киң кулланыла).

«КҮП МӘСЬӘЛӘДӘ ФИКЕРЛӘРЕБЕЗ УРТАК»

(Туфан Миңнуллинның Гәрәй Рәхимгә хатлары)

Әй, узган гомерләр!.. Туфан Миңнуллинның миңа хатлар яза башлавына да 40 ел үткән. Үзе бер кеше гомере.

Узган гасырның 60-70 нче елларында без Туфан белән татар әдәбиятында үз урыныбызны табарга, үз оябызны корырга тотынган яшь язучылар идек. Шуннан гомеребез буе иҗади яктан бик нык аралашып, бер-беребез белән киңәшләшеп, шаярышып яшәдек. Аның миңа 1975 һәм 1977 елларда ук язган бу хатлары да шуның ачык мисалы булса кирәк.



Моннан 40 ел элек язылган бу хатларга бүген кыскача гына аңлатмалар бирүне кирәк таптым.

«Федотовка бүресенә сәлам» дип башланган хатны ул минем туган авылыма адреслаган. Эш шунда ки, мин авылдан 1962 елны ук чыгып китсәм дә һаман аңа тартылдым, аны сагындым. Һәм, ниһаять, инде шигырьләрем «Казан утлары» кебек олпат журналда һәм Татарстан китап нәшриятында аерым китаплар булып басыла башлагач, авыл тормышы турында зуррак бер цикл язарга дип бер елга авылга кайтып киттем. Анда мин «Авыл дәфтәреннән» дигән шигырьләр шәлкеме яздым, ул «Казан утлары»нда басылып чыкты. Бу циклны аеруча яратучы кеше – үзе дә гомере буе авыл турында шәп шигырьләр иҗат иткән өлкән шагыйребез Сибгат Хәким булды.

Мин әнә шулай, ялгыз әдәби бүре шикелле, авыл тормышын «иснәнеп» яшәгән чакта Туфанның шушы хаты килеп төште.

Ул анда миңа «Конверт» исемле шигырь дә җибәрүен яза, ләкин хатта ул шигырь юк иде. Хатта ул мине 23 январьда Казанга кайтуымны сорый. Мөгаен, аның бу көнне берәр театрда премьерасы булгандыр.

1975 елның 6 ноябрендәге икенче хатын ул Мәскәүдән Казанга язган. Бу елны алар шагыйрь Зөлфәт белән СССР Язучылар Союзының Әдәбият институты каршында эшләп килүче икееллык Югары әдәби курсларда (ВЛК) укыйлар иде.

1977 елның 11 февралендә Мәскәүдән Казанга язган хатында аның «Әлдермештән Әлмәндәр» дигән әсәре турында сүз бара. Казанда чакта ул миңа бу әсәрнең яңа гына язылып беткән нөсхәсен укыган иде. Миңа әсәр бик ошады һәм мин аны ниндидер драматургик нигезләүләр белән Туфанның үзенә шәрехләп маташтым. Аннары бу фикерләремне хатка язып, аңа Мәскәүгә юлладым. Аның минем турыда «фәнни мактау», «сиңа драматургия фәннәре докторы дигән исем чәпәп куярга ярый» дип шаяртуы әнә шул сөйләшү һәм хатка ишарә.

Туфанның бу хаты килгәндә мин бик озак Биектау районының урман эчендәге «Каменка» дигән шифаханәсендә бик әшәке үпкә авыруын дәвалап яттым. Бер ел буе диярлек мин үпкәдән кан килеп азапландым. Табиблар аны туктата алмадылар һәм миңа Кырымдагы атаклы Алупка каласындагы шахтерлар санаториена юллама бирделәр. Ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, атаклы очучы Әмәтхан Солтанның туган җире бу. Анда батыр очучының бюсты куелган. Мин Алупкага килгән язучылар белән ул һәйкәлгә чәчәкләр куюны оештыра идем.

Әмма бу санаторийда да минем үпкәдән кан килүне туктата алмадылар. Кырымның башкаласы Ялта шәһәре читендә әле революциягә кадәр үк атаклы рус язучысы, үзе дә үпкә авырулы Антон Павлович Чехов үпкә чирләреннән дәвалаучы санаторий төзи. Монда инде үпкә хирургиясе буенча да белгечләр эшли. Мине шул Чехов исемендәге санаторий хирургларына күрсәттеләр һәм яшь кенә бер грек табибы миңа операция ясап, үпкәнең кан килә торган урынын кисеп ташларга тәкъдим итте. Инде ике еллап кан түкерү белән газаплангач, миңа риза булмыйча мөмкин түгел иде.

Туфан Миңнуллин, Илһам Шакиров һәм Гәрәй Рәхим. 90 нчы еллар

Операция бик уңышлы чыкты һәм, Аллага шөкер, мин бу авырудан бөтенләй котылдым.

Операциядән соң яңадан Алупкага, шахтерлар санаториена кайттым һәм анда «Саргаймагыз, каштаннар» дигән икенче повестемны яздым.

Татарстан Язучылар берлегендә миңа катлаулы операция ясалганны белгәннәр һәм, рухи ярдәм йөзеннән, мин яткан санаторийга каләмдәшләрем Равил Фәйзуллин һәм Рөстәм Мингалимовны командировкага җибәргәннәр. Рәхмәт Язучылар союзына, рәхмәт Равил белән Рөстәмгә – аларның махсус минем янга килүләре күңелне һәм иҗади дәртемне бермә-бер күтәреп җибәрде.

Туфан Миңнуллин хатларында Алупка шәһәрен, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин һәм Рөстәм Мингалимовны әнә шул вакыйгаларга нигезләнеп искә ала.

Мин монда Туфан хатларындагы гаять халыкчан, хәтта авылча татар теленә, Туфанның тышкы яктан гади, эчке яктан тирән юморына, авыл кешесенә хас фәлсәфилегенә, гаять эчкерсез һәм ялгансыз булуына, мине якын дусты итеп күрүенә чиксез соклануымны һәм горурлануымны әйтеп китәсем килә. «Күп мәсьәләләрдә безнең фикеребез уртак», – ди бит ул бер хатында.

Әнә шул хисләр мине Туфан хатларын әдәбият сөючеләргә тәкъдим итәргә этәрде.

Гәрәй Рәхим

ФЕДОТОВКА БҮРЕСЕНӘ СӘЛАМ!

Сагынган икән дә, сагынуына түзә алмый хат язган, дип уйлама. Исемдә, уемда да юк идең. Үзең хат язып та каткан күңелләрне эретә алмадың. Җавап хаты алмавыңнан сизенгәнсеңдер. Җир тишегенә китмәгән, Яңа елга кайтыр әле, нихәл, дип әйтермен, шул җитәр, дидем. Молодец, егетлек эшләдең – кайтмадың – алдадың.

Нигә язасың соң алайса, дисеңме? Тәк кенә. Эш юктан. Дөресрәге, бүтән рәтле эшкә ярамаганлыктан. Ике көн инде түшәк өстендә ятам – борыннан, күзләрдән ага. Кызганучы кеше юк. Беренче көнне өмет белән яттым: хәзер, мин әйтәм, звонок бирерләр, унлап-егермеләп өелешеп керерләр дә, нишләп ятасың инде, синнән башка дөнья әйләнми, дип әйтерләр төсле тоелган иде. Тот капчыгың, дөнья әйләнә икән ич. Миннән башка да... синнән башка да. Менә шунда сине дә үз хәлемдә күреп, кызганып куйдым. Кар-буран, ята инде бу, мин әйтәм: «Кайт! Сагындык!» – дип әйтүләрен көтеп. Тот капчыгың, дөнья әйләнә. Кем белә, бәлки кызгануым урынсыздыр, дөньяны син берүзең әйләндереп ятасыңдыр. Әгәр алай булса, ошбу хатны алмадым, дип уйла. Мин язмадым, дип әйтә алмыйм – конверт сатып алган биш тиенне кайсы статья буенча списать итим? Яңалыклар әйтә хәзер, дип өметләнмә, юк, яңалыклар, булса да әйтмәс идем. Чөнки һәр бәләкәй генә яңалык та тансык – берәүгә дә әйтмичә үзең генә кадерен beläse, кочаклап ятасы килә. Искене яңалык дип кабул итеп, ахмакларча куанырга гына кала. Күрәсең, авыру кешенең фантазиясе дә чирле, зәгыйфь.

Син анда шедеврлар гына иҗат итеп ятасыңдыр инде. Кайткач, түш киереп мактанып йөрерсең инде. Җенем сөйми мактанчыкларны. Ничава, кайт әле, кем икәнлегеңне күрсәтербез. Сезнең авыл урманында агачлар булса, безнең авыл урамында да күсәкләр бетмәгән.

Минем хәлләрне беләсең килеп, эчең яна инде синең, әйеме? Ха-ха! Тагын бер тапкыр ха-ха. Әйтмим. Бик беләсең килсә, 23ендә Казанга кайт. Акчаң булмаса, сорап яз, хәерче, миндә дә юк, дип телеграмма сугармын. Кайтсаң, кыстыра кайт, безгә өметләнмә, бер грамм юк.

Шигырь:

Йөз илле грамм суктым,
Дип, телеграмм суктым.

Уф, Алла! Үлсәм үләм, иртәгә эшкә барам. Тилерүем шушыдыр, тик торганнан ике бит нәрсә язып ташладым. Ә миңа ярамый, беләсеңме, ярамый! Авыру мин, чирле. Мин урын өстендә генә ятарга тиеш. Рәхмәт инде, әле дә син бар икән. Юкса, хат язарлык та кеше калмаган. Җутко. Биш тиен түләп алган конвертыңның кирәк булмавы да ихтимал икән ләбаса. Яз! Сиңа шигырь бу!

Конверт

(дип атала)

Ярый, җитте, булды. Исән-сау яшә. Эч пошып ятканда искә төшүең өчен рәхмәт. Иң якын кешеләреңә күп итеп сәлам әйт. Мине күреп белмәсәләр дә, әйт.

Туфан.

СӘЛАМ, ГӘРӘЙ РӘХИМ!

Сәлам, Флера!*

Сәлам, әлбәттә, кызыгызга! Төнге сәгать өч. «Өй түрендә җил җылый». Йокысызлыктан интегеп торып утырдым – «Әлдермештән Әлмәндәр»не язып бетерергә кирәк. Ләкин разгон алып китеп булмый. Разминка ясар өчен сиңа хат язам. Ни өчен сиңа – үзем дә аңламыйм.

Бәлки мине аздырып, төнге сәгать өчләр җиткәнче карта уйнатуың өчендер. Бәлки... Кем белә. Ни генә булса да, ямьсез сабакы, бу хатның кадерен бел, бер генә адәмнең дә төн утырып сиңа хат язганы булмагандыр.

Иң кызыгы шунда – язар сүзем юк. Сине эт итеп сүгеп бәхәсләшер идем. Күп мәсьәләләрдә безнең фикерләребез уртак. Шатлыкларымны сөйләр идем, авыз тутырып сөйләрлек шатлыкларым юк, Аллага шөкер. Хәсрәт-кайгыларымны искә төшерәсем дә килми. Яңалыклар? Юк. Утырам, тартам, укыйм, ятам.

Мәскәү урталарында. Ямансу. Кичә

*Флера – Г.Рәхимнең беренче хатыны

бер ярты (исереп китә күрмә) алып кайткан идем, эчешергә кеше таба алмадым. Башланмаган килеш тора. Шул уңай белән әллә берәр шигырь язып ташларга? Сабыр ит, сигарет кабызып коридорга чыгам (бүлмәдә тартмыйм), шунда оештырып керермен. (Вакыт әрәм китә китүен, черт с ним.) Булды. Шкафымда җылап тора сыңар ярты:

– Алгач, кирәк иде эчәргә...
Бер ялгызың эчү эчүмени –
Эчкәч, кемгә серең чишәргә?
Җыр башласам, кем кушылып җырлар?
Көләм, дисәм, кемнәр көлешер?..
Бер артыны уртаклашыр кешеләр юк,
Кайгы килсә, кемнәр бүлешер?

Ритм аксый бугай аксавын, редакцияләргә вакытым юк. Эт сигәнче шундый шигырь язгач, ярамаган тагы.

Үзегез нихәлләрдә яшисез? Тавыгыгыз, чебешегез өерелеп эчәсезме? Алкоголики несчастные, миннән качып... Тфү, ачуны чыгардыгыз, хатны да язып бетерәсе килми. Әйбәт булды әле, барыбер язарлык сүзем юк иде.

Бәйрәм белән котламаган да димә. Бу хат барып җиткәндә бәйрәм узган була. Ярый, күңелегез булсын, узган бәйрәм белән котлыйм.

Әгәр инде бик әрсезләнеп: «Мәскәүгә барып чыксам, теге яртыны эчеп китәм», дисәң, мә, матьти ети, ал адресны.

127254. Москва, И-254, ул. Добролюбова, д. 9/11, ком.212.

«Новослободская» метросыннан чыккач, 3 троллейбуска утырып «2-Гончаровский переулок»та төшәсең. Кире якка утырып китә күрмә, надан.

Еще раз с приветом,
Туфан Абдуллович.
6/XI-75.

СӘЛАМ, ГӘРӘЙША!

Хатыңны алдым бит, әй. Укып рәхәтләндем. Нинди ахмак сүз ул? Имештер, мин мактауны яратмыйм. Кем мактый бит. Дуслар мактаганны үлеп яратам. Бигрәк тә синеңчә итеп (фәнни мактау). Моның өчен сиңа драматургия фәннәре докторы дигән исем дә чәпәп куярга ярый. Трактат язгансың ич.

Менә Мәскәүгә килеп яши башладык. Ике көн лекцияләр тыңладык. Белем арта. Элек начар язучы идек, уртакул язучыга әйләндек. Тагын икееллык курс үтсәк, бәлки, яхшы булырбыз. Кызганыч, бу курсларны моннан унбиш еллар элек үтмәгәнмен, язам, дип кулга каләм алмаган булыр идем, бухгалтер булып тыныч кына көн күргән булыр идем. Укыган саен юк эш белән шөгыльләнгәнем ачыклана бара. Ә син мактыйсың.

Авыр көннәр, кичерәм: язмыйча да мөмкин түгел, язарга да оят (кыланмыйча әйтәм). Бүген Толстой һәм аның философиясе турында сөйләделәр. Язучының философиясе! Кайда ул безнең философия? Стенография.

Авыр көннәр дигәч тә зарлана, дип уйлама. Зарланмыйм. Укыганлыгымны күрсәтер өчен генә язам. Менә син курста укымагач, мондый нечкәлекләрне белмисең, аңламыйсың. Сиңа рәхәт. Матур кызлар күрсәң: «Чукынган кыз бигрәк матур», дисең. Без «Сөбханалла», – дип гарәпчә сокланабыз.

Казанда яңалыклар күрмәдем, искелек шул элеккечә. Ел йомгакларына калмадым. Әллә нигә каласым килмәде. Каласым килмәгәнгә әллә үзем, әллә ел йомгаклары гаепле – тәгаен өзеп әйтә алмыйм. Атта да бардыр, тәртәдә дә бардыр. Һаман бер үк сүзне күпме тыңлап була да, күпме сөйләп була. Минем бер пьесада әйтелгәнчә: «Үләргә хөкем ителгән кешенең сукыр эчәгесен кисеп маташабыз». 150 кеше язганны бер М. Мусин сызып ташларлык булгач, нинди әдәбият ди инде ул.

Карале, ни булды миңа? Зарланмыйм, дип җөмләмне көлеп башлыйм да сүгенеп, нокта куям икән ич. Бүлмәм салкын, әллә шул тәэсир итә микән? Шулдыр, каһәр төшкересе. Көздән тәрәзәләрне карамасаң, шулай була икән. Зөлфәтнең әле килеп җиткәне юк.

Планнар: бүлмә җылына башлагач,

нәрсә дә булса язуымны дәвам итәргә туры килер. Яки повесть, яки пьеса. Казанда яңа пьеса башлаган идем. «Ай булмаса, йолдыз бар» дип исем кушкан идем.

Менә шул. Апрель башларына кайтасыңмыни? Кайт инде әйдә. Булмә зур. Йокларсың. Йоклаганны йоклатыш замана.

Тфү! Тагын ни язып куйдым.

Ярый, дус. Давай, исән-сау бул. Безгә шунысы бик кирәк.

Сәламәтлек, уңышлар теләп,
Миңнуллин.
11/II 77.

ГӘРӘЙБӘК!

Син соңгарып язгансың, мин соңгарып язам. Син Алупкага күчкәнсең, мин Мурманск дигән калада йөреп кайттым. «Әлдермештән Әлмәндәр»не русчага күчереп куйганнар. Күрдеңме, абзаң нишли. Өлкән туганнарыбызны ничек яшәргә өйрәтә түгелме? Шулай ул, кадеремне генә белмисең: яланаякка үкчәсе тапталган ботинка киеп, тишек ыштаннарыгыз белән дачадагы өемә килеп керәсез – хөрмәт юк, ихтирам юк. Котыртып эчерәсез – оятыгыз юк. Хәзер бетте, дачама кайткач, сезнең ише шантрапа белән сөйләшмәячәкмен дә. Хәер, синең белән сөйләшәм икән, гәҗиттә шигырең чыкты бит синең дә. Бәхетең бар икән.

Казаннан хәбәрләр килеп тора. Яхшысы да, яманы да. Яхшысына сөенмим, яманына көенмим. Калын тирелегә әйләндем. Картайдым. Картлык турында шигырьләр язарга керештем.

Оча яфрак, сары яфрак – җиткән көзләр,
Китә казлар, киек казлар язлар эзләп.
Язлар эзләп киталмый тик талган йөрәк
Киләчәккә ара ерак, ара ерак.

Үтәр көзләр, китәр кышлар, килер язлар,
Кайтыр казлар урап-урап, киек казлар.
Кайталмый тик язларына янган йөрәк,
Үткәннәргә ара ерак, ара ерак.

Күрдеңме? Уфада куелган «Үзебез сайлаган язмыш»ка җыр тексты кирәк, диделәр дә эт сигәнче язып бирдем. Ә менә монысын бик озак уйланып яздым, шуңа күрә гениально булып чыкты.

КАРТЛАР ҖЫРЫ

Нәрсәмә, ниемә миңа ул
Мактаулар, котлаулар, бүләкләр?
Аһ булып күренә күземә
Таушалган, ауналган йөрәкләр.

Кирәктер, бәлки бик кирәктер
Бүләкләр, котлаулар, мактаулар.
«Кыж», диеп сөйләнә-сөйләнә
Карчыкка тотынып атлаулар.

Кирәкми, кирәкми, кирәкми
Мактаулар, бүләкләр, котлаулар.
Айгырлар күргән төш күреп тә
Алаша йокысын йоклаулар.

Менә шулай була ул шигырь, агай-эне. Тик, зинһар, син минем шигыремә җавап итеп пьеса язып җибәрә күрмә. Мин сине кызганмасам да, син мине кызган. Яныңа Равил белән Рөстәм бармакчы имеш, дип ишеткән идем, килделәрме? Туйганчы ләкәтә саткансыздыр инде. Без, үзең әйтмешли, дачада гайбәт сатышырбыз инде.

Давай, шуның белән хатка нокта куйыйм. Бер син генә түгел дөньяда, хатынга да хат язасым бар.

Сәламәтлек телим, сәлам белән,
Миңнуллин.
20 март 1977.

РЕДАКЦИЯДӘН: **Күренекле шагыйрь, журналыбызның актив авторы, җәмәгать эшлеклесе Гәрәй РӘХИМГӘ (Григорий Васильевич РОДИОНОВ) 15 июльдә – 75 яшь! Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек,иҗади уңышлар телибез.** ■

Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттахның вафатына 12 елдан артык вакыт узды. Ләкин аның архивында моңа кадәр беркайда да басылмаган кульъязмалар табыла тора. Кайберләре (рецензия, мәкалә, фикер алышулар) тәмамланган. Икенче берләре башланган да, ташланган – әллә дәвам итүне кирәк санамаган, әллә кичектермәслек башка эшләре булган...
Авторның ул чордагы уй-фикерләре, каләмдәшләре һәм башка шәхесләр белән мөнәсәбәтләре укучыларда кызыксыну уятыр мөгаен. Шуңа күрә түбәндәге язманы укучылар хөкеменә тапшырырга булдым.

Руфина Фәттахова

Махатма Еники һәм Батыев

Нурихан Фәттах

Миргазыян Юнысның «Татарстан яшьләре» (18 октябрь, 1997 ел) газетасында «Махатма Еники» дип аталган мәкаләсе басылып чыкты. Әмирхан Еники – Махатма Ганди, татарның милли хәрәкәт җитәкчесе. Әмирхан абыйны белмәгән берәр чит кеше, бәлки, ышанадыр да, ләкин Казанда, татар интеллигенциясе арасында кайнаган теләсә кем моңа көлеп кенә куячак. Әмирхан Еники үзе дә: «Укып чыккач, көләсем килде», – ди һәм: «Ләкин көлә алмадым», – дип өстәп тә куя «Мин – кем?» дигән җавабында («Татарстан яшьләре», 28 октябрь, 1997 ел).

Мин дә көлмәдем. Гаҗәпләнмәдем дә. Үз кордашыма һәм өлкәнрәк каләмдәшләремә карата мин бүген кайбер тәнкыйть фикерләре әйтә алган булыр идем. Ләкин татарның һәр аңлы интеллигентына каршы «еврейский погром» булган бу көннәрдә мин элеккеләрне онытып торырга кирәк таптым. Узган 40-50 ел буена без татар әдәбиятын, телен, культурасын чордашлар-каләмдәшләр белән бергәләп үстердек, үзебезнең милли горурлыгыбызны, дәрәҗәбезне саклап калу өчен иң хәтәр заманнарда да алар белән бергәләп көрәштек. Гомәр Бәшировлар, Нәкый Исәнбәтләр, Хәсән Туфаннар, Әмирхан Еникиләр, Сибгат Хәкимнәр, Салих Батталлар, Аяз Гыйләҗевләр, Гариф Ахуновлар белән...

Татар телен, культурасын без шулай ук Салих Батыевлар, Камил һәм Фазыл Фасиевлар белән бергәләп үстердек, бергәләп сакладык.

«Махатма Еники»дә Миргазиян Юныс Салих Батыевны «баш идеолог», «татар Сусловы» дип атый. Татарны урыслаштыручы, татар мәктәпләрен ябучылар Мәскәүдәге чын идеологлар, чын Сусловлар түгел, татарның үз идеологлары «татар Сусловлары» булган имеш.

1957 елны мин язучыларның «Аккош күле» дип аталган дачаларында тордым. Декада беткәч, көннәрдән беркөнне, мине алырга дип кара машина килгән, Батыевтан. «Миңа Батыев кирәкми. Кирәк булсам, үзе килсен», – дидем. Бик усал әйткәнмен. Бик тупас әйткәнмен. Соңыннан Салих абый Ба-

Салих Батыев

тыев белән берничә мәртәбә күзгә-күз очрашырга туры килде. Теге вакыттагы тупаслыкны җиткермәгәннәрдер, дип әйтеп булмый. Очрашкач, бернинди ачу-үпкә сиздермәде. Шулай ук Обком трибунасыннан Фәттаховны хурлау белән дә шөгыльләнмәде. Анысын Табиев булдырды шикелле.

Мин белгән Салих Батыев, шәхес буларак, киң күңелле, аралашучан, ярдәмчел һәм... татар җанлы кеше иде. Татарстан Верховный Советы Председателе чагында, бер очрашуымда шундый хәбәр әйтте: «Әле сиңа кадәр генә Бакый абый (Бакый Урманче) булды. Ике квартирны бергә кушып, аңа бер квартира – мастерской ясап бирдек», – диде.

Кулыннан килгәнчә ул миңа да ярдәм итте. Казанның төньягында яңа йорт салып чыккач, тау-ташлы урамга су торбасы салу, дамба ясап асфальт җәйдерү хыялы белән саташып йөри башладым. Әллә кемнәргә гаризалар-фәләннәр язып, иң ахырында аңа – Батыевка барып җиттем. Ул миңа дамба ясау, асфальт җәю кебек эшләрнең бик кыйбатка төшәчәген аңлатты, су мәсьәләсендә тырышырмын, диде. Сүзендә торды: 711 метр җирне казып,

Нурихан Фәттах (уңнан өченче) каләмдәшләре арасында

шуңа торба салып, безнең урам очына су бирделәр. Барысы да бушка, ягъни дәүләт исәбенә.

Икенче бервакытны тагын аңа барырга туры килде. Йорт салган чакта ниндидер шикле бәндәләр борчып тордылар. Юк-бар йомыш табып бирсе иртүк кирә, икенчесе кичкә таба кирә. Үз йортларына кайткандай, туп-туры түргә узалар. Бер кышны, төн заманында, кемдер капка шакый. Мин Уфадан, Нурихан абый белән сөйләшәсе бар иде, ди. Уфадан килгән кешене кире җибәреп булмый ич инде. Ачтым, керде. Торт алып килгән. Чәй эчтек, сөйләштек. Икеле-микеле сораулар бирә, төпченә. Куенында ниндидер серле нәрсә дә бар сыман. Ул чакта әле ерактан ук тыңлый торган аппаратлар юк иде бугай.

Икенче көнне Гомәр абый Бәширов янына киттем. Минем өчен иң ышанычлы кешеләрнең берсе иде ул. Сөйләдем, тын алырга да ирек бирмиләр, дидем. Батыевка барып кара, диде Гомәр абый. Бардым, көттермичә кабул итте. Аңа да шул ук сүзләрне әйттем. «Сөйләшеп карармын», – диде Салих абый.

Күп тә үтмәде, гаҗәп хәлгә тарыдым – моңарчы ничек тә минем белән сүз куертырга тырышкан кайбер урамдашлар күрмәмешкә салышып китә башлады.

Кайберәүләр әйтер бәлки: империя таркалды, кысу-кисү бетерелде, тыю да, цензура да юк бездә, дияр. Россия кеше хокукларын яклый торган халыкара конвенциягә кул куйды, Татарстанда кеше хокукларын яклау комитеты эшли, дияр. Әүвәлгечә укыйм, язам-сызам. Менә шуны – язганнысызганны, телне-тарихны өйрәнгәнне яратмыйлар...

1948 елның 17 январь көндәлегенә: «Кич республика библиотекасында булдым. «Советская этнография» журналын (1946 ел, №3) укыдым. Татарларның килеп чыгышы турында күп нәрсә аңладым», – дип язып куелган. Татар тарихын өйрәнә башлавыма

илле ел тулган. Ярты гасыр. Үтәдем мин кызып китеп биргән антымны, дияргә хакым бар. Мин, Күчтавылның Садырилман улы Нурихан, дөньяда моңарчы беркем булдыра алмаганны булдырдым. Мин иҗекнең серенә төшендем. Иҗек сере ул – Тарихның да сере.

Безне әлегә беркем танымый. Куллар богаулы, телләр бәйләнгән. Татарның биш тавышлы мәхәббәт җырлары һәм үлем ачысын бәян итә торган мөнәҗәтләре бар. Мөнәҗәтләрнең ватаны бары бер генә төбәктә – күмү йолалары бик нык алга киткән мумияләр һәм пирамидалар илендә генә булган, дип әйтергә туры килә.

Боларның барысы да – Шумер һәм Мисыр, Атлантида һәм Троя. Монголия дә түгел, Алтай һәм Идел буйлары да түгел.

Халкымның томанга төрелгән ерак Тарихы миңа җанлы бер җыр булып тоела. «Әллүки», «Гөлҗамал», «Карурман»нар кебек.

Безнең җырны, безнең биюләрне беркем үзләштерә алмаган шикелле, безнең Тарихны да беркем үзләштерә һәм йомып кала алмый. Безнең Тарих ул – дөнья тарихы һәм, әлбәттә, үзебезнеке дә.

Гасырлар буена татар моңлы, сагышлы өмет хисе белән яшәгән. Җыр һәм өмет аны саклап калган. Җыры сүнмәсә, теле югалмаса – өмете өзелмәс, тыны киселмәс.

1997 елның 17 февралендә, борынгы бөек патшаларның рухи дәвамчысы, хөрмәтле Президентыбыз Шәрип улы Минтимер Шәймиев, Тарих институтын рәсми ачу тантанасында: үз тарихыбызны без үзебез язарга тиешбез; тарих эше дәүләт тарафыннан яклау табачак, диде. Амин, шулай булсын.

20 август, 1998. Казан

Р.Фәттахова искәрмәсе:

Мәкалә М.Ш.Шәймиев исеме белән тәмамлана. Бу урында биш ярым елдан соң, 2004 елның 16 февралендә, Нуриханның үләренә бер көн кала язылган фикерләрен өстәп куйсак, урынлы булыр, дип уйлыйм. «Шәймиев – безнең бәхетебез, татар бәхете, Татарстан бәхете. Мин аны хөрмәт итүдән беркайчан да туктамадым. Без атаклы әдәбият-сәнгать кешеләрен беләбез. Алар – безнең тарихка кереп калачак иң олы, иң данлы кешеләр. Теге заманда мин белгән җитәкчеләрдән дә олы шәхесләр булды. Ләкин алар, заманына ярашлы рәвештә, чынлыкта югарыдан кушканны йомышчы малайлар кебек үтәп утыручылар булды. Татар өчен, Татарстан өчен алар да нидер эшләделәр. Тарихка керерләрме-юкмы, әйтеп булмый. Шәймиев эшчән, тынгысыз һәм аның бар эшчәнлеге безгә – халыкка, Татарстанга юнәлтелгән. Ул инде күптән халыкара масштабта билгеле. (Россияне әйткән дә юк.)

Аңа ике арада, ягъни Мәскәү белән Казан арасында политик басым шартларында, политик буларак авыр эш алып барырга туры килә. Үзенең фикерен югары дәрәҗәдә аңлата, төшендерә, үзенең төп позициясен саклап кала, татарның ни дәрәҗәдә талантлы халык булуын исбат итә белә. Бөек шәхес. Синең, минем, татарның бәхете (гарантиясе) ул – Минтимер Шәймиев».

16.02.2004 ел ■

Мәшһүр җырчы, миһербанлы зат...

Рамил Курамшин

«Рәшит Ваһапов» дигәндә, минем күңелемне горурлык хисе биләп ала. Моның берничә сәбәбе бар, әлбәттә. Беренчедән, татар музыка сәнгате тарихында шушындый мәшһүр җырчының булуы – һәрбер татар кешесе өчен зур горурлык! Икенчедән, Рәшит абый белән без – якташлар. Аның туган авылы Актук белән (Түбән Новгород өлкәсе) безнең авыл (Кучкай Пожары) арасы 10-12 чакрым гына. Шундый якташ абыең белән ничек инде горурланмыйсың, ди! Кешедән туган ягы турында сораша башласаң, гадәттә, ул шул төбәктән чыккан күренекле шәхесләрнең исемнәрен атарга керешә.

Миңа, Татарстаннан читтә үскән кешегә, андый сорауларга бик еш җавап бирергә туры килә, һәм мин һәрвакытта да: «Безнең якташ Рәшит Ваһапов, Хөсәен Фәезханов, Кави Нәҗми, Рәшит Нәҗметдинов, Лотфулла Фәттахов, Гани Вәлиев, Мөхтәр Әхмәдиев һ.б.», – дип санап киткәндә, һичшиксез, беренче итеп Рәшит Ваһапов исемен атыйм. Ә иң зур горурлыгым – миңа шул мәшһүр җырчыны, исән чагында, концертта җырлаганын күреп калу насыйп булды.

1961 елның июнь аенда безнең авылда: «Казаннан филармония артистлары киләчәк!» – дигән хәбәр таралды. Мин ул чакта яңа гына 7 нче сыйныфны тәмамлап, 14 яшемне тутырып килүче малай-шалай идем. Мәдәният йорты каршына эленгән афишада зур кызыл хәрефләр белән язылган «Рәшит Ваһапов» исемен укыгач, йөрәгем «жу!» итеп китте. Кирәк бит! Шундый зур җырчы безнең авылга килә! Өлкәннәрдән мин аның безнең якташ икәнен ишеткәнем бар иде, ләкин моңа бик үк ышанып бетми идем, чөнки минем бала акылымда андый зур артистлар бары тик Казанда, һич булмаса, Татарстанда гына туып-үсә алалар кебек тоела иде. Гомумән, ул елларда Казаннан, филармониядән килгән артистларны күрү минем өчен фәрештә күрүдән ким булмагандыр?! Сүз уңаеннан шуны әйтәсем килә. Гади генә бер авыл малаеның менә шулай дип уйлавы – Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен

Рәшит Ваһапов

Казанның, чынлап та, рухи Мәккә икәненә бер дәлил дә!..

Ниһаять, түземсезлек белән көткән концерт буласы көн килеп җитте. Концертка керә алу-алмау проблемасы, Аллага шөкер, минем өчен юк иде – чөнки авылда булган һәр концертта да, яшьләр өчен үткәрелә торган «танцы»ларда да гел миңа баянда уйнарга туры килә иде. Шуңа күрә клуб мөдире мине балалар киносына да, сирәк-мирәк була торган профессиональ артистлар концертына да берсүзсез «бушка» гына кертеп җибәрә иде. Безнең якта Казан артистлары концертларына халык дәррәү йөри, тамаша залында энә төшәрлек тә урын калмый. Бәхетемә, бер сыеныр урын таптым үземә (басып торырга гына, әлбәттә). Мәгълүм ки, концертны иң әйбәт җырчы тәмамлый бит. Концерт бара да бара. Афишада язылган артистларның барысы да чыгыш ясап бетергәч, концертны алып баручы Әзәл ага Яһүдин берзаман: «Сәхнәдә – Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһапов», – дип игълан итте. Инде арып беткән аякларым тураеп китте, күңел җылынып куйды. Сәхнәгә озын буйлы, мәһабәт гәүдәле бер абый чыгып басты һәм залга илаһи моң агыла башлады. Яшерен-батырын түгел, безнең якта халык – бик эмоциональ. Ләкин Рәшит абый җырлаганда ник бер шылт иткән тавыш чыксын! Әйтерсең лә, үзенең югары сәнгате белән кешеләрне сихерләде дә куйды. Җыр тәмамлангач кына, барысы да, аңына килеп, диварларны селкетердәй көч белән кул чапты. Басым ясап шуны әйтәсем килә. Ул бит такмак җырлар белән түгел, ә халкыбызның җәүһәрләре булган моңлы җырлар белән халыкның күңелен яулады. Берничә җыр башкаргач, «Урман», «Зөләйха» кебек җырларны игълан итүгә, халык алдан ук шатланып кул чапты. Хәтеремдә, Рәшит абыйның радиодан ишетеп белгән кайбер җырларын җырлаганда мин күземне йомып тыңлап тордым, янәсе, сәхнәдән җырлаган тавышы радиодан яңгыраганына охшаган микән, Рәшит Ваһапов шул үземе икән?! Радио дигәннән, Аллага шөкер, безнең якларга Казан радиосы дулкыннары барып җитә иде һәм бу хәл якташларымның бик зур бәхете, дияр идем. Мин үзем дә шул радиодан татар концертларын тыңлап үсмәгән булсам, ихтимал, язмышым бөтенләй башка юлдан китеп барган булыр иде.

Илдар Мәҗитов, Рәшит Ваһапов, Салих Сәйдәшев, Әсма Шәйморатова, Фәйзи Биккенин. 1949 ел

Ул елларда микрофон дигән нәрсәнең эзе дә юк иде бит. Ләкин Рәшит абыйның гаҗәеп моңлы һәм шул ук вакытта табигый көчле тавышы бөтен тамаша залын тутырды. Чыгышы тәмамланса да, халыкның көчле алкышларын ихтирам итеп, ул тагын берничә җыр башкарды. Бу концерттан соң инде менә 50 елдан артык вакыт үтте, әмма, һич арттырып әйтүем түгел, Рәшит абыйның «тере» тавышы бүген дә колагымда яңгырап тора!..

Бездә булганнан соң, алар бүтән татар авылларына китеп бардылар (безнең төбәктә 35 татар авылы бар), һәм бер-ике атнадан безнең авылга шундый хәбәр килеп җитте: Рәшит Ваһапов үзенең туган җире Актукта концертны бушлай куйдырган икән! Бу хәбәрнең дөреслеген мин байтак еллар үткәч төгәл итеп белдем. 1988 елның маенда Рәшит абыйның тууына 80 яшь тулды. Шушы уңайдан аның туган авылында искә алу кичәсе үткәрелде. Бу кичәдә катнашырга Казаннан Рәшит абый белән эшләгән Әзәл Яһүдин, Сәгыйть Алиев, Рәшит абыйның улы һәм хатыны Зәйтүнә апа, Зөһрә Сәхәбиева белән мин дә кайттым. Шунда кичә барышында мин өлкән генә укытучы абыйдан (ул Р.Ваһаповка туган тиешле кеше булып чыкты) алда язылган «хәбәр» турында сорашкан идем: «Әйе, Рамил энем, нәкъ шулай булган иде шул», – диде. Әйтергә теләгәнем шул: димәк, ул мәшһүр җырчы булуы белән бергә, кеше буларак та киң күңелле, миһербанлы булган!..

Алдарак мин «Зөләйха» дигән җырны искә алган идем бит. Бу җырны һәр татар кешесе белә, әлбәттә. Ләкин ул җырның нәкъ

Рәшит Ваһапов (рәсемдә беренче рәттә уңнан икенче) үзенең концерт бригадасы белән. Новосибирск, 1958 ел

менә безнең төбәктә туганлыгын бик сирәк кеше генә беләдер. Ә инде аның бөтен татар халкына таралып китүенә Р.Ваһапов сәбәпче була...

1940 еллар башында ул, Казанга килеп, филармониягә эшкә урнаша һәм «Зөләйха»ны концертларда, радиода җырлый башлый. Шулай итеп, ул халкыбызның уртак хәзинәсенә әйләнә.

«Чын сәнгать әсәре һәм чын талант ияләренең иҗаты гына мәңгелеккә кала», – дигән мәгълүм хакыйкать бар. Алар беркайчан искермиләр дә, таушалмыйлар да, киресенчә, еллар үткән саен аларның кыйммәте арта гына бара. Кызганыч ки, менә шушы хакыйкатьне бездә соңгы елларда оныта башладылар һәм «заманча» дигән шаукымга ияреп, җырларыбыз да, җырчыларыбыз да «интернациональдәйгә», ягъни урыслаша башладылар. Әгәр без бүген Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова кебек мәшһүр җырчыларыбызны оныта башласак, киләчәктә инде Илһам Шакиров, Габдулла Рәхимкулов, Әлфия Афзалова, Флера Сөләйманова кебек җырчыларыбызны да югалтачакбыз. Шуннан соң халкыбыз күңелен яулаган җырчыларыбыз онытылачак та инде... Ә милли сәнгате һәм милли рухы булмаган халык, милләт буларак, яшәүдән туктый – бу аксиома! Шуңа күрә Рәшит Ваһапов кебек җырчыларыбызның сәнгатен без радио-телевидениедән дә, матбугат битләрендә дә һәм башка төрле чаралар белән дә үсеп килүче яшь буынга һәрдаим пропагандаларга тиешбез. ■



ҮЗ ЯГЫНЫҢ БАЛАСЫ

Туфан Миңнуллин

Нижгар татарлары турында мин беренче тапкыр 1956 елда Мәскәүдәге Измайлов паркында ишеткән идем. Шундагы бер аланда яшьләр җыелып күңел ачалар – җырлашалар, биешәләр. Ят җыр ишетеп, бер төркем яшьләр янына бардым да тыңлыйм. Миңа бик кызык. Көйләре генә түгел, сүзләре дә ятрак минем өчен:

Ак пирцаткаң бар мәллә,
Бармакцасы тар мәллә?
Аләнәсең дә карыйсың,
Атер сузең бар мәллә?

Бер кыз белән егет кара-каршы җырлаша. Кызның тавышы искиткеч, егете дә калышмый. Әлеге төркемдәге яшьләрнең нижгарлар дип аталуын һәм татар икәнлекләрен (ягъни мәсәлән мишәр) белгәч, бигрәк тә кызык булып тоелды. Алар белән еш аралаша башладым. «Картуф» көен бигрәк яратып тыңлый идем.

Шунда мин безнең авылның карты-яше, бөтен эшен ташлап, радиодан җырларын тыңлаган Рәшит Ваһаповның да Нижгар татары икәнен белдем.

Татарстаннан читтәрәк яшәгән бу кавемнең ни җитте генә кешеләр түгеллеген соңрак та күрдем һәм көннәрнең берсендә шул якларга сәфәр чыктым. Ураз, Рбишча авылларында, Рәшит Ваһапов туган авылда – Актукта булдым. Сөйләштем, тыңладым, күзәттем – чыннан да, бу якта үзенә бертөрле кешеләр яшәгәнен аңладым. Телләрендәге үзенчәлек гаҗәпләндермәде мине – анысы инде «цыкылдап» торган татар теле. Хәер, без ул сүзне «чыкылдап» торган дибез. Аермасы юк. Әмма кешеләрнең холкы бүтәнчәрәк. Горурлар, әзмәз тәкәбберлек тә бар. Бүтәннәр белән сөйләшкәндә бик үк чишелеп китмиләр. Әйтәсе сүзләренең яртысы күңелләрендә кала. Синең белән сөйләшә башлап, бер-ике сүз әйтешүгә кем икәнлегеңне белеп алалар. Ахмак икәнеңне сизсәләр, сине мыскыл итебрәк сөйләшәләр. Акыллы икәнеңне белсәләр, хөрмәт белән карыйлар. Ләкин бер очракта да дәрәҗәләрен төшермиләр.

Татар халкының бөек җырчысы Хәйдәр Бигичев турында язганда, аның туган ягы, шул якның кешеләрен искә алуым очраклы түгел. Шул якның баласы иде ул, шул як кешеләренең холкы иде аңарда. Горур. Әз-мәз генә тәкәббер дә. Кемгә дә булса ярарга тырышып, дәрәҗәсен төшерергә теләмәгән җан. Үз кадерен үзе белгән шәхес. Бәлки, аның да йомшап киткән чаклары булгандыр, Хәйдәр белән бик еш очрашкан кеше түгел мин. Әмма очрашып фикер алышканда, аның кистереп сөйләшүе миңа ошый иде. Җырлаганда да ул, сәхнәдә башын югары тотып, Сабан туйларында беренче булып килгән нәселле чабышкы сыман басып тора иде.

Җырларның саллыларын гына сайлап җырлый иде. Җыен шырдыйбырдыйлар аның тавышына гына түгел, холкына да, хәтта гәүдәсенә дә ят иделәр.

... Әйе, тамак хакына җырлау заманына әләкте шул Хәйдәр. Минемчә, аның горур җаны моның белән ризалашмады. Талант иясе бәргәләнде, өзгәләнде һәм...

Бөек җырчы иде Хәйдәр Бигичев. «Иде» дип язу авыр. Ләкин бер юаныч бар: ул туган як, җырлы, моңлы як, бәлки, татар халкына тагын да талантлы кешеләрне үстереп бирер, Алла боерса. ■

Сибгат Хәким
(1911 - 1986)

1986 елның җәендә Сибгат ага Хәкимгә беренчеләрдән булып «Татарстанның халык шагыйре» дигән исем бирелде. Бу вакытта әдип хастаханәдә иде. Үз хәле хәл булган олпат шагыйребез әлеге шатлыклы хәбәрне ишетеп сөенгәндерме-юктырмы, анык кына әйтә алмыйм. 3 июльдә Сибгат ага вафат булды.

Минем СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазифасына керешкәнемә айдан артык вакыт үткән генә иде әле. Сибгат аганың вафат булуы турындагы хәбәрне Язучылар йортында (ул элек Комлев, хәзер Мөштәри исемен йөрткән урамда урнашкан иде) ишеттем. Шунда чагында балалар шагыйре Галимҗан Латыйп очрады. Куллар бирешеп күрештек. Минем ашыкканымны, кемнәрнеңдер тыз-быз килгәнен күреп, ул: «Монда бүген урак өсте вакыты икән!» – дип әйтеп куйды. Мин аның Сибгат аганы өнәмәгәнен белә идем. Бауман урамындагы Тукай клубында узган җыелышларда ул гел сүз ала торган иде һәм шулчакларда: «Нишләп Мәскәүдәге тантаналарга Сибгат Хәким һәм фәлән-төгән язучылар бара? Нишләп исемлектә без юк?» – дип, үз исеме янәшәсенә кайбер уртакул каләм әһелләрен дә куеп, пыр-пыр килеп чыгышлар ясый иде...

Сибгат ага вафатына дүрт ай булды дигәндә, Галимҗан Латыйп үзе дә якты дөньядан китте...

Бутлеров урамында урнашкан моргка шагыйрьнең кече улы Рафаэль белән бер үк вакытта диярлек килеп җиттек. Тагын кемнәрдер бар иде, алар истә калмаган. Хәтердә булганы шул: әдипне Театральный урамындагы фатирына алып кайттык. Икенчеме көнне шагыйрь гәүдәсен «ПАЗ» автобусына куеп Актёрлар йортына китердек шикелле...

Шушы урында татар-башкортның күренекле шагыйре Нажар Нәҗминең «Күңелнең алгы сызыгында» дигән язмасыннан өзек китерү урынлы булыр кебек: «...Сибгат Хәким миңа карата бик игътибарлы булды. Күңеленә хуш килгәнмендер, яраткандыр. Бәлки минем аны ятатканны белеп тә яраткандыр. Казан телевидениесе миңа багышланган ике тапшыру оештырды. Беренчесендә (1977) режиссёр Әхтәм Зариповның тырышлыгы һәм ихтирамы көн кебек ачык иде. Икенчесендә дә (1986) шулай ук. Шуларның икесендә дә Сибгат Хәким

катнашты, вакыт тапты. Телевидение камерасы алдында аның бер язусыз-нисез оста сөйләве дә хәйран калдырды. Бу аның тагы бер үзенчәлеге, талантының бер кыры иде.

Икенче һәм соңгы тапшыруда катнашыр өчен баруыма аерым тукталмакчы булам. Казанга килеп, кунакханәгә урнашуым белән Сибгат Хәкимнең өенә шылтыраттым. Ул, минем тавышны ишетү белән: «Нигә озакладың? Сине көтеп утырам. Радиога барабыз. Кил!» – диде. Опера театры янында очрашырга сүз куештык. Килдем. Ул көтеп тора. Күрәм: бик ябыккан, йончыган, йөзе агара төшкән. Инфаркт, димәк, үзенекен иткән. Без радиога киттек. Поэзияне бик тә яраткан, аның чын патриоты – радиода әдәби-драматик тапшырулар редакторы Рөстәм Фәйзуллин, чыннан да, безне нык көткән. Радиога язылгач, Сибгат Хәким мине Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәгә алып китте. Күргәзмә искитәрлек тәэсирле иде, мин заллар буйлап йөргән чагымда, С.Хәким утырып та торды. Хәлсезлеге сизелә иде. Аннан соң без аның өенә кайттык. Почта тартмасыннан гәзитләр һәм хатларын алды. Алар арасында Гамил Афзалдан да хат бар иде. «Гамил белән дә хат алыша икән», – дип эчтән генә уйлап куйдым...

Сибгат Хәким миннән җиде яшькә олы. Шулай булуына һәм авырудан соң йончыганлыгына карамастан, Казанга шушы килүемдә ул дүрт көн буе минем белән бергә булды: радиодан соң икенче көнне телевидениедә язылдык, өченче көнне безне Тукайның туган көнендә ел саен уздырыла торган шигъри митинг, кичен «Без китәбез, сез каласыз» дигән спектакльнең премьерасы көтә иде. Дүрт көн буе без бик күп сөйләштек, нәрсәләр хакында икәнлегенең байтагы хәтердә калмаган, ә хәтердә калганнарының кайберләрен монда язып та булмый, әмма иң хәтердә калганы – шагыйрьнең Курск дугасында сугыш барган җирләрне, окоп урыннарын, сугыштан соң барып күргәннән соң алган тәэссоратлары иде. Ул рота командиры булган. Рота һәм взвод командирларының, солдатлар кебек үк, сугышта кырылганнарын беләм. Мин аннан: «Ничек исән калдың? Курск дугасыннан соң да сугышлар каты барды. Кешеләр, командирлар һәлак булдылар», – дип сорагач, «Мине 1944 елның язында Румыния чигендә пограничник итеп калдырдылар», – диде. Минем өчен бу, әлбәттә, яңалык иде, чөнки без дә шул язны беренче булып Румыниягә кергән идек...

Безнең бергә булган көннәр Тукайга 100 ел тулу бәйрәме алдыннан иде. Казаннан киткәндә, шул 100 еллыкта тагын да очрашуны күз алдында тотып, Кырлайдан кайтышлый аның туган авылы Күлле Кимегә дә кереп чыгарга да хыялланып, аерылыштык. Без июнь аенда бәйрәмгә килдек, Сибгат Хәкимне, Тукай бәйрәменә бер атна калгач, больницага салганнар. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрындагы тантаналы кичәдә дә, Кырлайда да Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким, берсе арадан бөтенләй китеп, икенчесе чирләп, катнашмады. С.Хәким, авыруы көчле булуына карамастан, Тукай көннәрендә катнашырга теләп, тәмам егылганчы, больницага кермәгән.

Бәйрәм үткәч, Сибгат Хәким янына Мостай Кәрим белән икәүләп кермәкче идек, миңа берүземә генә керергә туры килде. Хәле элеккегә караганда җиңеләя төшкәнен үзе дә, Мөршидә ханым да әйткәч, тынычлана төштем. Минем баш сүз белән чыккан ике томлыкның беренче томын нәшриятта бүләк итеп биргәнлекләрен әйтте: «Икенче томын язып үзем җибәрермен», – дип тә куйды.

Әй, өмет! Шул өмет эчендә авыру шагыйрь белән саубуллаштым. Мин ишек төбенә җитәр чакта гына: «Рәхмәт!» – диде. Бу аның миңа әйткән соңгы сүзе булган икән. Ул сүзе 1986 елның 13 июнендә әйтелгән иде, ә инде 5 июльдә, аны җирләргә килгәч, табуты янында шушы соңгы сүзен кабатладым...»

Инде хәзер Гомәр Бәширов көндә-

Рәдиф Гаташ, Сибгат Хәким, Роберт Миңнуллин, Нәҗар Нәҗми. Казан, 1986

легендәге язуларга игътибарыбызны юнәлтик: «Бик аяныч хәл: бүген иртәнге 11дә Сибгат Хәким вафат. Ул берәр айдан бирле шифаханәдә ята иде. Узган елгы инфаркты яңарган, башка авырулары да кузгалган, диделәр. Шулай да берәр атна элек инде утыра башлаган, хәле яхшыруга таба бара дигәч, бераз сәламәтләнер бәлки, дип өметләнгән идек. Әмма берничә көн элек аңа яңадан приступ булган. Шуннан соң Сибгат әйткән: «Моңарчы яшәргә өметем бар иде, хәзер өметем өзелде инде, яшәп булмас, ахрысы», – дигән.

Шуны ишеткәннән соң, без дә бик борчылган идек, ниһаять, бүген 11 тулгач, Маһирә* фаҗигане хәбәр итте.

Сибгат белән без бер якныкы, Казан арты тумалары. Иҗат тормышыбыз да 40 нчы еллардан бирле янәшә барды, заманында бик якын дуслар да идек, менә күптән түгел, бер үк көнне халык шагыйре, халык язучысы дигән хөрмәтле исемгә лаек булдык. Әмма, кызганычка каршы, Сибгаткә ул исемне йөртү насыйп булмады.

Сибгат үзен Тукайның шәкерте, аның иң якын варисы, дип саный, ул моңа чыннан да лаеклы иде. Г.Тукайның 100 еллыгы алдыннан ул Тукайның истәлеген мәңгеләштерү өчен күп хезмәт куйды. Әмма үзе юбилейда катнаша алмады, каты авыру иде инде. Менә бүген ул бу фани дөньядан соңгы сулышын алды.

Ветераннар китә, ветераннар азая, әдәбият үзенең төп таянычларын югалта бара.

Бу көннәрне бик авыр кичерәбез. Әле күптән түгел генә Сара Садыйкованың вафатын да бик авыр кичергән идек, аның хакында язарга кул бармый тора иде... Менә бүген – Сибгат.

С.Хәким татар картларына хас сабырлык белән үзенең үлемен алдан ук көтеп алды. Шулай булуы мөмкинлеген алдан ук күрә белде, аһ-ваһ итмәде, зирәк акыллы картларча аңа алдан ук әзерләнде, бәлки, бәлки, дип күңелен дә чуарлатмады. Ул, мәсәлән, үләренә берәр ай чамасы каларак, М.Мәһдиевкә, нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдиновка соңгы көннәре якынлашып килүен сиздерерлек итеп хатлар язды. Хатларында ул тормышыннан, авыруыннан зарланмый, һәммәсе өчен, аңа күрсәткән яхшылыклары өчен бу иптәшләргә рәхмәтләр әйтә. Аларның эшләренә уңышлар теләи. Алты ай алдан газеталарга язылып, алдан ук квартира хакын түләп куя. Шифаханәдә ятканда аның янына Рауза Газизова кереп хәлен белешкәннән соң, аның күңелен күтәрү өчен:

* Маһирә Миңнуллина – 1969-1990 елларда Татарстан Язучылар берлегенең иҗат буенча кадрлар инспекторы.

С.Хәким җәсәде салынган табутны Актёрлар йортына алып кергән вакыт. 1986

– Әйдә, тизрәк тазар да менә Аккош күленә дачага китәрбез. Җәйнең бик матур вакытында анда сәламәтлегең тагын да ныгыр, – дигән.

Моңа каршы Сибгат үзен үзе юатырдай ясалма оптимизмга бирелү юлына басмаган.

– Юк инде, мин Аккош күленә бүтән бара алмам, ахрысы, мин башка җиргә китәрмен, – дигән.

Шагыйрь Илдар Юзеев та аны юатып шундыйрак мәгънәдәге сүзләр әйткән:

– Ел саен туган авылыгыз Күлле Кимегә кайта торган гадәтегез бар иде. Больницадан чыкканнан соң, анда кайтасыгыз бардыр әле, – дигән.

– Быел миңа Күлле Кимегә түгел, Яңа бистәгә юнәлергә туры килер, ахрысы, – дигән.

Вафат буласы көнне (3 июль) иртә белән ул юынган, үзе кырынган. Әгәр ялгышмасам, хатыны Мөршидәгә шундый фикер әйткән булса кирәк:

– Менә шулай инде, үләсе көнне Әхмәт Фәйзи дә шулай иртүк торып кырынган, – дигән сыман нидер әйткән. Мин моны Мөршидәдән ишеттем.

3 июль көнне ул иртә белән үзен ярыйсы хис иткән: юынган, кырынган, тамагын туйдырган.

– Бик яхшы булды әле бу, – дип сөйләшеп алган. Бераз ятып торганнан соң, карават башына таккан бауга ябышып торып утырган.

– Шул арада борылып карасам, ул инде китә дә башлаган иде, – ди Мөршидә.

Вафатыннан соң бер атнадан Аккош күлендәге дачаларында Мөршидә җидесен уздырды. Анда иң якыннарыннан утызлап иптәш катнашты. Мәҗлесне Гариф Ахунов алып барды. Иң өлкән яшьтәге кеше буларак, берничә сүз әйтүне миңа тапшырдылар. Тагын И.Юзеев, Н.Юзиев, Г.Шәрәфетдинов, Ш.Галиев, Г.Ахунов, Р.Гатауллин, Р.Миңнуллин, Р.Хәмид һ.б. сөйләделәр.

10 декабрьдә Актерлар йортында С.Хәкимнең туууына багышланган җыелыш булды. Г.Ахунов доклад ясады, шагыйрьләр шигырь укыдылар. Соңыннан концерт булды.

Хикмәт бу информацияне теркәп калуда гына түгел. С.Хәким әдәбиятта соңгы елларда ярыйсы ук зур урын тота башлаган иде. Аның юклыгы һәрвакыт үзен сиздереп тора».

*Язманы **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Әткәй каеннарының хәтерләре

Әлфия Шамова

Әтием тышкы кыяфәте, йөзе, чырае белән беренче караштa ук күпләрдән нык аерылып торды. Озын буйлы, олпат сынлы, киң җилкәле, күркәм йөзле, зур маңгайлы, кап-кара куе бөдрә чәчле, нур чәчеп торган зур зәп-зәңгәр күзле кеше иде ул. Йөреше-торышы, кием-салым белән гади иде.

Әтием Афзал Шамов – авыл егете, шуңа күрә аны кечкенәдән эшкә өйрәткәннәр: җир тырмалаган, сукалаган, печән чапкан, урак урган, ашлык суккан – кыскасы, авылда барлык эшләрне башкарган. Кул эше һөнәрләрен дә яхшы белә иде. Өйдә безнең аяк киемнәрен кияргә яраклы итеп төзәтте, ямады, олтан салды. Бу һөнәргә ул балачактан ук бабасыннан һәм абыйларыннан өйрәнгән.

Әтием холкы белән күпкырлы кеше иде: өлгер, хәрәкәтчән, гаҗәп зирәк һәм булдыклы, бик таләпчән һәм пунктуаль. Ул киң күңелле, һәркемгә кулыннан килгән бөтен ярдәмне күрсәтергә әзер торучы кеше булды. Аккош күлендәге язучылар бакчасында ул, улы һәм кияүләре белән бергә, веранда һәм сарай төзеде. Җиләк-җимеш, алмагачларны үстерүдә дә осталыгы зур иде. Аның үстерү серләренә шунда торган барлык язучылар да гаҗәпләнә һәм, кирәк булганда, мөрәҗәгать итеп килә, әти аларга файдалы киңәшләр бирә торган иде.

Татар зыялыларыннан ул белмәгән, аралашмаган кеше булмагандыр. Әтием рәсем сәнгате эшләрен дә яратты, бөтен күргәзмәләргә йөрде һәм күренекле рәссамнар – Лотфулла Фәттахов, Харис Якупов, Байназар Альменов, Бакый Урманче белән аралашты, аларның әсәрләренә дөрес бәя бирде. Хәтта әсәрләрендәге кимчелекләрен дә күрде, рәссамнарга кирәк чакта үзенең киңәшләрен дә бирә белде. Мәсәлән, безгә кунак булып килгән танылган рәссам Фәйзерахман Әминевне, Г.Тукайның «Шүрәле»сенә ясаган иллюстрацияләрендә чабып баручы атның дагасы дөрес сурәтләнмәгәнен әйтеп, анда артык кадакларның санына игътибарын юнәлтеп, гаҗәпкә калдырганы хәтеремдә.

Әти музыка сәнгате осталары белән дә якыннан аралашты. Мәшһүр композитор Солтан Габәши, Александр Сергеевич Ключарёв, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзи белән дә ул дусларча якын мөнәсәбәттә иде. Атаклы җырчы Гөлсем Сөләйманова безнең өйдә һәрвакыт иң кадерле кунак булды. Әти борынгы татар

Афзал Шамов (беренче рәттә сулдан икенче) каләмдәш-фронтовиклар белән бергә. 23 апрель, 1947 ел

көйләрен аеруча яратты. Музыка сәнгатен бик нечкәләп тоя иде ул. Бу аның әсәрләрендә дә тасвирланган: «Өзелгән кыллар», «Курай тавышы» һ.б. Иң яраткан музыка кораллары курай һәм скрипка булды.

Әти кешеләргә карата игътибарлы, сизгер, гади мөнәсәбәтле иде. Ул үзен һәрчак гади тотып, олысы-кечесе белән уртак тел табып килде. Буа районының Кильдураз авылында туып-үскән, хәзер Казанда яшәүче Илгиз Бикчәнтәев әтиемне болай искә ала: *«Миңа, алты-җиде яшьләрдәге малайга, Казан кадәр Казаннан тәмле-тәмле күчтәнәчләр күтәреп кайткан. Мине иң сөендергәне, шатландырганы – аның махсус миңа дип алып кайткан милли уен коралыбыз курай булды. Ул, чыннан да, киң күңелле, бала җанлы кеше...*

Афзал ага курай белән ничегрәк уйнарга, көй чыгарырга күрсәтеп бирде. Үзе үк төрле-төрле көйләр дә чыгарды...»

Әти спорт уеннарына да бик һәвәс кеше булды. Иң яраткан ялы – шахмат уйнау. Ул беренче разрядлы шахматчы киявен дә еш кына җиңә иде.

Әти бик тә ярдәмчел кеше иде. Язучы Шәриф Камал янына барып, хәлен белешеп кенә калмаган, аның гаиләсе өчен утын кискән, аны ярган, су алып кайткан. Бу турыда миңа әдипнең кызы Зәйнәп Байгилдиева әле илленче еллар ахырында ук сөйләде. Әти туганнары, дус-ишләре турында гына түгел, күп язучыларның сәламәтлеге турында да кайгыртты. Алар авырып киткәч, өйләренә яисә хастаханәләргә хәлләрен белергә барды, аларны дәвалаучы табиблар белән сөйләште, кулыннан килгән ярдәмне күрсәтте. Аның Таҗи Гыйззәт, Кави Нәҗми, Әхмәт Фәйзи, Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Гази Кашшаф, Ибраһим Гази һ.б.ның янына хәл белергә барганын хәтерлим.

Әтинең көндәлегеннән: *«7 март, 1955 ел. Соңгы айларда өч язучы бик каты авырып ята: Таҗи Гыйззәт, Халикъ Садри, һәм Иван Заботин. И.Заботинның авырый башлавына инде ел ярымнан артык. Аның нәрсә белән авырый икәнен табибларның әле хәзергә*

кадәр ачык әйткәннәре юк... Халикъ Садри да шулай ук ел ярымнан бирле авырый... Соңгы көннәрдә хәле тагын да начарланып китте... Таҗи Гыйззәтнең дә хәле соңгы көннәрдә бик начарланып киткән икән. Без бүген иртә белән өчәү (Гази Кашшаф, Ибраһим Гази һәм мин), тугыз белән ун арасында, аның янында булдык. Сәгать унбер тулганчы утырдык...»

1966 елда Г.Әпсәләмовның хәле бик авыр, хәтта өметсез дәрәҗәдә авыр иде. Прфессорлардан һәм табиблардан торган консилиум берничә мәртәбә «авыруы бик куркыныч», – дигәннәр иде. Габдрахман ага авырып яткан вакытта әти берничә ай дәвамында һәркөнне аның янына хастаханәгә барды, янында утырды, кирәкле дарулар эзләп табып китерде. Үзенең балаларын да булышырга өндәде: табиб һөнәрле улы, кызы һәм килене Габдрахман ага янында төнлә дежур торды, кече кызы исә әдипнең балаларына дәресләрен әзерләргә булышты.

Менә тагын бер мисал: *«5 июнь, 1966 ел. Х.Туфан хастаханәдә. Хәлен белергә кергән идем. Бу көннәрдә чыгарга тиеш. Үзе янына баргач, аны дәвалаучы таныш табибларны күреп сөйләштем, куркыныч бернәрсә дә юк, диделәр, барысын да картлыкка сылтадылар: склероз, ябыклык, кан басымының берникадәр күтәренкелеге...*

Кашшаф та бик озак хастаханәдә ятып чыкты. Аның авыруы шактый җитди: йөрәгендә һәм бавырында».

Габдрахман ага әтине бик хөрмәт итте, шуңадыр, аның турында болай язып калдырды: *«Афзал ага Шамов безнең әдәбиятның түренә яшенең өлкәнлеге, талантлы әдәби әсәрләр язганлыгы өчен генә түгел, бәлки кешелек сыйфатлары өчен дә менеп утырды...*

Татар язучылары арасында Афзал ага Шамов – иң кешелекле кешеләрнең берсе, диясем килә».

Куркусыз, тәвәккәл кеше иде әти. Ул 1920 елда гражданнар сугышына үзе теләп китә, акларга каршы сугыша һәм барон фон Врангель яуларын тар-мар итүдә, Перекопны штурмлауда катнаша, Украина далаларында Махно бандаларын дөмбәсли. Махночыларга каршы сугышканда, курсант Афзал атлы разведкада хезмәт итә. Бервакыт разведкага баргач, сугышчан иптәше украин егете Охраменко белән бергә, Афзал берьюлы өч бандитны, коралсызландырып, тотып алып кайта.

Ул 1944 елның җәендә фронтта, Белоруссиядә, бер кулына граната, икенчесенә пистолетын тотып ышыкланып килүче фашистлар төркеме алдына сикереп чыга да каты тавыш белән: «Hände hoch», – дип кычкырып, һавага атып, аларны кулларын күтәрергә мәҗбүр итә. Аннары җиде немецны әсирлеккә ала һәм аларны тиешле урынга илтеп тапшыра. Язучы Ибраһим Гази үзенең истәлегендә әти турында болай яза: *«Әгәр фронтта да бергә булган булсак, җиде фрицның дүртесен ул, мөгаен, миңа биргән булыр иде, чөнки, Афзалга юмартлык хас».*

Әти бик яхшы, йомшак күңелле кеше иде. Балаларны аеруча ярать. Чәй янында үзенең оныкларына бик кызыклы хикәяләрне, көлә-көлә, тәмләп сөйли иде – бирелеп тыңлыйсың. Ләкин ул шул ук вакытта бик таләпчән дә булды, бездән бирелгән эшне вакытында һәм яхшы сыйфат белән үтәүне сорады. Безне кечкенәдән: *«Әйтергә теләгән фикерне ачык аңлатыр өчен кирәкле сүзләр сайлагыз һәм дөрес сөйләүгә бик нык игътибар итегез»*, – дип өйрәтте.

Афзал Шамов киң белемле, үтә укымышлы, гаять күптармаклы, зур эрудицияле, талантлы әдип кенә түгел,

ул ифрат намуслы, эшенә җаны-тәне белән бирелгән кеше дә булды. Аның сокланырлык хәтеренә чордашлары шаккатты. Ул үзен бик оста, зур квалификацияле тәрҗемәче дә, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе дә, фольклорчы да, галим буларак та танытты. Әтием – әле утызынчы елларда ук халык җырларын, бәетләрен җыйган, аларны бастырган, Г.Ибраһимовның «Сайланма әсәрләр»ен редакцияләп чыгарган кеше. Аннары аның сигез томлык «Әсәрләр җыелмасы»ның проза әсәрләрен әзерләп чыгаруга катнашты, аларга аңлатмалар язды һәм истәлекләр китабын да чыгарды. Г.Ибраһимов хатларын җыю өчен аңа дистә еллар кирәк булды. Ул әдипне белгән, аның белән язышкан кешеләрне эзләп тапты, хат язып яисә үзен күреп, кулларындагы язмаларны ялынып-ялварып, кайчакларында зур акча яисә бүләкләр биреп җыйды һәм бөтен тапкан хатларны матбугат битләрендә бастырып чыгарды. Ләкин, кызганычка каршы, аннан тормаган сәбәпләр аркасында, аерым китап итеп бастыра алмады.

Әти Ф.Әмирхан әдәби мирасын халыкка кайтарып бирүгә дә зур өлеш кертте: 1941 елда әдипнең «Сайланма әсәрләр»ен, 1957 елда ике томлык «Әсәрләр»енең беренче томын аңлатмалар белән бастырып чыгарды. Бу эш гаять авыр шартларда эшләнде, чөнки Ф.Әмирханга озак еллар буе дөрес бәя бирелмәде, ул либераль буржуаз язучы тамгасы белән йөрде. Әлеге бәя аның әсәрләрен дөньяга чыгаруга киртә булып торды. Бу киртәне беренчеләрдән булып әти Хәй ага Хисмәтуллин белән алып ташлады.

Туган ил табигатен саклау буенча дәүләткүләм проблемаларны ул, татар язучыларыннан иң беренче булып, үзенең «Аккошлар, кире кайтыгыз!», «Елгалар һәм балыклар», «Табигать дуслары» исемле очеркларында илленче елларның ахырында ук күтәреп чыкты. Бу үткен мәкаләләрендә куелган төп максат – киләчәк еллар өчен кешеләр хәзер кайгыртырга тиеш, чөнки алар үзләре дә табигать балалары бит. Шуңа күрә һәр кеше табигатьне яратырга, аны саклау өчен көрәшергә тиеш. Табигать үзен яраткан кешеләрне генә ярата!

«Мәңгелек ут янында уйланулар»ында әти болай яза: «Әгәр без Җиңү көнен, бу зур бәйрәмне Бөек Ватан сугышында һәлак булган туганнарыбыз, абыйларыбыз, әтиләребез, бабаларыбыз истәлегенә һәр авылда, һәр районда, һәр шәһәрдә агачлар утыртып, бакчалар, парклар булдырып каршыласак, батырлар алдындагы бурычыбызның бер өлешен үтәгән булыр идек... Кулына көрәк тота алган һәр кеше, аларга багышлап, алар истәлеге итеп, үз бакчасына, үз өйләре алдына берәр төп агач утыртса да, яхшы булыр иде. Илебез матурланыр, яшеллеккә күмелер иде».

Моннан нәкъ йөз дә биш ел элек туган авылында, үз өйләре янында, бабасы Нәҗметдиннең киңәше белән, үзенә ун яшь тулу уңаеннан, ун төп каен утырткан. Бу каеннар гаҗәп матур булып, бөдрәләнеп үсеп киткән, ботакларын тирә-якка җәеп, бик озын булып үскән. Шундый гаять зур һәм бик юан каеннарны башка беркайда да күргәнем юк. Ул каеннарга сугыш вакытында да кул тидермәгәннәр, чөнки авылда әтигә хөрмәт ифрат зур булган. Бу каеннарны хәзер дә «Афзал ага каеннары» дип йөртәләр. Күп еллар үтсә дә, алар исән! Дөрес, алар инде унау түгел, кимрәк. Бу каеннар җәй көннәрендә ямь-яшел булып, авылның бер почмагына күркәмлек һәм ямь биреп тора. ■

Гали абый

Зәки Зәйнуллин

Гали Тукай – Габдулла Тукай нәселеннән. Бик күп данлыклы, атаклы, исемле шәхесләр биргән Казан ягында, Габдулла Тукайдан башка, берәүдә дә Тукаев фамилиясе юк. Әйе, Казан артында Тукаевлар бөтенләй юк. Чөнки Габтукай егет, унсигез яшендә Салавычны ташлап, чукынудан качып, Уфа-Ырынбур юлында нәкъ уртада утырган Эстәрлебашны эзләп чыгып киткән һәм шунда төпләнгән. Габтукай бабай Эстәрлебашта төпләнгәннән соң, 210 ел Эстәрлебашта Тукаев фамилияле бабайлар, ирләр, малайлар яшәгәннәр. Барысы да – Габтукай бабай балалары, 1912 елда алар 32 шәхес исәпләнә. Эстәрлебашта яшиләр, барысы да Тукаевлар. Шуларның берсе – Гали Тукай, 1903 елда туган. Әтисе – Зариф, әнисе әле сугыштан соң да исән иде.

Гали Тукай искитмәле сәләтле, талантлы кеше иде. Байлар, муллалар нәселеннән авылның иң беренче комсомолы, күршесе, комсомол Әхсән Зульмиев белән дуслар. Бер урам малайлары, йортлары – урам аркылы гына. Яңа хакимиятнең башсыз, кансыз икәнен тиз аңлап алып, Гали Тукай йөзен үзгәртеп, «пролетарий» булып китеп, большевикларга тырышып эшләп яши башлый. Комсомолга керә, үзешчән драмтүгәрәк оештырып, клуб ителгән Гобәйдулла мулла йортында байларны сүккән, муллалардан көлгән спектакльләрдә артист булып уйный башлый. Колхозлар төзелә башлагач, Эстәрлетамакка барып, өч айлык курсларда укып, тракторчы була. Үзе кебек Гайни Сукыр дигән абзый белән (Кылый Ишбулдин) Эстәрлетамактан Америкада ясалган «Фордзон» тракторы алып кайта. МТС әле юк. Капар Сәббахы кушаматлы-атлы абзый сөйләгәннән:

— Гөмбәз яланында Гали Тукай белән Гани Сукыр «Фордзон» исемле трактор белән җир сөрә. Теге трактор өч төрәнле сабан тарта. Тракторның дүрт тәгәрмәче дә тоташ тимер. Тракторчы утыра торган урын да тимердән. Утыргычта Гани абзыйның бишмәтен дүрткә бөкләп салганнар... Без дә бәләкәй түгел инде. Ундүрт-унбиш яшь.

Җир сөргәндә теге трахтырның су насосы ватылган. Моторы кыза, ә суытырга моторга су килми. Минем кебек дүрт малайны ярдәмгә сораган Гали Тукай. Икешәр чиләк булсын һәрберсендә, дигән. Ике малай – сөргән җирнең бер башында, тагын икесе шул җирнең икенче башында. Тегеләр пар бөркетеп, трахтырлары белән кыр башына өч төрәнле сабан белән җир сөреп килеп җитәләр. Туктыйлар. Без ике малай дүрт чиләк су белән тегеләрне көтеп торабыз. Теге дүрт чиләк суны мотор өстенә азлап-азлап агызып, кызган моторны суык су белән суыталар. Китәләр борылып кырның

теге очына. Анда тагын ике малай дүрт чиләк су белән көтә...

Бер атна эшләдек куышта йоклап. Шуннан, Эстәрлетамактан килеп, теге насосны яңага алмаштырып киттеләр...

***

Сугыш алдыннан Гали Тукай колхоз клубында мөдир булды. Ул куйган спектакльләр бүген дә минем күз алдымда. Зур татар театры куйган спектакльләр барысы да куелды. Беренче спектакльне мәдрәсә мөдәррисе (җитәкчесе) Мөхәммәт Шакир Тукаев Ырынбурдан алып кайткан. Ул авылда аклар вакытында куелган һәм мин аны 1918 елның көзе яисә 1919 елның март-апреле булгандыр, дип уйлыйм. Чөнки 1918 елның җәендә кызыллар чигенгәннәр һәм Эстәрлебашка 1919 елның июнь азагында гына кире әйләнеп кайтканнар. Ул спектакль «Галиябану» булган. Галиябануны Шакир Тукаевның уналты яшьлек төпчек кызы Хәлимә, ә Хәлилне Төрекләр нәселеннән унсигез яшьлек Ибраһим Төхфәтуллин уйнаган. 1952 елны мин Иркутскига киткәндә ул безнең судта адвокат булып эшли иде.

Шул 1918 елдан бирле Эстәрлебашта үзешчән драмтүгәрәк эшли. Минем «41нең арбалы хатыннары» исемле спектакльне Эстәрлебашта 2005 елның 5 маенда беренче мәртәбә куйдылар. Уңышы – искиткеч!

Гали абый колхоз клубында (авыл уртасында элекке мәчет бинасында районның Сталин исемендәге икенче зур клубы бар иде, тик ул Гали абый җитәкләгән колхоз клубы белән ярыша алмый – бик йомшак эшли иде) куйган спектакльләрдән истә калганнары:

«Көнлекче Әхмәт һәм аның чибәр хатыны», «Банкрот», «Бәхетсез егет», «Чаткылар», «Шәгурә».

«Галиябану» спектаклен куйганда без өчәү (мин дә) сәхнә декорациясе өчен читән үрдек: аяклары (икесе дә) эчкә карап торган Камәр бабай, Гали абый һәм мин. Камәр бабай үрә башлый да, 2-3 казык узгач, үргән талын Гали абыйга бирә, талның очы ярты – бер метр чамасы калгач, Гали абый аны миңа тапшыра. Тал керә торган соңгы ике-өч казык – минеке. Кичен бездә чәй эчкәндә Гали абый мине әтигә мактый:

— Илләмә дә шәп бу улың, Лотфулла абзый. Кискән чакта талны йөгерә-йөгерә ташый. Өстәвенә, матур итеп үрә дә белә!

***

Миңа – дүрт яшь. Безнең «8 Март» колхозында алты бригада. Бишесе – безнең авылда, алтынчысы – бездән өч чакрымда утырган Урман авылы исемле башкорт авылында. Колхоз идарәсенең урамга чыккан ике тәрәзәсе арасына Гали абый зур бер плакат төшереп элгән. Эштә ярышып, кайсы бригада ничәнче урын алуы турында ул. Беренче урын – самолет очып бара, икенче урын – поезд тарткан паровоз, өченче урын – автомобиль, дүртенче урын – ат менгән җайдак, бишенче урын – ишәккә атланган чабата кигән бер абзый, алтынчы урын – мүкәйләп барган бер кеше...

Атнага бер мәртәбә кем беренче, кем мүкәйләгән – алмаштырып торалар.

Гали абый такмаклар чыгара. Артист Абдулла абый Рафиков аларны көлке итеп, төрле көйгә салып, сәхнәдән такмаклый. Берсе генә истә калган:

Пирвыйлар пируг ашый,
Фтаруйлар – пәрәмәч.
Тритийлар ашый алмый
Трудлары булмагач.

***

Гали абыйны сугышка алып киттеләр. Ул 1942 елның көзендә Воронеж каласында һәлак булган. Сугыштан плен үтеп кайткан Самат абый Гали абыйның ничек һәлак булганын күргән:

— Дүрт катлы йортның иң өске катын-

да почмактагы бер бүлмәдә алты кеше урнашканбыз. Кич үзебезнең урамдагы солдат кухнясыннан ашарга алып керәбез дә, өстәл тирәли җыйналып ашыйбыз, примуста чәй кайнатып эчәбез. Һәрберебезнең үз урыны. Гали абзыйныкы исә иң түрдә, почмакта. Бер кичне, Гали абыйны үртәп, барып утырдым бит аның урынына. Ул нигәдер азрак соңлабрак кайтты. Кайтты, кулларын юды, өстәл янына килде дә мине үзе утыра торган урыннан куа:

— Самат! Куч үз урыныңа. Тәһарәтсез артың белән ничек смит итеп утырдың син минем урынга?

Мин кучтем. Ашап, чәй эчәргә генә тотынган идек, һич көтмәгәндә немец самолетлары килеп, бомба ташлый башлады. Берсе без утырган йортның почмагына килеп төшкән. Гали абзый утырган почмак бомба шартлаганнан кителеп, йорттан аерылып төшә башлады. Гали абзый калкынып карады, булмады.

Кычкырды бичара:

— Хушыгыз, егетләр! Мин киттем...

Төштек мәетен эзләргә. Икенче катка кадәр – ватык кирпеч... Ике йортны бомба белән ватып, өйгән дә куйган...

***

Гали абый белән Мәрхәбә апа яшәгән йорт бер ун ел элек бар иде әле. Анда читтән килгән пимачы Гарифның улы Нури абый пима баса торган остаханә ясаган иде. Гали абыйларның өч кызы бар иде: Вәсилә, Роза, Лия. Ике зурысы юк бугай инде, ә Лияне Салаватта яши, диләр...

Менә шундый Габтукай бабай нәселеннән, байлар, сәүдәгәрләр, ишаннар, алпавытлар, хәлфәләр, генераллар, мөдәррисләр нәселеннән чыккан чын татар, асыл абый бар иде борынгы Эстәрле-Каргалы авылында. 1775 елга кадәр Эстәрлебаш авылының исеме Каргалы булган. Урыс хакимияте ул исемне бездән тартып алып, Ырынбурдан унсигез чакрымга төньяктарак утырган Сәет Слободасына кушкан. Ул – бүгенге Каргалы... ■

Маликов Миргалим Шәйхрази улы турында «Хәтер» китабында (Казан, 1994) кыска гына белешмә бирелгән: «Маликов Миргалим Разиевич, 1911, д. Азметьево (Ахуново), моб. Камышевским РВК, ст. с-т, 992 сп, 306 сд, погиб 23.12.1943. пох.: Витебская обл., Суражский р-р, д.Питовка.»

Аның гаиләсе – хатыны Фатыйма, кызы Гүзәл белән 1989 елдан бер йортта күршеләр булып яшәдек. Аларның икесен дә, тәрбияләп, соңгы юлга озатырга да безгә насыйп булды. Гүзәл апа Маликова 2012 елда әтисе турында тулырак мәгълүмат алу теләге белән Казан Кремлендәге «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы Музей-мемориалы»на мөрәҗәгать иткән булган. Аннан алынган хаттан күренгәнчә, ул фронтта Миргам Разиевич булып йөргән. 306 нчы укчы дивизиясендә командир булган. Витебск өлкәсенең Сураж районы Витовка авылыннан 200 метрлап төньяктарак урнашкан 57 нче туганнар каберлегендә күмелгән.

Миргалим Маликовның сугышка кадәр эшчәнлеге Калинин районында чыгучы «Сталин юлыннан» газетасы белән бәйле. Ул 1936 елда район газетасына техник секретарь эшенә кабул ителеп, җаваплы секретарь вазифасына кадәр үсә. 1941 елның 18 августында шуннан сугышка китә.

Гүзәл апа әтисез үткән балачагын бик сызланып искә ала иде. Авылданавылга йөреп башлангыч сыйныфларда укыткан әнисе Фатыйма апаның балаларын чир-чипәттән саклау өчен

«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры урынбасары Сөмбел Таишева (язма авторы Илсөяр Хәйруллина кызы) М.Маликовның шәхси әйберләрен Актаныш музее директоры Мирсил Мәгыйз улы Әһлетдиновка тапшыра

Солдат

(Актаныш музеена – истәлекле әйберләр)

вакыты да, көче дә җитмәгәндер. Әтиләреннән өч яшьтә калган малайлары үлеп китә. Ә тугыз яшьлек Гүзәлне әнисе, күрше авылдан эштән кайткач, моргтан – үлеләр арасыннан табып, коткарып кала. Бу гаилә сугыш зәхмәтенең барлык җәбер-җәфасын, егерменче-егерме беренче гасырдагы кискен үзгәрешләрне үз тормышы аша чорга ярашлы рәвештә уздыра, дисәк, дөрес булыр. Гүзәл апа эшли-эшли укып, югары белем алган, КПСС сафларында торган кеше. Соңгы унбиш-егерме елда ул, мәдрәсә тәмамлап, Киров районы мәчетләренең берсендә өлкәннәргә һәм сабыйларга дин сабагы бирде.

Маликова Фатыйма Минһаҗетдин кызы Казанның Сухая река зиратында, Маликова Гүзәл (1934, 14 март) 2014 елның 18 августында Казанның Петровский бистәсе зиратында җирләнде.

Мин бу гаиләнең яшәү рәвешен белдергән, кечкенә генә фатирларында канлы сугышта шәһит киткән этиләренең истәлеге буларак сакланган кайбер әйберләрне һәм документларны Актаныш музеена тапшыру дөрес булыр, дип саныйм. Экспонат буларак залга куелмаган очракта да, болар музей фондында сакланып, яшь буынга егерменче гасырдагы тормышны, кешеләр язмышын күз алдына китерергә булышыр, дип ышанасы килә.

Хөрмәт белән,

Илсөяр Хәйруллина.
Татарстан һәм Россия журналистлар берлекләре әгъзасы,
Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре

Искәрмә:

Актаныш музеена тапшырылган әйберләр:

1.Громофон;
2. Аяклы тегү машинасы;
3. Сержант Маликов Миргалим Шәйхразый улының дивар рәсеме;
4. «Хәтер» китабы;
5. «Коръән» китабы, Маликовларның кайбер документлары (хезмәт кенәгәләре, рәсми хатлар, Шаһадәтнамә һ.б., таныклыклар), истәлек билгесе, фотолар. ■

Өч дус – өч шагыйрь. Сулдан уңга: Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Фәхрелислам Агиев. 1908 ел

Кол Гали, Сәйф Сараи, Котб, Мөхәммәдьяр, Габделҗаббар Кандалый кебек титаннары булган, берсе-берсе энҗегә тиң йөзәрләгән асыл исемнәрне хәтерләгән, аларның бибаһа мирасын саклаган меңьеллык әдәбиятка тыйнак иҗатың белән кушылырга батырчылык итү – яшь каләм иясеннән кыю йөрәк, үтә тәвәккәллек, бәлки, төптәнрәк уйлап карасаң, күпмедер дәрәҗәдә оятсызлык, әрсезлек, хәтта ки, ихтимал, әдәпсезлек тә сорыйдыр.

Мин белгән Тукай

Рүзәл Мөхәммәтша

Син илгә-көнгә күренеп, газиз туган телеңдә тәү мәртәбә тартынып кына «әннә» дигәнче (хәреф төртә башлаганчы димим дә!) бихисап игелекле эшләр эшләп бакыйлыкка тоташкан әлгәреләрне телгә алу исә, алар турында нинди дә булса фикер әйтү – үзеңнән икеләтә, өчләтә, бишләтә кыюлык вә шуның кадәр үк әле генә санап киткән башка сыйфатларны дәгъвалый. Мин дә менә аңлапмы, аңламыйчамы, Габдулла Тукай һәм аның бүгенге яшьләргә тәэсире, йогынтысы турында уйларга алындым да, Кафтауны кочарга теләп арлы-бирле йөренгән бер бичара дәрвиш халәтендә гаҗиз калдым. Нишләргә? Кайдан башларга?

Ихтимал,

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп
кашсыз йөзек, –
Без аның бик зур фәһерле,
чын бриллиант кашлары! –

дигәндә олуг шагыйребез 16-40 яшьләр арасында җан асраган гомум массаны күз алдында тотмагандыр, икенче бер әсәрендә ассызыклаганча, «чын яшь егетләр (*кызлар да, билгеле* – **Р.М.**), интеллигентлар» – җәдиди карашлы шәкертләр, гимназистлар, язучылар, артистлар, музыкантлар һ.б. турында әйткәндер. Бүген халыкның, бигрәк тә балаларның, үсмерләрнең зиһен, аңбелем, хәтер, тарих, әдәбият, мәдәният мәсьәләсендә яктылык тизлеге белән таш гасырга чигенүен исәпкә алсаң, билгеле, гавамга Габдулла Тукайның төп иҗаты (ягъни, бозтауның ас катламы) нәмәгълүм дә, кызыксыз да, кирәксез дә икәнен күрәсең. Бу аяныч хәл, рәхмәт төшкере, минем алда торган бурычны беркадәр җиңеләйтә: бүгенге буыннар шагыйрьнең әсәрләрен белмәгәндә ул әсәрләрнең әлеге буыннарга нинди тәэсире турында сөйләргә мөмкин инде? Язмышына, киләчәгенә, үткәненә үзләре

үк битараф икән, без дә аларны борчымыйк, планшетларында «Angry Birds» уйный бирсеннәр. Шөкер, кечкенә дә төш кенә, дигәндәй, акыллы, гыйлемле, өметле яшьләребез дә юк түгел. Менә аларга Тукайның тәэсире нинди булуы турында фикер йөртеп карарга мөмкин. Ләкин монда да, билгеле, автор үзенең гаять тар субъективлыгыннан котыла алмас.

Күренекле галимебез Фәрит Бәшир бер язмасында *«Заманнар үзгәрүгә мөнәсәбәттә күп социаль принциплар, идеологик доктриналар җимерелде, юкка чыкты, трансформацияләнде. Әмма нинди генә этапта да, кайсы гына чорда да татар иҗтимагый-мәдәни тормышында Тукай иҗаты, аның шәхесе һәрдаим игътибар үзәгендә кала килде»*, – дип яза. Дөрес сүзгә җавап юк: әдәбият тарихыннан Габдулла Тукайның вакбуржуаз шагыйрь, демократ-шагыйрь, инкыйлабчы-шагыйрь, атеист-шагыйрь булуын укып белсәк, тора-бара аның акрын гына милләтче һәм иманлы, динле шагыйрьгә кайта барганын үз күзләребез белән күрдек. Әдибебезнең һәрчак, һәр заманда янәшә, янда калуы куанычлы фал, әмма моның кадәр баш әйләндергеч үзгәрешләр кичерүе (үзе теләмәстән, дип ассызыклыйм, чөнки бездә үзе теләп иман яңартканнар күпме бит әле!) аңа файдага булдымы икән? Билгеле, «Тукай бик бәхетле, ул бер чорда да онытылмады, онытылмый да», дип куанышырга, бер-береңне котлашырга мөмкин. Котлашабыз да. Ләкин болар барысы да шагыйребезгә кирәк идеме икән соң? Ул моңа мохтаҗ идеме?

Алман галиме Михаэль Фридрих татар җәмәгатьчелегенең Габдулла Тукайны үлгәч үк арзанайта башлавы (бәлки, бу урында «брендка әверелдерүе» дип купшыландырсаң, заманчалаштырсаң да ярыйдыр) турында яза – әйтик, нашир һәм сәүдәгәр Шәрәфләр, ялгышмасам, 1913 елда ук «Тукай» сабыны чыгара башлый. «Тукай» конфетлары


Въ Казанскій Временный Комитетъ
по дѣламъ печати.

Представляя при семъ 4-ую тетрадь „Стихотвореній Абдуллы Тукаева" на татар. яз., напечатанную 1907 г. въ г. Казани, въ электро-типографіи Шарафъ, на счетъ книжнаго магазина „Стихотворенія" и содержащую въ себѣ 56 стран. въ 12 д. л. и въ 2 экз., на 7 стран. во 2-ую д. л. писчей бумаги каждый, русскій переводъ 6 стихотвореній, помѣщенныхъ въ брошюрѣ на стран. 7–8, 23–24, 24–26, 30–32, 37–38 и 41–46, имѣю честь обратиться въ Комитетъ съ покорнѣйшей просьбой не найдетъ-ли онъ нужнымъ наложить на брошюру арестъ на основаніи переведенныхъ много [illegible], встрѣчающихся и въ арестуемыхъ рукописяхъ.

Членъ Казанскаго Временнаго Комитета по дѣламъ печати Н. Катановъ

НОЯ 1911
№ 1286

Матбугат эшләре буенча Вакытлы Комитет әгъзасы Н.Ф.Катановның шул ук комитетка Габдулла Тукайның 1907 елгы шигырьләренә арест салуны сорап язган мөрәҗәгате. 1911 ел

дөнья күрә. Авыл халкын кан елатып күмәкләштерелгән хуҗалыклар (колхозлар) тора-бара Тукай исемен йөртүгә барып җитә, туксанынчы елларда Тукайны инде татарга каршы җигәргә дә чирканмыйлар: мәсәлән, «Китмибез» шигыре тәрҗемәсенең «Вот с этой русскою землей сама судьба связала нас» дигән юлы (ничек «Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйззе вә җәл)» гыйбарәсен шулай тәрҗемә итеп була?!) 1992 елның бер карагруһ митингында өндәмә итеп күтәрелә. Үткән эшкә салават, дип кул селтәргә бик мөмкин тоелыр иде, әмма бүгенге хакыйкать тә шактый ачы шул: былтыргы көзнең «Урыс маршы»нда катнашкан унбишләп кеше иң алдан янә, «Татары – это часть русского мира», дип... Тукаебызның сурәтен күтәреп барды...

Убылып төшкән фикерләр пирамидасының кайбер кирпечләрен

нигә шулай дикъкать илә алып, капшап, сурәтләп бимазаланаммы? Җавап бик гади: кирәксә-кирәкмәсә шагыйрь исеме белән авыз чайкау, вазгыятькә карап «тугры Тукайны»ң, Шомбай сыман, киемен алыштыру, аннан таран яисә калкан ясау үзенең кире эшен эшләде һәм эшли килә: әдәби умырткалары ныгымаган яшьләр, Дәрдемәндне, Һади Такташны, Хәсән Туфанны өлге итеп алганда да, Габдулла Тукайны, ким дигәндә, күрмәмешкә, белмәмешкә сабышуны хуп күрә, аны җитдигә алмый. Ким димәгәндә исә, турыдан-туры яманларга да күп сорамый. («Яраткан шагыйрьләрең кем?» дигәнгә өченче сыйныф укучысыдай «Габдулла Тукай», дип җавап бирүне, мәсәлән, балигълыкка яңа кергән «әһле каләм», тәгаен, хурлык санаячак.)

Бу җәһәттән бер хатирәне искә төшереп үтсәк, артык булмас, минемчә. Үзе Тукайны күз өстендәге каштай күргән Фәнзаман Баттал хәзер бәян ителәсе очракны гарьләнеп тә, әрнеп тә, кисәтеп тә сөйләргә ярата иде. Сиксәненче еллар башы... Кояшлы, чалт аяз көн, матур, хозурлык! Шунда яңа гына Язучылар берлегенә алынган яшь шагыйрьне очрата бу. Котларга уйлый, билгеле:

– Син бәхетле, энем! Синең яшьтә Тукай белән тиңләшү турында да хыялланырга мөмкин әле! Чөнки аның яшенә җитәргә дә биш-алты ел вакытың бар...

– Юк-бар сөйләмә инде, Фәнзаман абый, – дигән баягы егет. – Атом гасырында яшәп, чабаталы гасыр Тукае дәрәҗәсендә калсам, нинди генә шагыйрь булам соң инде мин?

Абзый кеше күңелсез бу хатирәгә: «Тораташ катып, өнсез басып калдым, кояш та юк миңа, күз дә күрми», – дип нокта куя иде.

Без фәкыйрегезне яшь шагыйрьнең җавабы бер дә гаҗәпләндерми. Ә минә өлкән каләмдәшеңә шулай ни уйлаганыңны турысын ярып әйтү, икейөзлеләнеп маташмау тирән ихтирам уята. Чөнки, гафу итегез, андый фикерләр миндә дә тумады түгел. Үтә торган нәрсә ул.

Күңелдә шагыйрьнең триумфы соңрак башлана-а!.. Азатлык хиседәй иркен, киң, тарихи хәтердәй тирән, төпсез Тукай диңгезенең чоңгылы суырып ала үзенә: авызга-борынга тула, тончыгасың, ярга чыгам, дип колач җәясең, ишәсең, ишәсең, әмма беләкләрең генә ныграк талчыга һәм әдәбиятның һәр жанрын бертигез күккә, илаһияткә тераеп күтәргән Атлант иҗатына ныграк батасың гына... Кичерәсең! Үзе таныганча, «американизировать» ителгән «Кичке азан»нар, бозаудан ахмак төрек шыгырдаучылырына ишәктән тиле тәкълидләр, «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф» кеби, инсан авызыннан чыкмаган диярлек тәркибләр, тагы шундый кабахәтләр»не[1] – барысын да кичерәсең! Беренчедән, баягы өзектә Тукай вөҗүденә, үз иҗатына катырак бәрелеп ташлаган, әлбәттә. Тукайча катырак бәрелеп. Ул чор, аның кешеләре, җәмгыяте, дөнья, ил, милләт эчендәге вазгыятьне, аның ихтыяҗларын, теләкләрен, өметләрен исәпкә алганда, әдипнең хәтта иң җитешсез һәм ашык-пошык сырланган ике җөмләсе дә дөрес вакытта, дөрес урында килеп, хәлиткеч вазифа башкарырга мөмкин булган. Һәм даими башкарган да. Бәгъзе көндәшләренең Габдулла әфәндене «тәрҗемәче», «тәкълидче» дип кимсетергә тырышуында да һичнинди гаеп юк: урысча бигүк укымаган татар галәме өчен ул чакта татарча Кольцов та, татарча Пушкин да, татарча Толстой да, татарча Крылов та, татарча Лермонтов та кирәк иде. Көн кадагына сугып барган мизгеллек шигырьләре дә кирәк иде аның!

[1] Габдулла Тукайның «Уянгач беренче эшем» (1913) мәкаләсеннән.

Икенчедән, әдипнең кабатланмас, үзенә кадәр дә, үзеннән соң да иҗат ителмәгәнчә көчле, затлы, илаһи мәхәббәт лирикасы да бар бит әле! Аңардан тән кымырҗый, йөрәк кысылып-кысылып, бөрешеп-бөрешеп куя, ә күңелдә миллион тойгы берьюлы тантана итә: шаккату, соклану, куану, ләззәт, курку, шөбһәләнү, көнләшү...

Кашки, Тукай – шигърият кенә түгел. Тукай ул проза да, яшәгән дәвере дә, реакция еллары да, салкын «Болгар» номерлары да, «Әлислах» газетасы да, Печән базары да, Ишми ишан, Садри Максуди да, Дөмбер карчык йортлары да, тугрылыгы да, кирелеге дә, шапшаклыгы да, чандырлыгы да, күзендәге агы да – барысы да Тукай. Шуларны кушып кына чын Тукайны тулаем күз алдына китерергә мөмкин. Шулар барысы оешкан, укмашкан, берләшкән очракта гына Пәйгамбәр Тукай барлыкка килә.

Вәләкин... Вәләкин...

Күпме гомер узуга, аннан соң дөньялыкка күпме шагыйрь-шогара килеп китүенә карамастан, Габдулла хәзрәтләренең һаман актуаль, мөһим булып калуы – куаныч, димәс идем. Ун дистә елдан соң да «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» соравының арка йонын кабартып басуы, әледән-әле «кара йөзләрнең безне булмас эшкә тәклиф итүе», «аристократсорыкортларның» башыбызга «чыгып искене бушатулары», хезмәтебезне, намусыбызны «көнен сартир, төнен сартир» кылулары, «тотып мәскәүләр якамыз», татарча сүгенгән өчен дә «даже в тюрьму сыйдырулары», һәм башкалар, һәм башкалар гаять күңелсез нәтиҗәгә китерә – һичнәрсә үзгәрмәгән икән лә! Гасыр кадәр гасыр буена вазгыять сыңар тамчыга да үзгәрмәгән! Мондый хәлнең ничек аталуы миңача да күп әйтелгән инде, кабатлыйм гына: фаҗига. Тукайның фаҗигасе бу. Безнең фаҗигабез!

Әйтәсе сүзләремне тәмамлауга барганда, шуңа да игътибар юнәтимче: Ләбиб Лерон бер эпиграммасында «Кыенсынып кына Тукай яшен узып барган» һәм «кылган эшләренә баксаң – оятрак» булган берничә шагыйрьне чеметеп ала, аларның бертөсле фикер йөртүе, шигырь юлларының, бер-берсеннән күчереп алгандай, охшаш булуыннан көлә. Мин дә бүген шул яшьтә. Һәм... минем дә шундый ук уйларга баткан чагым. Аннан берничек котылып булмый! Тукай – түшәм. Тукай – планка. Тукай – критерий. Кем мин? Нишләдем? Ни кырдым? Сыйфаты? Күләме? Халыкка тәэсире? Нәтиҗә бер, бөегебез безнең өчен әллә кайчан җавап биргән инде гүя: «Кайгысыннан зиһене тәмам чуалып, кая басар җир тапмый, бер басасын биш баса». Акланулар эзлисең: әдәбиятка мөнәсәбәт начар, яшәү кыйммәткә төшә, дөнья акча артыннан кудыра, гаилә, балалар... Ләкин шулай уйлап куюың гына була, тарих кара плащтан каршыңа басып, уттай кайнар хакыйкатен маңгаеңа терәп ата: ә Тукай соң?! Ул җиңелрәк, уңайлырак шартларда яшәгәнме әллә?!

Аны яшьтәш санап булмый. Һәрдаим киңәш-табыш сорап килгән аксакал картны (мәңге егерме җиде яшьлек аксакал картны!) ничек «яшьти» дияргә җөрьәт итмәк кирәк?

Каләм очыннан бик күптән дәфтәргә тамган бер шигыремдә «катырак янганга иртәрәк сүнәсе» дигән юллар бар икән. Тукайга тач туры килә бу. Шашынып, котырынып, ярсуланып, ачуланып янды да... өреп сүндергәндәй – пылт! – көн күзендә эреде, юкка чыкты.

Килде. Җәт кенә эшен бетерде. Китте.

Менә бусы бәхете аның. Юкса, Җир йөзенә нәрсәгә килгәнен дә белмичә, эленке-салынкы кыяфәттә юкны бушка аударып, эш юкта эш булсын, дип ат тизәге тибеп йөрүчеләр азмы бездә? Илаһ шундый язмыш биреп җәберләмәсен иде. ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

ОХЛОКРАТИЯ – Борынгы грек телендәге охлос кара халык, гавам, толпа'+кротос 'хакимлек' сүзләреннән оешкан термин. Платон/Әфләтун һәм Аристотель/Аристоның дәүләт турындагы тәгълиматларында *демократиядән* – халык хакимлегеннән үзгә «толпа, урам хакимлеге». Оешмаган, фетнәчел халык массаларының вакытлыча хакимияткә килүе, шундый төркемнең хөкүмәт органнары каршына системасыз социаль-экономик һәм сәяси таләпләр куюы.

Тагын кара: ***Демократия.***

ОЧАКОВ – Украинадагы шәһәр. Яңа эрага кадәр борынгы грек телендә *Алектор* дип аталган. 1492 елдан *Каракирмән* дигән төрек ныгытмасы була, аннары *Учак* (Очак) дип атала

Очаков (Oczakow) Герберштейн картасында. 1549 ел

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

башлый. 1789 елда Россиягә кушылганнан соң – *Очаков.*

ОЧРАК – Булган хәл, вакыйга, маҗара. Философиядә һәм математикада (мәс., ихтималлык теориясендә) бу сүзнең «көтелмәгәндә килеп чыккан хәл» дигән мәгънәсе мөһим роль уйный. Рус телендә – *случай, оказия* (бусы латин теленнән кергән сүз). *//Сукыр очрак* (Шәйхи Маннурда очрый торган төшенчә). *Ни соң ул очрак? Буш сүз ул, наданлык шуның артына яшеренә, ялкау акылның хәйләсе ул. Табигатьтә очрак дигән нәрсә бармыни? Ул мөмкинмени? Сәбәпсез гамәл мөмкинмени?* Климент Тимирязев, рус галиме, биолог. Тимирязев бик нык ялгышкан, чөнки табигатьтәге барлык эволюцион һәм революцион үзгәрешләр гамәлгә ашкан очраклар чылбырыннан башка нәрсә түгел.

ОЯТ – Төп мәгънәсе – «Берәр начарлык, гаеп *[гөнаһ]* эш эшләүне аңлаудан туган көчле уңайсызлану, үкенү хисе» («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән). Хәбәр функциясендә *уңайсыз, читен* мәгънәсен бирә. Рифкать Әхмәтҗанов бу сүз нindидер борынгы ойа дигән фигыль тамырыннан, дип фараз итә һәм моңа дәлилләр китерә. Охшаш тамырлы сүз, мәсәлән, себер татарлары телендә бар (*ойан* – оялчан). *//Оят качу. Оят өлеше* – кунаклар ашаганнан соң савыт төбендә калган ашамлык. *Оят сату* – фахишәлек итү. *Ләкин, оятыбызга каршы, ул үсешне бик аз җырлавыбызны сиздек.* Һ.Такташ. *Хәер! Ягкуп Галиев вә Маһруй оят вә әҗнәби кемсәнәләрдер.* Заһир Бигиев.

ӨЛКӘР – Борынгы төрки телдә – *Үлкәр*. Гадәттә *Иләк йолдыз* дип атыйлар. Борынгы төркиләр аны, иң якты йолдызлары санынча, *Алты йолдыз* дип йөрткәннәр.

Кайбер комментаторлар Өлкәрнең мәгънәсен «өлкән» сүзе белән аңлатырга тырышалар («зур йолдыз төркеме».)

«Иләк йолдыз», «Иләк» – күзгә ташланып тора торган йолдызлар төркеме, ләкин астрономиядә ул аерым йолдызлык дип исәпләнми, бәлки *Үгезбозау* йолдызлыгына карый, ә элекке бүленеш буенча Кучкар йолдызлыгына кергән; төркемдә гади күз белән 6дан алып 9га кадәр йолдызны күреп була, оптик инструментлардан караганда йолдызлар саны 250гә җитә). Гарәпчәсе – *Сөрәйя* (Кандил, Люстра), фарсыча – *Парвин*. «Татар исемнәре сүзлеге»ндә Өлкәрне *Җәббар* дип атау очрый, ләкин чынлыкта Җәббар йолдызлыгы – *Орион.*

//Йәнә Үлкәр мәңиз йыглышиты анлар – Кабат Өлкәр йолдызлары кебек җыелыштылар алар. Борынгы тексттан. *Өлкәр чәриг* – таралып урнашкан гаскәрләрне Өлкәр кебек бергә туплау.

Борынгыдан килгән халык календарендә *маймыл – мачин елы* бар. Бу елны корылык килә, зәһәр суыклар була, мал-туар кырыла, имеш. Боларның барысына да Мачин дигән явыз рух сәбәпче икән. Шуңа күрә терлекләр дә аны яратмаганнар һәм бервакыт йоклап яткан Мачинны таптап измәкче булганнар, ди. Әмма Мачин бик җитез булып чыккан һәм, алты кисәккә таралып, күккә ашкан. Шул кисәкләрдән Өлкәр йолдыз барлыкка килгән, имеш. Икенче бер мифка караганда, баштарак бу Өлкәр йолдызлыгында җиде йолдыз булып, алар җиргә бик күп суыклар җибәреп торганнар. Шуннан соң җирдәге җан ияләре Өлкәрнең бер йолдызын урлаганнар һәм суыклар кими төшкән.

«Өлкәр җиргә төшкәндә, сыер суга төшәр», дигән сүз бар. Бу әйтем Өлкәр йолдызлыгы офыкта күренгән вакытның иң эссе чак (?) булуына ишарәли, диләр.

Тагын кара: ***Парвин. Сөрәйя.***

Изге Коръән китабы



ӨММЕЛ-ВӘЛӘД *г.* – Бала анасы. Электә гарәпләрдә үзенең хуҗасыннан бала тапкан кәнизәк. Хокукый яктан *өммел-ибннән*, ягъни угыл анасыннан – ирекле хатыннан аерылган. Исламга кадәр һәм Ислам тарала башлаган елларда өммел-вәләдне башка коллардан аерып йөртү булмаган әле. Гомәр бин әл-Хәттаб (634-644) хәлифә заманында аларны сату һәм башка кешегә бирү тыела. Әгәр дә аның хуҗасы ул тапкан баланы үзенеке дип таныса, кол хатын ирекле дип саналган. Әгәр танымаса, ана да, бала да гадәти коллар исәбендә булганнар. Хуҗасы исән вакытта өммел-вәләд аңа карата гына кол булып, хуҗасының вафатыннан соң тулысынча ирекле хисапланган. Әгәр кол хатын көмәнле килеш сатылган булып, бу хәл билгеле бер вакыт узганчы беленсә, кол хатынны элекке хуҗасына кире кайтарганнар, ягъни сату гамәлдән чыгарылган.

ӨММЕЛ-КИТАБ *г.* – Бу сүз «Коръән тәфсире»ндә «Китаплар анасы» дип тәрҗемә итеп бирелә. Бу очракта ул «Коръән» мәгънәсендә килә. Мәүлана Мөхәммәд Али исә аны «китапның төп нөсхәсе, оригиналы» дип тәрҗемә иткән. Еш кына «Фатиха» сүрәсен «Өммүл», «Өммел-китаб» дип атау очрый.

ПАЗАРДЖИК – Көньяк Болгариядәге шәһәр. XIV гасырда барлыкка килеп, 1934 елга кадәр *Татар Пазарджик* дип аталган («Татар базарлыгы»).

ПАКЬ СУ – Агым сулар (чишмә һәм елга-инеш сулары), күл, диңгез һәм кое сулары, яңгыр һәм кар-боз сулары *пакь су* дип, ягъни тәһарәткә ярарлык су дип исәпләнә. Ат, сыер һәм сарык кебек ите хәләл хайваннар эчкәннән соң савытта калган су да пакьтер.

ПАКЬ ҺӘМ НАПАКЬ БАЛАЛАР – Шәригать буенча, әгәр атасы, анасы, бабасы һәм әбисе кяферләр булса, бала *напакь* дип исәпләнә. Әгәр дә әлеге якыннарыннан берәрсе мөселман була икән, баланы пакь бала дип карыйлар. Ләкин *пакь булу* әле мөселман булу, дигән сүз түгел. Әгәр дә кеше үзенең мөселманмы, әллә юкмы икәнлеген белмәсә, шәригать буенча ул *пакь* дип санала. Дөрес, аңа мөслимәгә өйләнү тыела, аны мөселман зиратында җирләргә дә ярамый. Ул шәригать нигезендә Исламны кабул иткәннән соң гына хак мөселман булып исәпләнә башлый. ■

Татарстан радиосы дулкыннарында 40 елдан артык алып барылган «Тел күрке – сүз» тапшыруларының чишмә башында танылган тел галимнәре белән бергә күренекле язучыларыбыз торды һәм яңа ачылган программабызның халык күңеленә барып җитүендә аларның әһәмияте гаять зур булды. Сибгат Хәким, Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттах, Хәсән Сарьян, Мөхәммәт Мәһдиев, Әбрар Кәримуллин, Равил Фәйзуллин, Рабит Батулла кебек язучыларыбызның чыгышлары тапшыруларыбызда даими яңгырап торды һәм зур кызыксыну уятып, тыңлаучыларның киң игътибарын җәлеп итте, олы ихтирамын казанды. Әдипләр сөйләм серләрен ачарга, аның нечкәлекләренә төшенергә өйрәттеләр, ана телебезгә мәхәббәт тәрбияләп, нинди генә авыр шартлар булмасын, аны күз карасыдай сакларга, киләчәк язмышын кайгыртып яшәргә чакырдылар. Бу язучылар арасында Уфадан милләттәшебез, әдип һәм галим, башкорт әдәбиятының күренекле вәкиле, башкорт мәктәпләре өчен «Әлифба» дәреслеге авторы Йосыф Гәрәй дә бар иде.Ул безнең тапшыруларда туган телебезгә кагылышлы кызыклы һәм гыйбрәтле язмалары белән катнашып килде. Кызганыч, саф татар телендә язылган бу язмаларның бүген безнең кулда тик «Әнием теле – күңелем гөле», «Этнонимнар ни сөйли?», «Чөйгәне шоңкар булган» һәм «Сүзләр озын гомерле» дигәннәре генә сакланып калган. Шуларның берсен – «Әнием теле – күңелем гөле» дип аталганын сезнең игътибарга тәкъдим итәбез.

Рөстәм Акъегет

Әнием теле – күңелем гөле!

Йосыф Гәрәй (1904-1988)

Нинди генә сүзләр юк! Нәфисләре бар. Күңелсезләре. Мөлаемнәре күп. Ачулылары. Хәтта мәкерлеләре йөри телдән-телгә.

Ачык күңелле сүзләр дә бик ишле. Моңлылар да аз түгел. Купшылар, шатлар, ямьсезләр дә җитәрлек.

Кайберләре ялтырап тора. Гүя, зәбәрҗәт! Икенчеләре дөм караңгы. Әйтерсең, мунча ташы.

Бер уйласаң, сүз җанлы кебек. Хәтта кеше кебек алар, бермәл ачык йөзле, бермәл шыксыз чырайлы. Төрле төс ала сүз. Ачу белән әйтелсә, «зифа» дигән сүз дә зифа түгел. Елмаеп туса, «юньсез» дигәне дә күркәм. Калып, тавышлы «нәләт» каргыш икән, шаян «дөмеккере» дә яшәгә тиң.

Шагыйрь гади сүзләрне дә энҗе итеп тезә. Исәр асыл ташны да күмер ясый. Сүз таба алмау оялта. Хурландыра. Тапкыр сүз ышандыра. Данлый.

Елаткан да – сүз, көлдергән дә – сүз. Күтәрә дә ул. Терелтә дә ул. Авыруга да сабыштыра, үтерә дә.

«Бәгырь», «күз нуры», «бер генә» сүзләре булмаса, сөюеңне ничек аңлатыр идең? Алай гына әйтмисең бит әле. «Бәгърем», «бәгырькәем», «бер генәм» дисең. Бер генә хәреф арта. Ә сүз йөрәк җылысына төренә.

«Мөртәт», «хаин», «сатлык җан» сүзләре булмаса, дошман ялчыларын ничек тиргәр идең?

«Былбыл туа, диләр, сайрар өчен,
Кеше туа, имеш, җырлар өчен,
Ләкин сәхнә түгел шул дөньясы,
Туры килә байтак еларга.

Явыз, дип әйтмә бу дөньяны,
Алай әйтмә, иптәш, ярамас.
Ә кеше гомере – көн белән төн,
Бәхет белән михнәт аралаш».

Кешегә шатланганда да, кайгыдан янганда да, бәхет тоярга да, хәсрәт чиккәндә дә сүз кирәк. Шуңа күрә тормышта канатландыра торган сүзләр дә, мәңге төзәлмәс яра салганнары да әйтелә.

Иң матур, иң җылы сүзне иң яраткан, иң якын кеше ишетә. Мәгәр, аяныч, иң пычрак, авыр сүзне дә якын кешегә бәрәләр. Онытa кеше, бахыр. Кичерә, «табак-савыт» шалтырамый булмый, ди. Шалтырау гынамы? Түшәм, диварлар тетри. Ләкин вакыт дигән хәйран калмалы табиб оста дәвалый. Шатлык килә дә кайгыны юа.

Һәммә кеше Галимҗан Ибраһимов яки Әмирхан Еники була алмый. Ләкин сүз кадерен һәр кеше белергә тиеш. Яшьләрнең теле, кызганыч, бик ярлы. Күп сүзне белмиләр. «Белмәү гаеп түгел», диләр. Гаеп, иптәшләр. Бик гаеп. Белергә тырышмаганга белмиләр. «Инсаф, гөрләвек, сагалдырык, селтәм, тут, тәүфыйк, түтә» сүзен дә белмәгәч, ничек сөйләшәсең. (Мин шушы сүзләрне ишетмәгән бер егетне очраттым.)

«Фатыйма», «Гайшә», «Гөлсем»нәрдән, «карчыклар исеме!» дип көлгән кызлар да, «Ибраһим», «Ишкилде», «Фәррәх»ләрне «предки» дип мыскыллаган егетләр дә бар. Ә үзләре кем? «Финат» та «Фәлсәт» яки «Әүфә» дә «Әфидә»! Ымлык та түгел бит болар, ичмасам. Куркылык урынына шулай, ташка үлчим, мәгънәсез «кушамат» тагалар әллә? Ә тарихи исемнәр нинди асыл мәгънәле! Мәсәлән:

Вәсил, Вәсилә – мәгънәсе: аерылмас дус; Газали, Газалия – көчле, буй-сыны күркәм; Ләбиб, Ләбибә – акыллы, зирәк; Нәсим, Нәсимә – кыйбла җиле; Хәбиб, Хәбибә – килбәтле, сөйкемле иптәш һ. б.

Туган тел исемнәргә дә, бүтән сүзләргә дә бай. Бөтен сүз – газиз. Онытылмаса иде ул сүзләр. Һәр төшеп калган сүз телне ярлыландыра. Элек менә аран (арып-талып мәгънәсендә), муллану («мул»дан), матавык (тоткарлык), авык (ягъни бик кыска вакыт, момент мәгънәсендәге) сүзләр булган. Нигәдер онытылганнар. Сүз үлү – аяныч хәл. Әмма дә сүзләр дә үлә шул.

Ат җиккәндә генә дә бик күп әйбер һәм сүз кирәк: дилбегә, тезген, дуга, бавыргалык, чөелдерек, йөгән, авызлык тәртә һ.б. Атлар бик кимеде. Ат җигүчеләр аз. Шуңа бу сүзләр авылда да онытыла баралар. Атлар да, бу сүзләр дә яшәсә иде!

Безнең гомердә генә тутырма (ягъни өйдә ясалган колбаса), кулланма («биш бармак»), кош теле, кәлҗимә, казы дигән ашамлык исемнәре онытылды. Ясасыннар иде әниләр тутырманы, пешсен иде гөбәдияләр. Яшәсен берүк әгълә ашлар һәм аларның атамалары! Дөрес, яңа сүзләр дә туа. Ләкин арага кирәкмәсләре килеп керә. Шуның өчен аларны бик сак сайларга кирәк. Гадәттә, үз телен белмәгән кеше чит сүзгә ябыша. Нигә «доходы күп», дип әйтергә? «Килере» дип була бит. Нигә «носки» дип маташырга. «Оекбаш» бит ул! «Кулымдагы күк яулыгым җитәр микән чатырга?» – дип җырлый идек без.

Телне «икмәк-тозлык» кына белгән «тәрҗемәчеләр» туган телне бик ботарлыйлар. Берәү, «невеселое настроение»не «күңелсез кәеф» дип, кәефне бозды. «Кәеф» күңелле дигән сүз ул. «Күңелсез кәеф» булмый. «Кәеф юк», дип кенә әйтергә иде.

Берәү «Шофер, ты в ответе!» дигәнне «Шофер, син җавапта!» дип тәрҗемә иткән. Бу бит үз телеңнең табигатен белмәү. «Син җаваплы!», «Җаваплылык синең өстә! – диярргә кирәк.

Үз теленең рухын, грамматикалар ачып бирә алмас эчке серләрен тоймаган яшьрәк иптәшләр катлаулырак фикерне инша кылганда абзацларны «күренгәнчә», «билгеле булганча», «әйткәнчә» дип башлыйлар. Бу сүз шәрәмәтләре русның «как видно», «как известно» яки «как сказано» кебек әйтемнәрен бирә алмый. Форма килә, әмма мәгънә килми.

Кайберәүләр «до свидания» дигән тәгъбирне «яңадан күрешкәнгә кадәр исән булыгыз» дип күчереп алганнар. «До свидания»нең эчтәлеге алай түгел. «Яңадан күрешергә язсын» дигән изге теләк ул!. Бездә дә халык: «Сау булыгыз!», «Сәламәт булыгыз!» дип сөйләшә.

«Буларак» сүзен дә байтак иптәшләр урынлы кулланмыйлар. Бер карт миңа хат яза: «Мин сезне язучы буларак беләм», – ди. Кем монда язучы булып чыга? Минме? Хат язучымы? Әлбәттә, хат язучы. «Булачак» сүзе җөмләнең иясенә – субъектка гына карарга тиеш. Ә бу карт аны тәмамлыкка – объектка бәйли. Шуңа ул теләмәгән кире мәгънә туа.

Һәр яхшы сүз хөрмәткә лаек. Һәр сүз үз урынында яхшы. Сүз бит ул – тарих, күзгә күренгән фикер, йөрәк авазы. Сүз күп булсын. Бу кешеләрнең үзара аңлашуын тизләтә, зиннәтли, аныклый.

Сөйләшкәндә төрле сүзләр очрый:
Салкыны бар, була җылысы.
Җылы сүзләр күңел гөле, диләр,
Гөлгә кырау була тегесе...

Серләшкәндә төрле сүзләр чыга.
Ялтырата йөзне кайнары.
Сулган йөзләр хәтта шундый сүздән
Күргәнем бар чәчкә атканны.

Яратыгыз сүзне. Сокланыгыз аңа. Саклагыз. Җыегыз аны. Асылташлар, чәчкәләр җыйган кебек җыегыз. Эзләгез. Табыгыз. Кулланыгыз. Сөйләгәндә авызыгыздан йолдыз чәчегез! Тыңлаучының йөзе яктырсын. Күңелдән энҗе-мәрҗәндәй уйлар, әгъла хисләр тусын.

И гүзәл тел! Син иң башлап,
мин тугач та җиһанга,
Мөлаем елмаю белән
сүз кушучы иң алдан.

И нурлы тел! Һәрвакыт син –
газизе бәгъремнең,
Авылдашым, кулалмашым,
шатлыгым, кайгым минем.

И моңлы тел, и хәзинәм,
фәһемле фикердәшем,
Каләм очлап бирүчем син,
ахирәтем, сердәшем.

И уңганым, бертуганым,
гомерлек якын дустым,
Башка телләрне өйрәткән
хәстәрле укытучым.

Син һәркемне өйрәтәсең
Туган илен сөяргә,
Эшләргә дә, җырларга да,
еларга да, көләргә.

И туган тел! И даһи тел!
И уйларым асылы,
Мең буын бабам-әбиемнең
хисе һәм акылы. ■

Исемнәр, кушаматлар...

Гүзәлия Хаҗиева,
филология фәннәре кандидаты, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре

Телебезнең камил яшәешен, милләтебезнең рухи көчен арттыруда, халкыбызда милли рух тәрбияләүдә язучы тарафыннан сайлап алынган сүзләр, поэтик чаралар һәм аларны оста итеп куллана белү мөһим роль уйный. Әлеге сүзләр, поэтик чаралар уй-кичерешләрне, яшәеш һәм көнкүреш үзенчәлекләрен, әдипнең дөньяга карашын, образларның рухи дөньясын чагылдырырга ярдәм итә. Тел чаралары арсеналыннан отышлы файдалана белү мөһим булып тора. Әлеге тел чаралары арасында ономастик берәмлекләр аеруча әһәмияткә ия. Алар тарихи чыганак ролен үтәп, авторның дөньяга карашын, әдәби логикасын күзалларга мөмкинлек бирәләр, контекст эчендә әдәби бөтенлекнең образлар системасын формалаштыруда катнашалар. Әдәби әсәрләрнең ономастик системасы язучы иҗат лабораториясенең фәлсәфәсен һәм психологиясен яктыртуда да кыйммәтле.

Бу нәүбәттә, Мамадыш районы Кече Кирмән авылында яшәп иҗат итүче Рафаил Газизнең проза әсәрләре игътибарга лаек. Аның әсәрләрендә урын алган ономастик лексика поэтик һәм лингвистик әдәби текст төзелешен формалаштыра торган чараларның берсе булып тора һәм, шул рәвешле, язучының үз стилен барлыкка китерә. Әдип авыл тормышын, хезмәтен тирәнтен аңлап яшәгәнлектән, ул авыл кешеләренең уй-хисләрен, эчке дөньясын яхшы тоемлый һәм иҗатында да шуны ачык чагылдыра. Яшәеш фәлсәфәсе, тормышчанлык, авылның язмышы турындагы борчулар, өлкән буын белән яшь буын арасында бәйләнешнең югалуы турындагы уйлар – болар барысы да язучы, шагыйрь иҗатының төп чишелү көткән проблемаларны тәшкил итәләр. Бу үзенчәлекләр – барысы да әсәр геройларының исемнәрендә, авыл топонимиясендә дә чагылыш тапканнар.

Автор нигездә прототипларының реаль исемнәре белән эш итә. Аның иҗатында уйдырма топонимик, ан-

Рафаил Газиз. Кече Кирмән авылы. Июнь, 2016

тропонимик берәмлекләргә мөрәҗәгать итүе аз күзәтелә. Автор татар авылының дөнья картинасын, чын тормышын, гореф-гадәтләрен аның чын, реаль ономастикасы белән дә күрсәтә диярлек нигез бар: «Куша белгәннәр элек. Чын исеме Шәмсекамәр бит – кояш һәм ай дигән сүз». «Күтәреп мунчага алып барды, сеңлесе Гандәлифә юындыргач, күтәреп алып чыгып, мамык түшәгенә салды». «Сыздырып җибәрде өч тальян: Ибраһим, Хөсәен, Барый абый...» «Егерме бишенче елгылар байтак: Һаҗәр апа, әни, Ибраһим абый, Сәлимә апа, Миргазиз абый, яшьрәк булсалар да, Хөсәен абый белән Сылубикә апа». «Сиңа да үпкә зур, Барыйҗан, чөнки Тәхиятуллада син төзәтеп-көйләп биргән уфалла, артык худлы йөри» («Кичер, кичерә алсаң...»).

Әдип авыл тормышын, хезмәтен тирәнтен аңлап яшәгәнлектән, ул авыл кешеләренең уй-хисләрен, эчке дөньясын яхшы тоемлый һәм иҗатында да шуны ачык чагылдыра.

Язучының сөйләм контекстына кеше исемнәренә -тай/-тәй иркәләү-кечерәйтү кушымчасын кушуы сөйләмгә чынбарлыкның төгәл палитрасын бирергә ярдәм итә. Бу кушымча төрки телләрдә һәм татар диалектларында берлек сандагы тартым кушымчасы нигезендә ясалган, иркәләү-кечерәйтү мәгънәсендә килгән тайым сүзенә бәйләнешле. «Нурлыбикәттәегез пешергән дучмак-

ны өч сынык ашаганнан соң, яхшылап чәй эчеп, эш киемнәрен – халат-мазарларны эләктереп чыктым ишегалдына» («Богзай»). «Фәтхиянең гадәтен белгән Зәкирәттәй» («Хөсәен ничек кайткан?»). Кайбер очракларда автор -тай/-тәй кушымчасының кыскартылган формасына да мөрәҗәгать итә: «Кала сулда Банутти исәнләшеп, кала уңда Васыйл ым кагып». «Камәрти урын өстенә менгәч тә, кайбер кеше кызларыннан да күрмәгән кадер-хөрмәт күрсәтте» («Кичер, кичерә алсаң ...»), «Эшнең чиста түгел икәнен шундук сизгән Фатиматти» («Гаян абый хат укый»). Әдип хикәяләрендә авыл халкында кулланылган реаль кеше исемнәрен генә әсәр тукымасына кертеп калмый, ул күпчелек исемнәрне реаль кушамат белән бергә куллана. Мәгълүм ки, авылда кушамат тагу – ул гадәти күренеш. Авылның дөнья картинасын тагын да киңрәк күзаллау, палитраларын тулырак күрсәтү максатында, автор бу әдәби алымнан оста файдалана. Шул рәвешле, Р.Газизнең хикәяләрендә авыл колориты тагы да куера төшә. Хикәяләрендәге кушаматлар әдәби геройны формалаштыруда, аны образ ясауда иң тәэсирле берәмлекләр, дип саналырга хаклы. Автор әсәрләрендә күптөрле кушаматларны куллана: «Әчегән Хамис», «Хәллә Шәфыйгы», «Норма Сәми», «Күкәр Нигъмәте», «Бүдәнә Салих», «Чүлмәк Вәгыйзь», «Хабыйк Хөсәен», «Күкеле сәгать», «Герман», «Шәһәр Рәфәгате», «Куян Фазылы», «Мүки Хөсәене», «Куян Хөсәене», «Мәтә Закиры», «Норма Мөхипулла», «Бүдәнә Салих», «Куян Сәхие», «Печән Гаязы», «Аю Гаяны»...

Язучы, «Кичер, кичерә алсаң...» әсәрендә геройга кушамат тагылуын болай дип аңлата: «Безнең авылда Вәгыйзь абыйның гына ике кушаматы бар. Берсе – Герман, чөнки бу – аның яраткан «сүгенү» сүзе. Икенчесе соңгы елларда гына тагылды. Анысы – Күкеле сәгать. Әйе шул. Тәрәзәсе шалт итеп ачылып, аннан ялт итеп Вәгыйзь абый башы атылып чыккач, авылдашлары таккан кушамат. Авыл тарихында булмаган байлык, бер кешегә ике кушамат». «Дөл-дөл» хикәясендә Куян Хөсәене кушаматының килеп чыгышы: «Нәселләрендә ишле бала үстергәнгә, Куян кушаматы тагылган. Әнә шул кушаматка хыянәт итмичә яшәүче Хөсәен абый иде»

Р.Газизнең хикәяләрендә кушаматлар геройларның тышкы, физик үзенчәлекләрен: «Бүдәнә Салих» («Кичер, кичерә алсаң..»), «Аю Гаяны» («Дөл-дөл»); характер үзенчәлекләрен: «Түтүт Гарифы» («Гаян абый әкият сөйли»), «Сәдака Миңнехан» («Әманәт»), «Шәвәли Шәвәлиеч» («Үчтеки Миңлехан»); төбәккә, туган авылга, урынга бәйләнешле: «Норма Сәми» («Кичер, кичерә алсаң...»), «Бәкер Вафич» («Гаян абый хат укый»), «Норма Ягъфәр» («Түттүт Гарифы»); нәселгә бәйләнелешле: «Куян Сәхие» («Дөл-Дөл хикәясе»), «Куян Зарифы» («Түтүт Гарифы»), «Куян Кәримулласы», «Куян Вакыйфы» («Җылылык») яктырталар.

Р.Газиз иҗатында поэтик топонимнар системасы гаять үзенчәлекле сурәтләнгән. Алар әсәрдәге фонны бөтен нечкәлекләре белән генә барлыкка китереп калмыйлар, шул ук вакытта геройларның дөньяны танып белүен, тоемлавын сурәтләүдә дә ярдәм итәләр. Авылның үз яшәеш киңлеге бар. Әдип әлеге киңлекне күз алдына китерүдә топонимик материалдан бик уңышлы файдалана. Хикәяләрендә гидронимнар турында язганда, укучы күз алдына китерерлек, сенсорик тоемлауны арттырырлык

эпитетлардан да файдалана. Автор чишмәне исеме белән атап кына үтми, ә аңа чагыштырулар ясый, эпитетлар өсти: «...Кирмән алыпсатарлары Кардон чишмәсе буена сыгылып-бөгелеп, мәдрәсәдә дога көйләп утыручы шәкертләр сыман атынучы талларга сандугачлар бүләк иткән» («Ак болыт»). «Трайт чишәсенең суын эчтек. Су түгел ул, энем, ширбәт» («Ак Болыт»). «Сәрдәхуш елгасы башындагы каеннардан берән-сәрән генә яфрак оча» («Ак болыт»), «Менә Яке елгасы башындагы уяз да артта калды. Хәтерлисеңме теге Хөснетдин бабайларның Бакырчы чишмәсе юлында күмер яндырганнарын?» («Кичер, кичерә алсаң...»); «Сәрдәхуш елгасындагы Сердәш чишмәгә, исемнәребез уелган каен янына менмичә булмас» («Ак болыт»). Шулай ук аның әсәрләрендә топонимнар: «Кече Кирмән авылына баруым минем» («Ак болыт»). «Менә шул Сәми Ташлы авылдан Краснайга баручы урысның, менә ул урыс тач Әгъзам абыйга охшаган иде, үзе озын, үзе җирән... («Кичер, кичерә алсаң...»). «Барый абыйны Мамадышка илтеп салганда инде гангрена узынган була» («Кичер, кичерә алсаң...»). «Инкыйлабтан соң 1016 йорты булган авыл Су-Елга, Өләүкә, Хәсәнша күченгәч тә зур иде» («Ак болыт»); Микротопонимнар: «Икенче көнне Сукыр урамдагылар башына бәрхет түбәтәй кунаклаган, аягына затлы читек кигән, ак күлмәге өстеннән затлы камзул әләктергән кешене танымадылар» («Ак болыт»). «Аръяк урамындагы Латыйфәттәйләргә төш» («Ак болыт»). «Тиздән Өчпочмак патшалыгы булачак Сайкичүдә үзешчән сәүдәгәрләр «йөгерешә» («Иптәш капитан»). «Беренче булып Югары Зират игътибарыгызны җәлеп итәр («Ак болыт»). «Су-Елгадан Кече Кирмәнгә теркелдәсәгез, иң беренче булып каршыгызга Ризван каеннары чыгар» («Ак болыт»).

Мәгълүм ки, авылда кушамат тагу – ул гадәти күренеш. Авылның дөнья картинасын тагын да киңрәк күзаллау, палитраларын тулырак күрсәтү максатында, автор бу әдәби алымнан оста файдалана.

Рафаил Газиз әсәрләрендәге һәр ономастик берәмлек үзенчәлекле стилистик мәгънәгә ия. Хикәяләрендәге исемнәр эчтәлекне дөрес һәм тулы ачарлык итеп сайланган. Персонаж исемнәренең бай хәзинәсендә татар халкының тарихы, затлы әхлагы, зәвыгы, мәдәни һәм рухи культурасы, хыял-омтылышлары чагыла. Барлык антропонимик категорияләр дә персонажның характер үзенчәлеген тулы ачуда, кеше күңелендәге изге, саф хисләрне уятуда һәм әсәрнең идеяэстетик кыйммәтен сәнгатьле чагылдыруда мөһим чыганак булып торалар.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Рафаил Газиз әсәрләренең ономастик киңлеге гаять мул. Ул – татар тормышының тирән чагылышын тоемларга, татар исемиятенең палитрасын күрергә, туган як матурлыгын аңларга өндәүче талантларның берсе.

Әдәбият:

Газиз Р. Кичер, кичерә алсаң; – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998.
Газиз Р. Ак болыт: (хикәяләр, шигырьләр, мәкаләләр). – Чаллы, 2003. – 224 б. ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның июль ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Атлар җыю

Гаскәргә атлар сатып алу Казанда августның 10ында, сентябрьнең 4ендә вә 29ында булачак. Өч ярымнан дүрт ярымгача булган яшьтәге эшкә сәләтле, аладан башка һәммә төстәге атлар токым вә җенесенә карап, 200 сумнан башлап 1115 сумгача сатып алыначактыр.

Кояш. – 1916. – №991. – 3 июль

Трамвай тәртипсезлеге

Июльнең 5ендә Печән үлчәү чатындагы юллар бозыклык сәбәпле, Екатеринский урамга бара торган вагон, эчендәге кешеләргә хәбәр итми-нитми вокзал ягына киткән дә барган. Күбрәге мөселманнардан гыйбарәт юлчылар протест бирсәләр дә, трамвай хезмәткәрләре катылык белән генә җавап кайтарганнар. Нәкъ шушы вагонга управа әгъзасы Ш.Апанаев эләккән булган.

Кояш. – 1916. – №994. – 10 июль

Кыйммәтчелек мөнәсәбәте белән

Зәңгәр мәсҗед мәхәлләсендә Мөхәммәтҗан Хафизовның сүз кузгатуы буенча меллаларның варидәте [кереме] азлык, аларга вазифа бирелмәве вә хәзерге кыйммәтчелекләр сәбәпле, аларга иганә җыярга карар кылынган вә мәхәллә әһеле арасыннан бу эшкә Шакир Габделгафуров белән Мөхәммәтҗан хафиз тәвәккел ителеп [керешеп], 900 сумга кариб [якын] иганә җыелган. Мөхбирегезгә ирешкәненә караганда, бу иганәне меллаларга бүлү түбәндәгечә, кызык кына булган: Ибраһим меллага 500 сум, шул мәхәлләнең икенче вә өченче имамы булган Сабир хәзрәт белән аның угылына бирәр йөз сумнан 200 сум. Мәхәлләнең беренче мөәзиненә 150 сум, аның ярдәмчесенә 25 сум бирелгән.

Әсирнең туганнары вә белеш-танышларына

Казанның вилаять земствосы комитеты исеменә Германиягә әсир төшкән 25 нче сибирский стрелковый полкның нижний чины Галиулла Шәһидуллин дигән кешедән ашамлык әйбер сорап, үтенеп хат килгән. Комитет бу хат иясенең ыруг-кардәшләрен никадәр эзләсә дә таба алмаган. Шунлыктан идарәбезгә мөрәҗәгать итеп, гаребтә [көнбатышта] ач калган бу бичарага мөрәҗәгать итүләрен үтенеп, ыруг-карендәш яхуд белеш-танышлары вә гомумән мөселманнарга гарыз итүне [белдерүне] үтенәдер. Бу әсиргә посылка яки хатны Красный крест аркылы җибәрергә мөмкиндер. Адресы менә болай: Германия, г.Нюрнберг-Бавария, лагерь военнопленных, 3 рота, 8 отд., Галиулла Шагидуллину.

* Даталар иске стиль белән бирелә.

Сугыш сафыннан сәлам. Минск

Гает фитыр намазына җыелганыбыз хәлдә, сугыш сафыннан кардәшләребез вә танышларыбызга сәлам вә тәбрикләребезне җибәрәбез. Штабс капитан Еникеев, подпоручик Әхмәров, подпоручик Бәкерев.

Кояш. – 1916. – №999. – 26 июль

Яңа бистә аркылы

Яңа бистә аркылы шакшы түгү кәрваны үткәрү мәсьәләсе бу көн булачак шәһәр думасы мәҗлесендә каралачагыннан вә бу карар катгый карар булачагыннан, һавасы начар булган бу мәйданнарда торучы мөселманнарны бу мәсьәлә яхшы ук тәшвишкә [куркуга] салган. Бу урында шакшычылар кәрваннары үткәрелә калса, болай да һавасы бозык Иске вә Яңа бистәләрдә торырга да мөмкин булмас, дип куркалар. Шуның өчен бу эшнең булдырылмавы хакында урыннарга мөрәҗәгать итеп, үтенечләрдә булынырга карар кылганнар. Шул җөмләдән мөселман гласныйларының да бу көнге дума мәҗлесеннән калмауларын[1] вә мөселман җәмәгасенең теләгән тәкъвия кылып [яклап], Яңа бистә аркылы шакшы кәрваннары үткәрү юлы ясауны булдырмаска тырышуларын үтенәләр.

Вакыйгалардан бер вакыйга

Пеләтәндә күмәч ябып торучы Җиһаншинаның Фәхретдин Заһидуллин дигән күмәч ябучы хезмәткәре бар икән, ди. Шул ук тирәдә Хәкимулла Вәлиуллин дигән извозчик та бар, ди. Болар көннәрнең берендә бергәләшеп эчәргә теләгәннәр. Эчкене эзләп-эзләп таба алмаганнар, ди. Чөнки әче квас сатучылар, шикәр комы тапмаганга күрә, мөштәриләрдән [сатып алучылардан] эчемлек бәрабәренә акча алмыйлар, шикәр комы сорыйлар икән, ди ки, ике «сәйях» тә Казанның һәммә «дикъкать итәрлек» урыннарында шикәр комы сорарга мәгъруз калганнар. Ахырында «ике сәйях», киңәшеп, мондый бер эш эшләгәннәр: күмәчче үз хуҗасының 6 потлы бер капчык шикәр комын урлаган, извозчик шуны күчерү хезмәтен үтәгән. Ахырында болар Троицкий урамында бер ятерен эчке (квас) сату «мәркәз»енә барып кергәннәр. Мәркәздә боларга якты йөз, татлы сүз, әче квас – һәммәсе туяр булып торган. Квасчы бер савыт квас биреп, «сәйях»ләр шул ук савыт берлә шикәр комы сатып, кәеф-сафа корып тормакталар икән. Кинәттән бер эш булып киткән: «сәйях»ләр кулга эләккәннәр...[2]

Кояш. – 1916. – №1000. – 28 июль

Халык уразасы

Мәмләкәт химаясендә хезмәт итмәктә булган каһарман гаскәрләребезгә ит азыгын иркенләтү-күбәйтү максаты белән һәфтәсенә [атнасына] 4 көн – сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе вә җомга көннәрендә хайван бугазлаудан, ит сату вә алу һәм ит ашаудан саклану уразасы башланды. Бу пост уразасы гади тормыштан аермасыз рәвештә бара. Итле ашлар бик җиңеллек белән үсемлек вә сөтле ашларга алмаштырылып торалар вә һичбер аерма хис итмидер.

Кояш. – 1916. – №1001. – 31 июль. ■

---

[1] Думада моны тикшерү «бик озынга сузыла, ..., әфкяр [фикер] бик төрлеләнеп китеп, бу мәсьәлә яңадан күп әгъзалы мәҗлескә калдырыла» (№1001, 31 июль).
[2] Бу елларда Россиягә «коры закон» кертелә.

КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

ӘҖӘТКӘ – МӘҖӘТ*

Бер шагыйрь бер бай адәмнең ханәсенә барды. Байны мәдехләп (мактап) шигырь әйтте. Ул бай адәм моңар бик хушнуд (рәхәтләнү) булды. Әйтте: «Хәзердә минем кулымда акчам юк, ләкин ашлыгым бик күп, иртәгә кил, сиңа ашлыктан бернәрсә биреп җибәрермен», – диде. Шагыйрь иртәгесен янә байның ханәсенә килде. Бай әйтте: «Нихәл, ник килдең?» – диде. Шагыйрь әйтте: «Кичә ашлык бирермен, дип вәгъдә кылган идең, аның өчен килдем», – диде. Бай әйтте: «Гаҗәпсең, ахмак икәнсең, син мине сүзең белән хушнуд кылдың, мин һәм сине сүзем белән хушнуд кылдым», – диде.

СӘЯСӘТ НӘРСӘ УЛ?

– Сәясәт нәрсә ул, әфәнде, беләсеңме?

– Юк.

– Һәй, тиле, шуны да белмисең! Менә нәрсә ул: әгәр патшаны патша алдаса, ул – политика, ягъни сәясәт була. Әгәр купец купецны алдаса, ул коммерция була. Әгәр мулла мулланы алдаса, ул хәйләи шәргый була. Әгәр мужик мужикны алдаса, ул мошенничество була. Аерма шунда гына: алар һәммәсе бернәрсә, тик кешеләренә карап, исемнәре генә башкарак.

ТӘРБИЯ

–Улым, син Борһан белән уйнама, ул – тәрбиясез, хулиган малай.

– Ул үзе минем янга килә бит.

– Килсә, син аны кыйнап җибәр!

ЧАЛБАР НӘРСӘДӘН?

Укытучы балаларга йоннан ничек тукыма ясалганын өйрәтә:

– Сарыкны тоталар да йонын кыркалар. Аннан соң ул йонны төрле чүпләрдән әрчиләр дә эшкәртәләр. Шуннан тукыма була. Ул тукымадан теләгән нәрсәңне тегеп киясең. Аңладыгызмы? Йә, әйт инде, Нәҗип, синең чалбарың нидән тегелгән?

Нәҗип:

– Әнинең иске юбкасыннан.



МАКТАНЧЫК АТА

Бервакыт малае арифметикадан «бишле» билгесе алып кайткач, атасы:

– Алма агачыннан ерак төшми шул, минем малай бит ул! – дип мактанып куйды.

Икенче вакыт малаеның «икеле» алуын ишеткәч, ул, хатынына ачу белән карап:

– Аңгырадан аңгыра тумый, ни тусын! – дип, пыр тузынды.

КЕМ СҮГӘ?

Түбә өстендә кәҗә бәтие басып тора икән, түбәнең астыннан бүре үтеп бара иде. Кәҗә бәтие бүрене эт итеп сүкте. Моңарга каршы бүре әйтте:

– Юк, мине син сүкмисең, мине син басып торган түбә сүгәдер, – диде.

ИГЪТИБАРЛЫ ИР

Бер кеше хатыны белән кызларының туена баргач, табында ашап-эчеп утырганда, хатынына карап торган-торган да:

– Бәрәч, хатын, күзеңә ак төшкән түгелме соң? – дип куйган. Хатыны моңарга каршы:

– Кыз чагымнан ук шулай иде бит, – дип әйтте ди.

МАЙ ЧҮЛМӘГЕ ТЫШЫННАН УК БИЛГЕЛЕ

Бер кыз әнисенә мактанган:

– Кызык иттем, идарә янынннан үткәндә, авырый икән бу, дип белсеннәр өчен, чатанлап үттем, – дигән.

– Чатанлап түгел, биеп үтсәң дә синең ялкау икәнеңне бөтен авыл белә инде, кызым, – дигән анасы.

ОХШАМАГАН РӘСЕМ

Бер кеше үзенең рәсемен ясаткан. Иптәшеннән:

– Бу рәсем миңа охшамаганмы? – дип сораган. Иптәше:

– Юк, бу сиңа охшамаган, – дип җавап биргән.

– Кай төше охшамаган?

– Әнә, кара: бу рәсемдә син кулыңны үз кесәңә тыккансың, ә синең кулың гадәттә күбрәк кеше кесәсендә була, – дигән.

ТЕАТРДА

Театрларның берсендә, хатын-кызлар зур эшләпәләр киеп утырганлыктан, артта утырганнар бернәрсә күрә алмый иде. Моны белгәч, театр мөдире: «Ханымнардан эшләпәләрен салып утыруларын үтенәбез!» – дигән язу элеп куйды. Ләкин һичбер хатын эшләпәсен салмады. Шуннан соң мөдир: «Кырык яшьтән үткән хатыннар эшләпәдән утырсалар да ярый», – дигән икенче кәгазь ябыштырды. Шуны күрү белән барлык хатыннар эшләпәләрен салды.

**Биредә К.Насыйри туплаган, Г.Бәширов, М.Бөдәйли җыйган мәзәкләр файдаланылды.* ■

Вак-вак ләтыйфәләр* һәм хикәя кисәкләре

Казан

Садыйк хаҗи Галикәев[1] һәм аңар табигъ[2] булган байлар Романовлар юбилее мөнәсәбәте илә шәһәремез өчен бер ятимханә – приют ачарга карар бирделәр.

Мал алучы:

– Садыйк абзый, бик кыйммәт сатасыз, минем бу хакка алыр хәлем юк.

Садыйк абзый:

– Әфәндем, кыйммәт булса безнең өчен түгел, милләт өчен, сездән алынган артык ике тиен мотлакан[3] приют кассасына салыначак. Ана, прилавка астына кара, сезнең ике тиеннәрегездән яхшы ук бер приют үсеп килә инде.

«Ялт-йолт» журналы. – 1913. – № 59. – Б.8.

Үземә кыйммәтрәк тора

– Абыстай, сәдака рәхим итмәссезме?

– Мә, тот бер тиен. Алла бирсә, хәзрәт рәсүл рухына, пәйгамбәрләр рухына, хуҗа Бәһаветдин рухына, бабайлар, әткәй, әнкәй рухына Коръән укып, дога кылырсың.

– Бер тиенгә шулкадәр кешенең рухына Коръән укып дога кылыргамы?

– Абыстай, әллә сез гакылыңыздан шаштыңызмы? Үземә кыйммәтрәк тора.

Идарәдә

Мөхәррир (наширгә кулъязмасын биреп):

– Ышаныңыз, нашир әфәнде, минем бу мәкаләм бер җирдә дә, бервакытта да басылганы юк.

Нашир:

– Ышанам, ышанам сезгә. Бер җирдә дә басылмаган һәм басылмас та.

Җылауның сәбәбе

Бер байның җеназасында бер озын гына кеше акырып-акырып җылый. Аннан сорыйлар:

---

* Ләтыйфә – мәзәк.

[1] Галикәев Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы (1847-1919) – Казан сәүдәгәре һәм җәмәгать эшлеклесе.
[2] Табигъ – иярүче, буйсынучы.
[3] Мотлакан – һичшиксез.

– Сез әллә мәрхүмнең кардәшеме идегез?

– Юк.

– Алай булгач, ник алай акырып җылыйсыз?

– Мәрхүм миңа кардәш тиешле булмаган өчен!..

«Ялт-йолт» журналыннан – 1913. – №49. – Б.12-13.

Мачы

Мачы ашаганда ник күзен йомып ашый?

Аның сәбәбе шул имеш. Кыямәт көнендә Аллаһы хәзрәти: «Хуҗаң сине туйдырдымы?» – дип сораячак.

Мәченең бөтен эче усаллык, явызлык берлән тулы булганга, аңар туйдырды, дип әйтү авыр булыр имеш, ди. Инде туйдырмады, дип әйтсә, Ходай ялганны сизә дә җәза бирергә тиеш була. Авызы ашаса да, ләкин күзе күрмәсен өчен, Аллаһы алдында туйдырмады, дип җавап бирер өчен күзен йомып ашар имеш, ди.

Бу хәзерге бәгъзе бәндәләрнең яхшыга күз йомып, яманны гына күрүләре кебегрәк икән.

«Ялт-йолт» журналыннан. – 1913. – №50. – Б.11.

Энә берлә лом

Энә берлә лом бәхәскә керделәр, ди. Энә әйтте, ди: «Хаҗи абзый мине йотар», – дип; ә лом әйтте, ди: «Мине йотар», – дип. Шуннан соң икесе дә Хаҗи абзыйга үзләренең Хаҗи абзыйның Кәгъбә күргән корсагына керәселәре килгәнлекләрен бәян иттеләр. Хаҗи абзый энәгә карады да:

– Син кем энәсе буласың? – дип әйтте, ди.

Энә:

– Мин Мәгълифә карчык энәсе булам, – диде, ди.

Хаҗи абзый:

– Сине йота алмыйм, син кеше хакы икәнсең, – дип әйтте, ди.

Энә чыгып китте, ди. Шуннан соң лом үзенең йотылуын гарыз кылды, ди.

– Соң син кем ломы буласың? – дип сорады, ди.

Лом:

– Иван Захарычныкы, – дип әйтте, ди.

– Ә.... Урысныкы икән, – дип әйтте дә, голт итеп йотты-җибәрде, ди.

Иртәгесен Гали Хаҗи йөз мең берлән шарт иткән хәбәре бөтен каланы яңгыратты, ди.

Шалкан – колмак

Шалкан сәфәргә чыгып китте, ди. Бара торгач җилбердәп килә торган колмакка очрады, ди.

Шуннан соң колмакка:

– Әссәламегаләйкем, исерткеч, –дип әйтте, ди.

Колмак:

– Вәгаләйкемәссәлам, корсак күперткеч, – дип җавап бирде, ди.

Бу җавапка шалкан бик хурланып әнкәсенә кайтып елады, ди, колмак миңа шулай дип әйтте, дип бик зарланды, ди.

Әнкәсе:

– Балам, шалкан! Борынгылар, ни чәчсәң, шуны урырсың, дигәннәр. Үзең яхшы сүз әйтсәң, яхшы җавап ишетер иден, – дип әйтте, ди.

Шуннан соң шалкан тагын сәфәргә китте ди. Тагын теге колмакка очрады, ди.

Колмакка:

– Әссәламегаләйкем, чалмалы баш, – дип әйтте, ди.

Колмак:

– Вәгаләйкемәссәлам, тансык аш, – дип җавап бирде, ди.

Шуннан соң шалкан үз-үзенә: «Урманга ни дип кычкырсаң, урман сиңа шул җавапны кайтара, дип әйтте дә инсафка кайтты», – ди.

«Әүлия»[4]

«Ялт-йолт» журналыннан. – 1913. – №50. – Б.11.

Текстны һәм искәрмәләрне басмага ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

[4]«Әүлия» – Галиәсгар Камалның (Камалетдинев Галиәсгар Галиәкбәр улы) псевдонимы (1879-1933) – күренекле драматург.

Мирасворд

1915-1919 елларда Оренбургта эшләгән татар театр труппасы

Нәкый Исәнбәт драмасы

Төп, нигез (иск.)

Татар журналы

Тойгы

VII-XI йөзләрдә Азиядә яшәгән төрки телле кабилә

... Ногман

Фронтовик шагыйрь Бәдрүш ...

Гаскәр башлыгы

Бәрхет (иск.)

Рәт, мәгънә, җай

Борынгы Рим армиясендә ярдәмче атлы гаскәр

Актаныш районындагы авыл

... Булгакова

Гарәп артикле

Әдәби әсәр, китап бүлеге

... борчасы

Мордовиядәге татарлар күпләп яши торган район

Әхмәт ... (борынгы суфи шагыйрь)

Нәүрәп

Нурихан ...

Әмирхан Еники хикәясе

Кызыксыну, дәрт, омтылыш (иск.)

Кәҗә бәтие (диал.)

Гурий Тавлин трилогиясе

Сыр сорты

Ишарә

Күңел, хәтер (иск.)

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

Корьән сүрәсе

Ким Ир ...

... - баба йоласы

Шамил Маннаповның әдәби тәхәллүсе

Коры елга

Вавилон Алласы

Мактау шигыре, мәдхия

... Идрисов (А.Матросов батырлыгын кабатлаган миллаттәшебез)

Шумер-аккад мифологиясендә кояш Алласы

Эфиопия акчасы

Баян, Гайсин, Әхмәдиев

Шагыйрь, тәрҗемәче ... Гобәйди

«... Скала» (Милан опера театры)

Бизәкле тукымадан яки шнурдан үреп эшләнгән билбау

Борынгы төрки язма

Рәис Габдулла төзеде.

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: алап, Ашлы, «Күги», Бату, карачы, Салих, «Асар», Эвтерпа, гайре, ти, Ваан, сап, богыл, сага, Салахов, лат, Усманов, фида, Мишә, тако, «Урал», Али.

Өстән аска: кисап, ләү, ас, хосус, ГУЛАГ, га, пси, иравыл, арту, алай, Арк, эра, хромка, «Айвенго», виола, арбалет, Фәйзи, ач, Рисаләи, Латыйп, Ага, патша.

Губернатор сарае.
Казан.
1894 ел

«Безнең мирас»

елъязмасы / июль

• 495 ел элек (1521)

Казанда Ширгали (Шаехгали) ханга каршы халык баш күтәрә. Ханны төшереп, аның урынына Сәидгәрәй (Сәхибгәрәй) хан булып утыра.

• 240 ел элек (1776)

Күренекле сәяхәтче-галим Ив.Ив. Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларның тасвирламасы» дигән китабы дөнья күрә. Китапта татарлар хакында да бай мәгълүмат бар.

• 235 ел элек (1781)

Казан губернасында яңа административ бүленеш хакында карар игълан ителә.

• 110 ел элек (1906)

17 июльдә күренекле композитор Латыйф Хәмиди (1906-1983) дөньяга килә.

• 90 ел элек (1926)

Июль ае башында Гадел Кутуй, татар шахтёрларының хезмәте һәм тормышы белән танышу өчен, Донбасска сәфәргә чыга.

• 85 ел элек (1931)

15 июльдә Урал өлкә татар театры ачыла.

«Яңалиф» журналында Һади Такташның «Киләчәккә хатлар» поэмасының «Өченче хат»ы басыла.

• 75 ел элек (1941)

13 июльдә Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш армиягә алына.

• 65 ел элек (1951)

«Совет әдәбияты» журналында Әнвәр Давыдовның «Кояшлы көн» поэмасы дөнья күрә.

• 25 ел элек (1991)

Чаллыда «Мирас» фондының яңа бүлеге оештырыла. Бүлекнең төбәк советына фольклор галиме Фатих Урманчеев һәм публицист Фаяз Дунай сайлана. ■

РЕЗЮМЕ

Июльский номер журнала открывается постоянной рубрикой «В мире останется слово моё». На сей раз слово предоставляется Сибгату Хакиму. В рубрике «Историческое наследие» публикуются статьи: «Булгар. Восточная палата», «Хитрость Чингизхана» (А.Мухаммадиев), «Крещеная Сарда» (Н.Петров-Текин), «Языческие феномены в веровании у крещеных татар» (Л.Константинова), а также цикл статей, посвященных татарам Нижнего Новгорода и Старокулаткинского района Ульяновской области. В рубрике «Литературное наследие» к вашему вниманию представлены «Благодатное знание» (Ю.Баласагуни), «Махатма Еники и Батыев» (Н.Фаттах), письма Гараю Рахиму, написанные Туфаном Миннуллиным, также можете насладиться чтением воспоминаний об Афзале Шамове, изложенные его дочерью А.Шамовой, в рубрике «В глубине памяти» .

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

SUMMARY

The July issue of the magazine is opened with the traditional heading «My words stay in the world». This time the floor is given to Sibgat Khakim. In the heading «The historic heritage» there are articles «Bulgar. The Eastern chamber», «The cunning of Genghis Khan», (A. Mukhammadiev), «Baptized Sarda»

(N. Petrov-Tekin), «Pagan phenomenon in belief of Kazan province baptized Tatars» (S. Maximov), «An experience of studying history of baptized Tatar villages» (L. Konstantinova), and also a compilation of articles about the Tatars of Nizhniy Novgorod and Starokulatkinskiy district of Ulyanovsk. In the heading «Literary heritage» there are presented «The blessed knowledge» (U. Balasaguni), «Makhatma Eniki and Batiev» (N. Fattakh), letters from Tufan Minnullin to Garay Rakhim, and in the heading «From the depth of memory» you can enjoy reading memoirs about Afzal Shamov written by her daughter A. Shamova.

THE MAGAZINE CONSTANTLY BRINGS TO LIGHT ALL THE MOST IMPORTANT EVENTS OF OUR NATION LIFE.

Ф.Халиков
«Татарстанның халык артисты Н.Дунаевның керәшен киемендә сурәтләнгән портреты». 2013.
Киндер, майлы буяу

Ф.Халиков
«Керәшен кызлары киемендә сурәтләнгән Эльвира портреты». 2013.
Киндер, майлы буяу

И.Максимов
«Кышкы пейзаж. Уткино (Ылыя) авылы».
Кәгазь, акварель

АЛДАГЫ САННАРДА:

«Романга бәян тәкъдим итәм. Бу ни соң – яңа жанрмы? Билгеле, мондый жанр була алмый. Шулай да, тормышта төрле хәлләр очраштырып торуын искә алсаң, язганымның «Гасырдан озынрак сузылган көн» дигән романга өстәлгән повесть икәнлеге аңлашылыр... Әйтергә кирәк, бу бәянда Чыңгызхан турында күчмә халыкларның телдән-телгә йөргән бер риваяте, – чынбарлыкка дәгъва итмәсә дә, тарихи хәтерне яңарта торган миф файдаланылды.»

Чыңгыз Айтматов. «ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ»

Романга бәян

«Сабирҗан агайны бу көн авыру бик баскан, тәмам хәлсезләндергән иде. Мең бәла илә генә башын күтәреп, өстенә юеш бишмәтен киеп, акрын гына контор алдына барды. Анда күп хезмәткәрләр кенәгәләрен кулларына тотып, бүрекләрен тышта калдырып, яланбаш конторга керәләр дә аз бер вакыттан соң кайсы сүгенә-сүгенә чыга, кайсы:
«Талыйсыз, күзегезгә керсен», – дия каргап, үртәлеп чыга иде».

Касыйм Бикколый. «САБИРҖАН АГАЙ»

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – 54132 (П-2343)
РОССИЯДӘ – 70275
www.beznenmiras.ru

4 612750 670172

№007 / 2016